үтә җылылык белән сурәтләнә. Автор идеалындагыча, халык табигать белән бергәлектә яши, хезмәт белән көн күрә. Чирмешән буйларындагы бүгенге күренешләр исә балачак сурәтләреннән кискен аерыла: елга ташландык җирләрдән агып үтә, өстен күгәргән яшел пәрәвезләр, бака уылдыклары каплаган, матур, чытлы кызларының кер чайкый торган басмаларында да каз-үрдәкләр генә күренә. Тормыш, яшәү билгесе булмау авторның күңелендә әрнү, кешеләрнең бу дәрәҗәгә төшүенә ачу уята. Төрле метафоралар, җәенке чагыштырулар эмоциональ фонны тагын да көчәйтә.

Язучы фикеренчә, «татар дөньясының нәгызе, куе боткасы» әнә шуннан башланып китә. Монда Чирмешән елгасына җиткәнче, бер-ике рус, чуваш авылын санамаганда, тыгыз булып татар авыллары урнашкан. Автор аларның наданлык, карангылык эченә батуын ачынып яза. Багыш, Киксәр авылларын сурәтләүләр килеп туган мәсьәләнең катлаулы һәм татар авыллары өчен типик булуын, тиз арада аннан чыгу юлларын эзләү кирәклеген дәлилли.

Укый-яза белмәү, халыкны әйдәп барырга тиешле кешеләрнең – муллаларның караңгылыгы, әфьюн белән мавыгуы, эчкечелек, эшсезлек – менә авылны мөшкел хәлгә китергән сәбәпләр. Автор бу проблемаларны төрле геройларга бәйләп күтәрә. Мәсәлән, приговорны тәрҗемә итәргә кеше таба алмау заманы өчен проблема булып аңлашылса, мулланы указлы итү өчен имза урынына тамгалар җыю геройларны тәмам шаккатыра. Ялкаулыкның халыкка китергән зыяны укучыга авылның мулласы, хатын-кыз образлары аша җиткерелә. Авылның иң изге саналган урыннарыннан берсе – мәчет янында да әрем, алабуталар үсә. Мулланың үз бакчасында да бәрәнгеләре «боегып», ә эт эчәгеләре «яшәү, гөлләнү хокукын алып» утыралар. Ялкаулык муллага гына түгел, авылдагы бөтен бәндәгә сеңгән. Көпә-көндез җыелышып буш сүз сөйләшеп утыру – авыл кешесе өчен гайре табигый хәл. Шулай булуга карамастан, бүгенге авыл моңа ияләшеп беткән. Матурлык, чисталыкның гәүдәләнеше булган татар хатын-кызларының да вакыты урам уртасында җыелып, кычкырып сөйләшү, шаркылдап көлешү белән үтә, алар инде «хатын-кызлык нәзакәтен» дә югалтканнар. Гомумән, үсеш, алга китеш юк, булган кыйммәтләр дә акрынлап югала. Шул рәвешле автор конкрет авыллар мисалында милләтнең киләчәге мәсьәләсен күтәреп чыга, һәм килеп туган проблемаларны мәгърифәтчеләрчә хәл итү ягында тора.

Әлбәттә, язучының бу әсәре дә эшләнеше, сурәтләү чаралары ягыннан йомшак. Характерлар тулысынча ачылып бетми, гомумиләштерүләр тиешле дәрәҗәдә түгел. Әмма автор халыкның яшәү рәвешен тирәнтен

белеп, заманның актуаль проблемаларын күреп, аларны бергә төенләп бирә алуга, үткән, бүгенге һәм киләчәк яссылыкларында сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен күрсәтүгә ирешкән. Язучының вакыйгалар чылбырын тирә-як авылларда йөрергә чыккан егетләр күргән тәртиптә укучыга тәкъдим итүе дә үзенчәлекле.

ӘДӘБИЯТ

1. Гуляев Н. А. Теория литературы: учеб. пособие для филол. спец. пед. ин-тов. – 2-е изд., испр. и доп. – М.: Высш. шк., 1985. – 271 с.
2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.
3. ТР ФА Г. Ибраһимов исем. ТӘҺСИнең ЯҺМҮ: ф. 57, тасв. 1, с.б. 19.

***Р. Г. Галиуллин***
***Казан***

## Т. ӘЙДИНЕҢ «ЕЛАН УГЫ», «ИБЛИСКӘ РИШВӘТ» РОМАННАРЫНДА ҺӘМ «БОҖРА» ПОВЕСТЕНДА ДЕТЕКТИВ СЮЖЕТНЫҢ РОЛЕ

Язучы Тәүфикъ Әйди (1941–2001) татар әдәбиятына XX гасырның соңгы чирегендә аяк баса һәм 90 нчы елларның демократик үзгәрешләр чорында үзенчәлекле каләм иясе буларак ачыла. Әдип татар әдәбиятында сәяхәтнамәләр жанрын тернәкләндереп җибәрү һәм аны яңа биеклеккә күтәрүдә күп көч куя. Язучы каләменнән төшкән детектив-психологик роман, повесть, хикәяләр шулай ук әдәбият тарихында күренекле урын биләп торалар. Үзенчәлекле стиль белән иҗат ителгән һәм чит илләрдәге татарлар тормышын үзәккә алу ягыннан кызыклы бу әсәрләр танылган татар галимнәре һәм язучылары Тәлгат Галиуллин, Флүн Мусин, Нурихан Фәттах, Равил Фәйзуллин һәм башкаларның игътибарын җәлеп итә.

Татар әдәбиятында беренче детектив әсәр – Заһир Бигиевнең «Меңнәр, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы XIX гасырның соңгы чирегендә, мәгърифәтчелек идеяләре чәчәк аткан чорда дөнья күрә. Детектив (лат. Detection – ачу, ачыклау, шуннан ингл. Detective – җинаятьчеләрне эзләүче шымчы, полиция агенты) – җинаятьне ачу барышында дөреслек җиңеп чыккач чишелә торган, явызлык һәм яхшылык конфликтына корылган әдәби әсәр (1, 45–46). Т. Әйдинең 1978 елда «Казан утлары» журналында басылган «Боҗра» повесте әлеге жанр таләпләрен күздә тотып иҗат ителгән. «Боҗра»да авторның милициядә эшләү чоры

чагылыш тапкан. Ф. Мусин билгеләвенчә, әсәр «саф» детективка якынрак тора (6, 170). Ул «Тасманур» заводыннан бер тонна көмеш урлаучыларны эзләп тотуны тасвирлый. Игътибарын тулысынча диярлек шушы җинаятьне тикшерүгә юнәлтеп, автор бу эшнең шактый катлаулы төс алуын, аңа тотынган геройлардан бик күп эзләнү, уйлану, криминалистик осталык соравын күрсәтә. Әйтергә кирәк, әсәрдә җинаятьләрне ачу эшенә романтик караш белән полемикага керү сизелә. Автор ялтыравык маҗаралыктан качарга тырыша, җинаятьне ачуның прозаик ягына күбрәк игътибар итә кебек. Нәҗибә Габдуллина, Җәмил Гайнуллинны һәм Айбулат Байчуринны берләштергән ясалма мәхәббәт өчпочмагы төенләнештән чишелешкә кадәр озата килә. Нәҗибәнең асылда Җәмилләр белән бер караклар төркеменнән булуы һәм тикшерү эшләрен ялган эзгә төшерү өчен үзенә күптәннән гашыйк өлкән тикшерүче Айбулат белән мәхәббәт уенын башкаруы әсәрне маҗаралы итә. «Божра» детектив жанр формасы таләпләренә буйсынса да, традицион, классик детектив әдәбиятка туры килми, чөнки шул чорда өстенлек иткән соцреализм иҗат методы йогынтысы сизелә. Әсәрнең төп юнәлеше совет чынбарлыгына, совет җәмгыятенең камиллеккә омтылуына, совет милициясе аркылы чын совет кешесенә дан җырлаудан гыйбарәт.

Г. Ибраһимовның «Тирән тамырлар» романы «Фәхрине үтереп ташладылар», дигән атаклы җөмлә белән башланып китә дә, фабула җебе шуңа бәйле рәвештә сүтелә, үстерелә, сәбәплелек бәйләнышы каһарманнар язмышында ачыла. «Елан угы»ның төбендә дә шул ук алым ята. Алдынгы карашлы, һәр яктан килгән, уңай герой комиссар Шиһабетдиновны чит, ят, тар бүлмәдә үле килеш табалар, шуннан тикшерүләр, төрле төркемнәр арасындагы көрәш һәм атышлар башланып китә.

«Елан угы» 1982–1989 еллар аралыгында языла. Бу вакытта әле җәмгыятьтә коммунистлар идеологиясе хөкем сөрә. Шунлыктан язучы да гадәт буенча басып алучылар ягын алып, Бохара әмирлеген битәрләү юлына баса. Ягъни үз милләтенең мөстәкыйльлеге өчен көрәшкән бохаралылар түгел, ә ничәмә дистә еллар үзенең эчке тәртипләре белән яшәп яткан илгә бәреп кергән чакырылмаган кораллы көчләр – инкыйлабчылар уңай герой буларак тасвирлана. Чекага Үзәктән җибәрелгән революция пәһлеваны хәрби комиссар Баһаветдин Шиһабетдинов, теркәү бүлеге башлыгы Фарукҗан Байкучатов аек акыллы, ифрат намуслы, Ленин фиркасе эшенә бирелгән кешеләр. Илдәге тәртипне вата-җимерә үз властен урнаштырган Чеканың терәге – ярлы-ябага Иргәш, көтүче Амантай, чәйханәдә хезмәт күрсәтүче нәселсез кыз... Бу эшләргә шул якларда туып-үскән кешеләрдән тартылган Рахманкол, Симиниев,

Әминевләр Рәсәйдән иңгән бәхетне кабул итә алмыйлар, алар иҗтимагый аңнары артта калган кешеләр буларак сурәтләнә.

Т. Галиуллин билгеләвенчә, авторның безнең көннәр өчен ифрат кирәкле, файдалы һәм отышлы юнәлешне «әрәм» итүенә игътибарны юнәлтергә кирәк. «Т. Әйди романында Урта Азия фаҗигасендә катнашкан татарларны яңачарак сурәтләү, аларның җирле халыкларның омтылышын аңларга, төрки халыкларны бүлгәләүгә алып килгән төеннәрне үзәккә алырга мөмкинлек бар иде. Ул – файдаланылмаган», ди ул (5, 221). Бүгенге көн күзлегеннән чыгып фикер йөрткәндә кайбер идеологик кимчелекләре булуга карамастан, «Елан угы» романында Бохара төбәгендә яшәүче татарларыбыз тормышы, аларның җирле халык белән бәйләнеше җанлы тасвирланган. Романның укылышлы, интригаларга бай булуында, әлбәттә, детектив сюжетның роле зур.

Нинди җир ул Ватан? Сатлыклар кемнәр? Татар хәрбиләре ни өчен легионга керә? Әсирләрнең алман хәрбиләре белән бәйләнешләре нинди була – әнә шушы сорауларга җавап эзләгән «Иблискә ришвәт» романы 1995–1996 елларда иҗат ителә. Роман Икенче Бөтендөнья сугышында Германиягә әсир төшкән татарларның тормышын һәм язмышын үз эченә ала. Әсир татарларны берләштерүче сыйфатлар уртак: алар барысы да үз юлларын сайлый алмый икеләнә. Кайсысы дөрес: СССРга хезмәт итүме, әллә Германиягәме? Кайсы империянең җиңүе татар милләте өчен отышлырак? Ничек исән калырга? Кара эш башкарган Хәлимәләр, Саматлар өчен әсирлек вакытлы күренеш. Алар мөмкинлек тууга моннан качып, туган илләренә кайтачаклар. Көнчыгыш министрлыгында хезмәт иткән, укыган, гыйлемле Янгураз һәм Шәмсирләр киләчәкләрен Германия белән бәйләп карыйлар. Вакыйгалар геройларның максатка ирешү, исән калуга омтылышлары белән үрелеп үсә бара. Совет гаскәрләре Германия чигенә якыная барган саен аларның хис-кичерешләре, кыйблалары үзгәрә башлый. Баштан ук үз сүзләрендә нык торган Янгураз, Хәлимә, Шәмсир кебекләр кыйблаларына тугры кала. Самат, Рәмзи ишеләр кисәк үзгәрә, милләт сүзен кулланудан тыела, үзләрен аяп калу өчен алман ягына чыккан татар әсирләренә каршы фетнә оештыра башлыйлар. Саматның Янгуразга һөҗүме шуңа дәлил. Совет гаскәрләре Германиягә бәреп кергәч, Хәлимәләр, Саматлар аларга кушыла. Аларны исә анда газиз ватаннары түгел, Сталин төрмәләре көтә... Алман җитәкчелегенең сәясәте дә тәгаен ачыклана. Аларга үз башлары гына кадерле, татар әсирләренә булган хөрмәт вакытлы гына күренеш, сугыш аларның җиңүе белән тәмамланса, татарларның язмышы төгәл билгеле түгел. Аларның да алманнарга кол булуы бик ихтимал. Шәмсирнең Янгуразга әйткән сүзләрендә

үз дәүләте булмаган милләтләргә кайда да бер кояш икәнлегенә ачыну сизелә. «Өметләребез акланмады сыман, туганкай. Бердән, без итәгенә ябышырга тырышкан җан да Иблис бугай. Икенчедән, безнең өчен аеруча күңелсезе – бу Иблис беренче Иблистән көчсезрәккә охшый», − ди ул (4, 308). Шулай да татар милләте күтәреләчәк әле. Моның өчен Янгуразлар бар. Т. Әйдинең «Иблискә ришвәт» романы Бөек Ватан сугышына милли күзлектән чыгып бәя бирү, шул чордагы татар әсирләре тормышын тасвирлау ягыннан үзенчәлекле.

Атап үтелгән әсәрләр укучыларны сюжет сызыгының кызык, кискен, көтелмәгән булуы белән җәлеп итә. Т. Әйди әлеге әсәрләрендә детектив сюжетны оста һәм урынлы файдаланган.


ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

2. Әйди Т. Божра. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 208 б.

3. Әйди Т. Елан угы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1991. – 368 б.

4. Әйди Т. Иблискә ришвәт. – Казан: Аваз, 2000. – 376 б.

5. Галиуллин Т. Үткәнеңнән гыйбрәт ал... – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 256 б.

6. Мусин Ф. Детектив турында // Казан утлары. – 1985. – № 10. – 170 б.



***Ф. Х. Миңнуллина***
***Казан***


## М. ГАЛӘҮНЕҢ «БОЛГАНЧЫК ЕЛЛАР» ҺӘМ «МӨҺАҖИРЛӘР» ӘСӘРЛӘРЕН СӘХНӘЛӘШТЕРҮДӘГЕ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘР


*Мәкалә 18-24/2012(Г) номерлы Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең яшь галимнәр өчен Республика күләмендә оештырылган грант кысаларында язылды.*


Соңгы еллар татар драматургиясендә проза әсәрләренә нигезләнеп инсценировкалар язу активлашты. Ю. Сафиуллинның «Ирдәүкә», Ф. Садриев һәм Л. Гәрәеваның «Көтелмәгән кайгы», Р. Зәйдулла белән Р. Сабирның «Хөкемдар», Ф. Галиевнең «Болганчык еллар», И. Мөхәммәтгалиевнең «Мөһаҗирләр» һ. б. шундыйлардан. Заман концепциясе ягыннан карасак, Ю. Сафиуллин, Ф. Галиев, И. Мөхәммәтгалиевләрнең М. Галәүнең «Болганчык еллар» һәм «Мөһаҗирләр» әсәрләренә нигезләнеп иҗат ителгән сәхнә әсәрләре XIX гасыр ахырында илдәге үзгә-

решләрне тарихи бәйләнешләрдә чагылдыра. Алар геройлар аша үткән чорның социаль күренешләрен, халык язмышын, аның яшәешен, уй-фикерләрен, катлаулы тормышларын сурәтләп, чынбарлыкта хөкем сөргән социаль, әхлакый тәртипләр турында сүз алып баралар. Иң мөһиме – үткәннең олы вакыйгаларын бүгенге көнгә аваздаш итәләр. Сыйнфыйлык кискен куелган заманда язылган М. Галәү романнарында кешеләрне сыйнфый яктан бүлү бар. Ю. Сафиуллин, Ф. Галиев, И. Мөхәммәтгалиевләр авыл байларына хас кайбер тискәре сыйфатларның бүгенге байларыбызда чәчәк атуын, үз мәнфәгатьләрен генә кайгыртып яшәүне Вафа образы аша күрсәтәләр. Ул «ничек итсәң ит, әмма тук һәм рәхәт яшә» дигән принцип белән көн күрүче кеше буларак сурәтләнә. Миңлебайлар йортында Сафаны өйләндерү турында сүз башлангач та, Вафа белән Фатыйма авылны үз кулында тота торган бай кызы кирәклегенә басым ясыйлар. Гомумән, пьесадагы кискен социаль конфликтлар идеяләр көрәше, характерлар бәрелеше ярдәмендә бирелә. Вафага хас икейөзлелек, әхлаксызлык, ваемсызлык сыйфатлары ачлык еллары вакыйгаларында тагын да ныграк ачыла. Боларны ачуда драматурглар уен алымын отышлы кулланалар. Эшкә ялланып, приказчиклар артыннан шымчылык кылып, Габдулла байның кызу канлылыгы нәтиҗәсендә аерган хәләл җефетенә өйләнеп, аларны алдап, күп кенә акча алуы (шәригать кануннары буенча Габдуллага янәдән тормыш иптәше белән никахлашу өчен хатыны башка берәүгә кияүгә чыгарга, соңыннан гына ире белән никахлаша ала), байлык туплавы шуның бер мисалы. Билгеле булганча, әдәбиятта уен кешенең үзенчәлекле үз-үзен тотышы, дөньяга караш формасы кебек тә бирелә ала. Сафа исә гаделлек, игелеклелек бар нәрсәдән дә өстен дип саный. Гомумән, геройларга хас булган сыйфатлар, яшәү фәлсәфәсе 1891 елгы коточкыч ачлык вакыйгаларында тулырак ачыла. Ачлыктан соң, крестьяннарның күп өлеше хәерче хәлдә кала. Бердәнбер юл – читкә эшкә чыгып китү. «Ирдәүкә» һәм «Мөһаҗирләр», «Болганчык еллар» драмаларында нәкъ менә шулар дөрес чагыла. Анда заман һәм характерлар тарихи җирлектә бирелә. Әсәрләрдә Саҗидә ирләр белән рәттән торып эшләрлек батыр, үткен, чая, бай күңелле драматик шәхес буларак тасвирлана. Гадәттә, драмада сурәтләнгән геройлар хаклык, дөреслек өчен көрәшеп, катлаулы драматик хәлләргә очрап, шул юлда һәлак булырга мөмкиннәр (1, 100). Пьесаларда тасвирланган Саҗидә образы шуның ачык мисалы. Әлеге геройга мөнәсәбәтле драматурглар кешенең гуманизм, мәхәббәт һәм үз хокуклары өчен көрәшүенә, бәхеткә омтылуына дан җырлыйлар. Бу принцип уңай герой концепциясендә мөһим урын алып тора. Саҗидә

үз чорының көрәшчесе, кеше хокукларын яклаучы, шул ягы белән ул безнең чорга аваздаш. Димәк, герой концепциясе заманнар бәйләнеше идеясеннән аерылгысыз. Мәгълүм булганча, 1897 елда Россия территориясендә халык санын исәпкә алу була. Халык арасында татарларны чукындыралар дигән сүзләр тарала. Әлеге курку, шикләнү урынлы. Чөнки патша хөкүмәте гасырлар буе нәкь менә шундый сәясәт белән эш итте. Ф. Галиев мәсәлән, Ю. Сафиуллиннан аермалы буларак, үз әсәренә Ефим поп образын кертеп җибәрә. Шуларга бәйле рәвештә, ул патша хөкүмәтенең рус булмаган халыкларга карата алып барган сәясәтен ача.

«Ефим. Теләсәгез, мин сезне чын белем ала торган җиргә урнаштыра алам. Сезгә укыган чагында ук җитәрлек акча бирәчәкләр... тик бер шарт белән...

Барый. Нинди шарт?

Ефим. Сезгә исемегезне, фамилиягезне һәм динегезне алмаштырырга кирәк» (2, 290). Татар халкының белем алу проблемалары да, бу мәсьәләләргә татар халкының мөнәсәбәте дә күренә. Биредә дә әдипнең заман концепциясе заманнар бәйләнеше идеясеннән аерылмый. Пьесада да, романда да, ризасызлык белдергән халыкны бастыру өчен, татар авылларына җәза отрядлары – «обжор командасы» җибәрелә, гади халыкның хөкүмәт тарафыннан төрлечә эзәрлекләнүе сурәтләнә. Болар XX гасыр ахырында булып узган вакыйгаларны, безнең бүгенге көнебезне хәтерләтә. Әсәрләрдә яңа салымнарга түләү өчен каян акча табарга? дигән сорауларга җавап эзләгән халык Төркиягә күчеп китәргә кирәк дигән карарга килә. Төркия җиренә күченеп китү турында сүзләр тарала башлагач, Саҗидә дә икеләнмичә, шул фикерне яклаучылар ягына кушыла. Авыл байлары, куштаннары, ил өстенә килгән бу бәлаказалардан исән-имин чыгып тагын да ныграк байыйлар. Гади халыкның уңдырышлы җирләрен юк кына бәягә сатып алалар. Әлеге күренеш И. Мөхәммәтгалиевнең «Мөһаҗирләр»ендә читкә китүчеләргә зур гына бәягә паспорт булдыручы Ибраһим образында тулырак бирелә. Матур, бәхетле тормыш турында хыялланган халыкны Төркиядә дә фаҗигале авыр тормыш көтә. Кыю, тәвәккәл Саҗидә бу авыр чорда да югалып калмый. Гомеренең соңгы көненә кадәр бәхете өчен көрәшә. Романда да, пьесада да Саҗидәнең характеры тагын бер яктан сынала. Балалары булмавын аңлагач, ул Сафаны икенче мәртәбә өйләнергә күндерә. Милләтнең иң асыл сыйфатларын үзләренә туплаган бу драматик шәхес образы милләт анасы дәрәҗәсенә күтәрелгән символик мәгънәгә ия. Кыз халыкның ирекәә омтылу, азатлык идеалын гәүдәләндерә. Шәхес иреге халык азатлыгыннан аерылгысыз. Шуңа Саҗидә һәм башка ге-

ройлар язмышы халык яшәеше белән нык бәйле. Сажидә драматик образында халыкның героик рухын гәүдәләндерә. Кыз образын ирекле тормышка, азатлыкка омтылыш идеясе белән бәйләп, әдипләр аны яшәү чыганагының башлангычы итеп тә сурәтлиләр. М. Галәү романнарының төп идеясе коллыкка, һәртөрле изүләргә каршы туктаусыз көрәшен раслаудан гыйбарәт. Романнар нигезендә туган драмалары да шушы идеяне ачуга буйсындырыла. Ул татар халкы тарихын бербөтен итеп тоярга мөмкинлек бирә. Үткәнне хәзерге һәм киләчәк заманнарга бәйли. Бүгенге тамашачы белән театр арасына яңа диалог күпере сала. Бу әсәр тарихи, фәлсәфи, социаль эчтәлеге белән күп проблемаларны һәм заманнарны иңләргә мөмкинлек бирә, төрле чорларның үзенчәлекле, уртак якларын күрсәтә. Шул рәвештә, драмалардагы аянычлы язмышлы шәхесләр образлары аша халык драмасы чагылыш таба. Батырлыкка, азатлыкка, дуслыкка, саф мәхәббәткә омтылу рухы әсәрләрне берләштерә. Заман концепциясе чын демократик казанышлардан ерак булган җәмгыятьнең, милли мәсьәләләрне чишә алмый газаплanuчы илнең бер чорын ачыклауга кайтып кала. Авторлар заманны бердәмлек бетү, ил таркалу заманы дип күрәләр.

ӘДӘБИЯТ

1. Фролов В. Судьба жанров драматургии / В. Фролов. – М.: Советский писатель, 1979, – 412 с.

2. Яңа татар пьесасы. – Казан: Идел-Пресс. – 2005. – 431 б.

***А. Р. Мубаракшина***
***Казан***

## ТУКАЙНЫҢ КҮҢЕЛ ЙОЛДЫЗЫ

«Йолдыз» газетасының 1909 елгы 472 нче (29 ноябрь) санында Габдулла Тукай «Күңел йолдызы» исемле шигырен бастыра. Текстның ахырында авторның кыска гына искәрмәсе дә бар. «Күптән инде Габдулла Җәүдәтнең шул ике сәтыры күңелемә ошагач, мин дә бер нәрсә язган идем. «Йолдыз»га мөнәсәбәте булганга, шунда дәреҗ иттем» (1, 320). Тукай шигырьгә эпиграф сыйфатында әлеге төрек шагыйреннән икеюллык ала. Н. Н. Сабирҗанов һәм Г. Ф. Мамина «XX йөз башы төрки әдәбиятлары мохитендә Г. Тукай иҗаты» мәкаләсендә язганча, «...шагыйрь, авторларын күрсәтмичә генә, татар матбугатында “төрекчәдән” дип шактый күп шигырьләр бастыра... Әмма Тукай ифрат намуслы,

иҗатына әһәмиятле этәргеч бирүчеләрнең исемнәрен укучыларына да белдерә. Мисалга, “Күңел йолдызы” шигырен ул 1909 елда Габдулла Җәүдәтнең “Бер кыйтга” шигыреннән илһамланып яза, төрек каләмдәшенең ике юллыгын үз әсәренең эпиграфы итеп бастыра» (1, 320). Габдулла Җәүдәт (1869–1932) – сәясәтче («Яшь төрекләр»дән), журналист, публицист, ирек һәм дөреслек җырчысы – алдынгы карашлы шагыйрь. Татар шагыйре аның иҗатына да очраклы гына мөрәҗәгать итми. Җентекләп тикшереп караганда, бу ике шагыйрь иҗатында лирик темаларда, образларда шактый гына охшашлык сизелә. Беренче чиратта алар үз милләтләренең, илләренең социаль-сәяси хәлен күңелләренә бик якын алалар.

Тәнәфферләр, тәхаттырлар, тәрәххемләрлә дөньядан –
Гөзарым, захмедар васле бер һиҗрә мөкәүкәбдер.

Ягъни:

Нәфрәтләнү, хәтерләүләр, ачынулар белән дөньядан үтәрмен,
Шулай да ялы күңел бер сөю белән нурланган, (1, 61)

дигән юлларда шагыйрьнең күңел сызлануларын, ачынуын күрәбез. Тормышның гаделсезлеген, йөрәктә калган ачы хатирәләр – бар да милләт язмышының кичерешләре. Ләкин күңелдә якты киләчәккә өмет яши, ди кебек Габдулла Җәүдәт. Ә Тукай «Күңел йолдызы» шигырендә шул төрек шагыйренең ачынуларын аваздаш итеп, милли җирлеккә сәбәбен ачык күрсәтеп күчерә. «Йолдыз» газетасында бастыруы да юкка түгел. «Йолдыз» – татарның ирекле фикер йөртә ала торган газетасы, Тукайның социаль-сәяси характердагы бик күп шигырьләре анда басыла. Мөхәррире Галиәсгар Камал шагыйрьдән гел нәрсә дә булса язып бирүен сорап тора. Габдулла Тукай да, Габдулла Җәүдәт кебек үк, публицист, журналист, демократ, сәясәт эшлеклесе.

Йолдыз – әлеге шигырьдә метафора булып, берничә мәгънәдә килә. Милли контекстта караганда, символик укылышта, йолдыз – өмет, яктылык, хыял булса (5, 46); иҗтимагый-социаль җирлектә «йолдыз»ның газета исеме булуы, аның дөреслекне язуы, либераль рухта эшләве, халыкны агартуда ярдәм итүе һәм Тукай иҗатын бөтен яктан яктыртуы белән «бу төнем йолдызлы, йолдызлы» булуы белән билгеле. Н. Ш. Хисамов билгеләгәнчә, йолдыз символы Тукай иҗатының буеннан-буена сузыла. Мисал өчен, «“Йолдыз”дан да курка» шигырендә авыл агасының либераль-демократик, нигездә җәмгыять тәртипләренә лояль караучы «Йолдыз» газетасын өендә күрүдән коты алынуын яза (4, 19). Шулай

ук шагыйрьнең ***«Бу көндә бер сарай ачды әһали...»*** (1905) шигырендә «Йолдыз» сараен мактап язуы билгеле.

Бу көндә бер сарай ачды әһали –
Гүзәлдер, мисле әндәр, кадре гали.
Гаҗибдер чәй вә аш әсбабе хали;
Мөрәттәб, монтазамдыр кәл-лөали.

*«Йолдыз» («Йолдыз сарае»)* – Госманлы дәүләтенең солтаны Сәлим III (падишаһлык еллары – 1789–1807) тарафыннан әнисе Миһришаһ Солтан өчен төзеттерелгән. Солтан Габделхәмид II (1876–1909) заманында Госманлы дәүләтенең төп сарае булган.

Без анализлый торган шигырьгә әйләнеп кайтсак, Тукай Габдулла Җәүдәтнең хис-кичерешләрен үз шигыренә күчереп, әсәрнең лирик герое чын милли патриот, халык киләчәге өчен кайгыручы герой булып төгәлләшә. *«Куркытмыйдыр безне»* – Тукайны беркем, бернәрсә беркайчан куркытмады һәм чын шагыйрь, аныңча, курку белмәс дөреслек җырчысы булырга тиеш. *«Безне»* дип язганда ул әнә үзе кебек чын шагыйрьләр, язучыларны Габдулла Җәүдәт, «Йолдыз» газетасының мөхәррире Галиәсгар Камалны күздә тотуыдыр. (Галиәсгар Камалны «Йолдыз» газетасының мөхәррире булуы белән шушы шигырьгә мөнәсәбәте бар дип карарга кирәк.) *«Елар җирдә көләм мин, һич чытып тормыйм аңа йөзне»* – дигән юлларда Тукай үз иҗатына үзе гомуми бәя бирә кебек яңгырый. Ул XX гасыр башында барган иҗтмагый вазгыятьнең сатира аркылы авыр хәлдә булуын сурәтләп бирә алучы иң көчле шагыйрь. Тукай сатирасы – үзе бер тирән фән. Сатира җәмгыятьтәге бөтен кимчелекләрне үз эченә ала. Сызлануларын, Габдулла Җәүдәт сүзләре белән *«нәфрәтләнү, хәтерләүләр, ачынуларын»* сурәтләгәндә сатираның иң югары ноктасы – сарказмга кадәр мөрәҗәгать итеп, елар урында көлә ала Тукай. *«Минем гомрем караңгы төн»* – төн, символик укылышта сынаулар, билгесезлек, шомлылык (5, 110). Әлеге юлларда сүз шагыйрьнең шәхси тормышы турында да, милләтнең йокыдан уяна алмыйча ятуы турында да бара. *«Кояшым һәм аем тугмас»* – кояш – яшәү чыганагы, яшәешкә башлангыч бирүче, бөек Ана образы, ай – караңгыда юл күрсәтүче, ягъни кыен чакта ярдәм итүче терәк, яңарыш, үлемсезлек, көч символы (5, 92). Әлеге шигырьдә лирик геройның тормышында матур киләчәк вәгъдә ителмәсә дә, ул үзенең язмышы белән зарланмавы, канәгать булуы кебек укыла: *«шуңа да шөкер итәм мин: бу төнем йолдызлы»*. *«Төн»* дип ул үзенең авырлыклардан һәм сынаулардан торган шәхси тормышын атаса, *«йолдызлы»* дип – халык язмышы мәйданына кадәр

киңәеп, аның киләчәге якты булуга өмет бар ди, чөнки төн йолдызлы (өметле). *«Мәлгунь көч, кара көчләр»* дә аны дөрес юлдан яздыра алмый. Халыкның уянуын, татарның таң вакытын күпме көтте, күпме эшләр башкарды... һәм өметен өзмәде. Цензура дип тә, сәясәт дип тә тормады – кара йөзләрнең маңгаена бәреп язды – үз шигърияте, иҗаты белән юлсызларны юллы итте, җиһанда үзе дә йолдыз булып гүзәл эзен калдырды: *«Җиһанда калдырып китсәм икән, йә раб, гүзәл эзне!»*

*«Барча кодсиятебез дә айлы, йолдызлы!»* – максатының якты төгәл юлы булуы, өметле (айлы, йолдызлы) икәнен белгәнгә күрә, лирик геройның *«күңле мөкәүкәптер өмид, хәсрәт, тәәсирлә»*. Шулай итеп шигырьнең ахырына кадәр «йолдыз» символы берничә мәгънә белән тулыландырыла. Ә ай белән йолдыз образларының янәшә килүләре, Н. М. Йосыпова билгеләп үткәнчә, илаһи матурлыкны ачуга юнәлдерелә (3, 111).

Дүртенче строфадагы «йолдыз» халыкның йокыдан уянуына өмет кебек яңгыраса, алтынчы юлда иҗтимагый аренада халыкның матур киләчәген күрергә теләп чыгарылып килгән «Йолдыз» газетасы кебек аңланылу мөмкинлегенә ия. *«Йолдызым якты, һаман нурлы»* дигән юлларда инде өметкә, газета исеменә өстәп, тагын бер мәгънә – Тукайның иҗатына бәя булып яңгырый. Тукай 1909 елларда төшенкелеккә бирелмичә, ялкынланып, *«нурланып, яктырып»* иҗат итә. Шигърияте белән битарафларны уята, юлсызларны юллы итә: *«гаҗәпме, юлга салса, ичмасам, бер данә юлсызны»*. Ахыргы строфадагы «күңел йолдызы» яңадан өметкә, якты киләчәккә әйләнеп кайта. *«Күңел йолдызы»* көчле позициягә, ягъни шигырьнең исеменә үк чыгарыла.

Габдулла Тукай белән Габдулла Җәүдәтнең хис-кичерешләре уртак, икесе дә милләт язмышы өчен янучылар, милләтне «бер сөю белән нурланган» күңел белән сөяләр. Төрек шагыйренең «Бер кыйтга»сы белән татар шагыйренең ахыргы строфалары мәгънә ягыннан аваздаш яңгырый. Шигырь *аа, бв, гв, дв, ев, жв* рифмалы, уналты иҗекле гаруз формасында язылган.

Халыкның шул ачы язмышы, караңгылык, наданлык баткаклыгында, изелүләр астында яшәвеннән күңелдә туган *«хәсрәт, тәәсирләр берлә»* шагыйрьне дөнья әдәбиятында якты йолдыз итеп балкытты. Тукай иҗаты кайсы гына халык әдәбиятында, мәдәниятендә булмасын, һәрвакыт *«якты, һаман нурлы»* булып кала бирер.

## ӘДӘБИЯТ

1. Тукай Г. Әсәрләр: 6 томда // Шигъри әсәрләр (1909–1913), 2 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2011. – 400б.

2. Сабирҗанов Н. Н., Мамина Г. Ф. XX йөз башы төрки әдәбиятлары мохитендә Г. Тукай иҗаты // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Г. Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011. – Б. 176.
3. Йосыпова Н. М. Тукай лирикасында суфичылык символларының кулланылышы һәм трансформациясе // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Г. Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011. – Б. 176.
4. Хисамов Н. Ш. Шигъриятtә Тукай феномены // Габдулла Тукай мирасы һәм милли-мәдәни багланышлар. Г. Тукайның тууына 125 ел тулуга багышланган Халыкара фәнни-гамәли конференция материаллары. – Казан, 2011. – Б. 176.
5. Трессидер Дж. Словарь символов / Пер. с англ. С. Палько. – М.: ФАИР-ПРЕСС. 1999. – С. 448. (словарь символов тресидера.doc, 201 с.)

*Л. Т. Муртазина*
*Казань*

# ОТРАЖЕНИЕ КУЛЬТУРНЫХ ЦЕННОСТЕЙ НАРОДА И ТРАДИЦИЙ ОБЩЕСТВА В ТАТАРСКОЙ СОВЕТСКОЙ ПРОЗЕ

Тема мобилизующей национальной идеи на протяжении многих лет продолжает оставаться центральной в российском и татарском обществе, как в политических дискуссиях, так и в работах писателей. Отношение человека к нации и Родине – одна из глубочайших экзистенциальных проблем, которая приобретает особую актуальность в переходные исторические периоды. Естественно, что стремительные изменения социально-экономических условий в России, экспансия западной массовой культуры подвергают кардинальному изменению устоявшиеся представления о национальной идее. Прежние ценности и ориентиры целого ряда социальных групп теряют свое значение, их место занимают новые, и, нередко, встает вопрос: останется ли Россия страной с уникальной национальной культурой или же постепенно утеряет свою самобытность. Вместе с этим, остро встает вопрос о сохранении национальных традиций как в языке, так в культуре и в татарском обществе. Здесь уместно будет вспомнить слова В. В. Путина, который он высказал в статье «Россия – не этническое государство и не американский «плавильный котел»: «Для России – с ее многообразием языков, традиций, этносов и культур – национальный вопрос, без всякого преувеличения, носит фундаментальный характер. Любой ответственный политик, общественный

деятель должен отдавать себе отчет в том, что одним из главных условий самого существования нашей страны является гражданское и межнациональное согласие» (1).

Отметим, что Россия в своих поисках созидательной национальной идеи не одинока. Одной из особенностей современного мира является активизация различных по своему содержанию этнических процессов. «Этнический ренессанс» – это ответ на вызовы глобализации. Он показывает стремление различных народов сохранить свою культуру, язык, религию и традиции. С одной стороны, отдельные индивиды и народы стремятся к самоидентификации, пытаясь найти суть своего духовного бытия в истории предшествующих поколений, религии, языке, культурных ценностях, традициях политических и социальных институтов. С другой стороны, одновременно с процессом дифференциации наблюдается унификация самых разных культурных традиций, Столкновение указанных глобальных тенденций мирового развития порождает кризисные ситуации как в политической, так и культурной сфере» (2, 37).

Очерченный выше круг проблем цивилизационного развития России имманентно присущ и татарской философской и культурологической мысли. В начале XX в. татарская интеллигенция сфокусировала свое внимание на решении историософских проблем. Поиск путей решения суверенности татарского народа, раскрытие души отдельно взятого человека Г. Исхаки, Г. Тукаем, вехи рефлексии татарской национальной идеи в XX веке.

«Исследование теоретических основ осмысления национальной идеи в российской философской, культурологической и исторической мысли создают дополнительную возможность описать такие актуальные в научном и социальном плане вопросы, как закономерности функционирования» (3, 15) одной из сфер общественного бытия – национальной, определить составляющие элементы и этапы процесса диалога культур и феноменов инокультурных заимствований в татарской истории – т. е. тот круг философских и культурологических проблем, которые являлись центральными в творчестве А. Гилязова, Н. Фаттаха, А. Еники и др., классиков татарской литературной мысли.

Нам интересен тот момент, в творчестве этих писателей были ли созданы оригинальные концепции эволюции татарской культуры, как это показал в нач. XX в. Г. Исхаки. Следует подчеркнуть, что, например, А. Гилязов, как и Г. Исхаки рассматривал развитие татарской культуры в тесной связи с эволюцией национального самосознания народа. Данный методологический подход нашел свое отражение в целом ряде фун-

даментальных научных трудов современных татарских историков, среди которых можно выделить Р. Хакима, Г. Давлетшина и др. Выделить такую концептуальную идею в литературных произведениях предстоит литераторам.

Любой национальный вопрос, на наш взгляд, опирается на ключевое понятие «традиции» и конкретизируется при помощи обращения к проблеме историзма, так как «чувство истории» лежит в основе понимания традиции как живого целого, оно «предполагает ощущение прошлого не только как прошедшего, но и как настоящего». Как нам видится, чувство причастности к истории своего народа побудило творить татарских писателей, ощущая в себе не только собственное поколение, но и всю татарскую литературу, как нечто, существующее одновременно. Историческое чутье писателя является своеобразным «механизмом» приобщения индивидуального творчества к национальной культуре.

Так, понятия «язык», «народ» приобретают в художественных построениях А. Гилязова, А. Еники, Н. Фаттаха культурологический характер. Язык является для А. Еники самостоятельной сферой, наделен онтологическим смыслом, он вне полагается истории и культуре. «Столь высоко организованный язык не только дверь в историю, но и сама история» (4, 21). Язык и любое слово в языке являются хранителями не только культуры, но исторической самостоятельности, духа народа. «Единство культуры – это единство культуры народа, который живет на одной территории. Говорить на одном языке – значит мыслить и чувствовать и иметь эмоции, довольно-таки отличные от эмоций народа, который говорит на другом языке» (5, 87).

Замечая неизбежность и необходимость существующей громады социальной постройки, татарские писатели XX в. осознавали и меру ответственности личности за сохранение, может быть, самих первооснов бытия: «…гуманизировать двадцатое столетие, согреть его теологическим теплом, – вот задача потерпевших крушение представителей татарского народа, волею судеб, заброшенного на новый исторический и социальный «материк».

В их произведениях каждый главный герой становится личностью, т. е. объектом и субъектом культуры. В то же время авторы не забывают о главных составляющих культуры личности – через них раскрывается сущность национального самосознания. Здесь можно подчеркнуть, что культура татарского народа становится смысловым миром для каждого мыслящего человека, человека не из толпы. Это приобретает статус экологической культуры в произведениях, ориентированных на

сохранение культурного составляющего татарского народа и рассматривается как неотъемлемая часть общечеловеческой культуры, включающая моральные ценности, нормы поведения, способы взаимодействия людей в сфере сохранения культуры, языка, народа, систему формирующих их социальных отношений, проявляющаяся в национально ориентированном поведении людей, осознании общей ответственности за будущее своей нации.

ЛИТЕРАТУРА

1. Путин В. В. Россия – не этническое государство и не американский «плавильный котел» // www.business-gazeta.ru/article / 52925 / (от 23.01.2012).

2. Шаховский В. И. Языковая личность в эмоциональной коммуникативной ситуации // Филологические науки, 1998, №2. – С. 32–39.

3. Чупина Г. А. Философия осознания: проблема смысла // Проблема сознания в отечественной и зарубежной философии ХХ века. – Иваново, 1994. – С. 12–18.

4. Толстой Н. И. Язык и культура // Русский язык и современность. Проблемы и перспективы развития русистики. – М., 1991. – С. 82–90.

***Л. Ф. Наруллина***
***Казан***

## РАЗИЛ ВӘЛИЕВНЕҢ «ИСКЕ СӘГАТЬ ДӨРЕС ЙӨРИ» ПОВЕСТЕНДА ЯШЬЛӘР ТЕМАСЫ

Яшьләр темасы татар әдипләре еш мөрәҗәгать иткән темаларның берсе булып тора. Әдәбият галиме Фәрваз Миңнуллин фикеренчә, әдәбият фәнендә «яшьләр повесте» дигән яңа термин барлыкка килде. (1, 40). Ул «яшьләр повесте»нә түбәндәге авторларның әсәрләрен кертә: А. Ганиев «Сүзсез җыр», Ф. Яруллин «Җилкәнне җилләр еккач», Гөлшәһидә «Минем кала алуым», Ф. Мансуров «Якты тауда бүз тургайлар», С. Хафизов «Яшьтәшләр», Ф. Шәфигуллин «Өй салуның ние бар», М. Галиев «Ак абагалар», «Ул чакта», Ф. Гыйльметдинов «Урсай тау итәгендә», «Елганың борылган төшендә», Г. Рәхим «Көннәр язга авышкач», «Саргаймагыз, каштаннар».

Әлеге повестьларның үзәгенә тормышта үз урынын эзләүче яшь кеше образы куела. Төп игътибар аның авыр тормыш шартлары белән очрашуына бирелә. Яшьләрнең киртәләрне уңышлы узып, олы тормышка аяк басулары Разил Вәлиевнең «Эт кояшы» һәм «Иске сәгать дөрес йөри» әсәрләрендә киң яктыртылган.

Язмада авторның «Иске сәгать дөрес йөри» әсәренә тукталып үтәсем килә. Бу әсәрен автор яшьли яза. Шуңа күрә дә повестьны уку барышында без Разил Вәлиевнең яшьләр психологиясен яхшы белүенә тап булабыз.

Әсәрнең темасы – төп герой Искәндәрнең бер көнлек тормышы, яңа елга керер алдыннан бер көн эчендә кылган эш-гамәлләре, уй-кичерешләре, тормышта үз урынын эзләү. Повестьтә шулай ук мөһим проблемалар күтәрелгән: гаилә иҗатка комачаулыймы? Кеше гаиләсез бәхетле була аламы? Яшьләр үз идеалларына тугры калырга тиешме?

Әсәрнең төп герое Искәндәр, беренче карашка, бәхетле тормыш кичерә. Аның гаиләсе, фатиры, эше, яшь вакыттан ук аралашкан дусишләре бар. Әмма тынгысыз күңеле моңа гына риза түгел, ул һаман нидер эзли, җанына тынычлык таба алмый. Моның сәбәбе – Искәндәрнең иҗат кешесе булуында. Ресторанда музыкант булу аңа табыш китерсә дә, рухи канәгатьләнү бирми.

Искәндәр гомере буе музыкант булу максаты белән янып яши, ә иң зур хыялы – музыка язу. Ул кечкенәдән композитор булу турында хыяллана. Чын иҗат кешесе буларак, ул төннәр буе нота кәгазьләре белән утыра, хатыны Сөмбелне уятып, аңа язган көен пианинода уйнап күрсәтә. Ләкин бу эш-гамәлләрен сөеклесе аңламый, бары тик көлә генә. Искәндәрнең иҗат итү теләге якыннары арасында яклау тапмый. Монда без геройның эчке дөньясы белән тормыш шартлары арасында барган каршылыгына тап булабыз.

Пианино янына утыргач, Искәндәр икенче бер дөньяга кереп китә. Музыка – аның бердәнбер юанычы. Әсәр юлларына күз салыйк: «Искәндәр пианино янына килеп утырды. Аның куллары кагылуга, пианинодан сагышлы музыка агылды. Искәндәр, бар дөньясын онытып, алга-артка чайкала-чайкала уйнады да уйнады» (2, 372). Уйнаган көе аның язмышы шикелле сагышлы иде.

Искәндәр – тормыш шартларына яраклаша алмаган, иң беренче чиратта, үз-үзе, шулай ук дус-ишләре, хатыны Сөмбел белән каршылыкка кергән герой. Ул бу тормышта үз урынын таба алмый. Искәндәрнең күңел дөньясы беркемне кызыксындырмый.

Искәндәрнең мондый хәлдә калуында кем гаепле соң? Әлбәттә, бары тик үзе генә, гәрчә герой моны аңламаса да. Ул янәшәдәге кешеләргә артык игътибар бирми, аларның киңәшләрен ишетергә дә теләми. Ресторанда үзе белән эшләүче Альфредның Искәндәргә әйткән сүзләренә колак салыйк: «Кит син моннан, Искәндәр, яхшы чакта кит... син талантлы бит. Менә дигән көйләр язасың» (2, 330–331).

Эшеннән туеп зарланган Искәндәр аңа: «Китеп кая барасың?» – дип кенә җавап бирә. Искәндәр – үзенә эш урынын гына түгел (берничә мәктәп алыштыруын искә төшерик), ә тормышта үз урынын таба алмаган кеше. Куркаклыгы һәм кыю адым ясарга батырчылык итә алмавы аркасында, ул япа-ялгыз кала. Геройның төп кимчелеге – гаепне үзеннән түгел, ә әйләнә-тирәдәгеләрдән эзләү. Үзенең күңел газапларын ул тормыш ваклыкларыннан күрә. Аның өчен дус-ишләре дә, хатыны Сөмбел дә – иҗат турында берни аңламаучы гади җир кешеләре. Ул аларга хәтта кимсетеп тә карый: «Менә сезнең аркада, хатын-кыз аркасында, җирнең үги улы булып беттек тә инде... Җәнлекне ник ата кеше – хатын-кызга затлы тун, энҗе-мәрҗән кирәккә. Урманны ник кисә кеше – хатын-кызлар берберсен уздырып мебель даулаганга. Сугышлар нигә чыга – хатын-кыз аркасында... Безне менә шушылай начар итеп кем тәрбияли – хатын-кыз тәрбияли...» (2, 351).

Нәтиҗәдә, герой гаиләсенә күңел җылысы бирергә сәләтсез кешегә әйләнә. Шул сәбәпле ул буш, салкын фатирда ялгызы кала.

Әсәрдәге автор әйтергә теләгән төп фикер, ягъни әсәрнең идеясе – кеше якыннарыннан башка бәхетле була алмый, гаилә берничек тә иҗатка комачауламый, ә бәлки, киресенчә, яраткан кешеләре янәшәдә булганда гына кеше матур сәнгать әсәрләре тудыра ала.

Әсәрнең образлар системасын оештыруда яшьләрнең роле зур. Искәндәр, нигездә, курсташлары белән аралаша. Бергә укысалар да, тормышка карашлары һәм куйган максатлары белән студентлар бер-береннән бик нык аерылалар.

Студент елларыннан ук яшьләр үзалдына билгеле бер максатлар куялар. Аларның бу тормышка һәрберсенең үз фикере, үз карашы бар. Еллар үткәч, без бу максатларның тормышка ашканмы-юкмы икәнен күрә алабыз. Мисал өчен Фидан образын алыйк. Фидан студент елларында бөтенесеннән аерылып тора. Аз сөйләшә, үз эшен төгәл башкара. Ә музыкант булуга ул бер хобби – мавыгу дип кенә карый. Яшьтәшләренә сөйләгән сүзләренә игътибар итик:

«Музыка – бәйрәм ул, ә бәйрәм көн саен килми. Көн саен аның кирәге дә юк! Кеше бәйрәм итәргә килми, яшәргә килә!» (2, 362).

10 ел үткәч тә аның фикере үзгәрмәгән булып чыга. Фидан кафеда склад мөдире булып эшли. Эшеннән һәм тормышыннан бик канәгать булып яши. Искәндәргә карата да үз фикере бар – Искәндәр күктә, болытлар арасында йөзә. Аларның сөйләшүенә колак салыйк: «Институтта укыган чакта ук йолдыз чире белән чирли идең. Һаман терелеп житмәгәнсең икән. Әллә мине... музыканы үзеңә караганда кимрәк ярата дип

уйлыйсыңмы? Һо-о, юк! Арып-талып эштән кайткач, пианино янына килеп утыруга, бу дөньяның бар әрҗәләре, капчыклары эреп әллә кая юкка чыга. ...шул чакта гына үземне бәхетле хис итәм мин» (2, 354). Ләкин Искәндәрдән аермалы буларак, Фидан зур музыкаль талантка ия түгел. Шуңа күрә дә ул башка профессияне сайлый һәм бу өлкәдә уңышлы гына эшли.

Яшьләр арасында тагын эпизодик Рүдәл образы да бар. Ул һәркемнән көлергә яратучы, гел гаеп эзләүче көнчел бер кеше. Институтта укыганда егетләр аннан ераграк йөриләр, ә кызлар вак-төяк йомышка йөртәләр. Автор Рүдәл образын ачуда чагыштыру алымын уңышлы кулланган: «...бит алмалары йодрыктай бүртеп чыккан, борын яфраклары тырпайган, корсагы, түм-түгәрәк булып, зәңгәрсу пиджагын тартып тора. Койган да куйган урам күгәрчене инде... Әллә инде төс-кыяфәте, әллә инде очраган бер кешенең башына бәләкәй генә... пәп итеп йөргәне өченме... аны күгәрчен дип атап йөри башладылар. Сөйләшкәндә дә гөр-гөр килеп тора..., ирененнән беркайчан да елмаю китмәс – суйган да каплаган күгәрчен инде» (2, 393). Ә яшьләрнең саубуллашу мәҗлесендә Рүдәлне автор карчыга кошы белән чагыштыра. «Рүдәл җитез биюгә кушыла алмый, шуңа күрә вальс башланганны гына көтә дә кыз янына карчыга кебек ташлана» (2, 393).

Тагын бер эпизодик образ – Кадыйр образы – төп герой Искәндәрнең балачагын тулырак күз алдына китерер өчен кулланылган. Кадыйр – тракторчы, аңа балачагын исенә төшерүче кеше. Әсәрдә күп кулланылган чигенешләрнең берсендә без Искәндәрнең мәктәп елларына әйләнеп кайтабыз. Менә Искәндәр беренче тапкыр гармунда уйный, беренче тапкыр мәктәпкә бара. Ул вакытта мәктәп директоры аңа: «Музыкант чыгачак синнән. Юлыңнан тайпылмыйча барсаң, менә дигән композитор чыгачак», – дигән була. Дөрестән дә, Искәндәр гомере буе юлыннан тайпылмыйча барырга тырыша, әмма бик күп тормыш каршылыкларына очрый. Автор әсәрдә чагыштыру алымын кулланып, Искәндәрне бер якка, ә «өннәренә кереп качкан йомраннар»ны икенче якка аерып куя. Сабакташлары Хәмит, Интизар, Рүдәл, Фиданны автор җыйган ризыкларын өннәрендә эшкәртеп ятучы йомраннарга охшата. Искәндәр алар кебек яшәргә һич кенә дә теләми. Аның бу теләген тормыш иптәше Сөмбел дә аңламый.

Сөмбел – Искәндәр белән бергә укыган яшь, чибәр кыз. Имтиханнарны тапшырып бетерү хөрмәтенә үткәрелгән мәҗлестә һәр егет Сөмбелнең игътибарын үзенә җәлеп итәргә тели. Сөмбелне тасвирлауда автор эпитетлар (дулкын чәчле, ташкын чәчле, кояшлы иренле,

иңбашларына агып төшкән чәч дулкынында коенып утыручы кыз) һәм метафоралар («Аның чәчләре музыка агышына кушылып тирбәлә, дулкынланып йөзенә төшә, ул үзенең чәчләре арасына кереп адаша») кулланa (2, 342).

Сөмбел образын ачуда автор төп геройның әнисенә мөрәҗәгать итү алымын да кулланган. Әнисеннән хат килеп төшкәч, Искәндәр аның белән «сөйләшә». Сөмбел – тормышка аек акыл белән карауччы реалист. Аның өчен югары белем алу да, эшле, фатирлы булу да – гадәти нәрсәләр. Ул – шәһәр кызы. Ә Искәндәргә болар барысы да авырлык белән бирелә. «Институтка керү, мең бәла белән тулай торактан урын алу... туй ясау, диплом яклау, эшкә урнашу, фатир алу... Менә шуларны эшләү өчен генә дә күпме көч киткән, күпме җан кыйналган». Искәндәр бик азга гына сөенеп яши белә, Сөмбелгә кечкенә дип тоелган фатирга да ул балаларча сөенә. Монда без ир белән хатынның тормышка булган карашларының төрле булуына тап булабыз. Алар «урыннары очраклы гына туры килгән пассажирлар кебек» яшиләр. Гаилә таркалгач, Искәндәр очраган бер поездга утырып, билгесез сәфәргә чыгып китә. Әсәрнең «Поездда» дигән бүлегендә без ярдәмче образлар белән очрашабыз. Ибрай, Мотыйк, Сәгыйдулла – тормышның ачысын-төчесен күп күргән гади хезмәт кешеләре. Алар тәэсирендә Искәндәрнең күзе ачыла. Ул киләчәккә өмет белән карый башлый. Әсәр юлларына күз салыйк:

«...ул моңа кадәр еллар буе җанын газаплап йөргән сорауларга, ниһаять, җавап табуын аңлап, аһ итте... бары поезд, аның йөрәгенә кушылып текелдәгән вагон тәгәрмәчләре, бераз беркатлырак, ләкин авылча хәйләкәр, авылча үҗәт бригадир Ибрай, күпме яшәп тә җирдә үз урынын тапмаган, күңеле утырмаган сәрхүш Мотыйк, бүген белән үткәне арасында йөреп, киләчәге турында кайгыртырга оныткан Сәгыйдулла бабай гына аңа тормыш мәгънәсен аңлата ала иде» (2, 408).

Күргәнебезчә, «Иске сәгать дөрес йөри» повестенең образлар системасын оештыруда яшьләрнең роле бик зур. Алар барысы да тормышта авырлыклар белән очрашалар. Студент вакытта алар киләчәккә планнар корып яшиләр. Еллар үткәч, кайберләре тормышта үз урыннарын бик җиңел таба, ә кайберләре сайлаган юлларыннан тайпыла яки гомере буе тормыш мәгънәсен эзләп, бәргәләнеп яши. Ничек кенә булмасын, автор безгә яшьләрнең үз намусларына тап төшермичә, авыр тормыш киртәләрен үтүләрен күрсәтергә тели.

Разил Вәлиевнең бу әсәре кеше образларын психологик планда тасвирлануы белән үзенчәлекле, әдипнең геройлары, аның үз сүзләре белән әйтсәк, «үз күңелләрендә, үз эчләрендә казыналар, тормыш мәгънәсен

аңларга тырышалар, җәмгыятьтә, дөньяда үз урыннарын табарга омтылалар, шуның өчен көрәшәләр» (3, 49–50).

ӘДӘБИЯТ

1. Фәрваз Миңнуллин Прозаның гражданлык йөзе (Бүгенге прозада повесть жанры). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 40 б.

2. Вәлиев Р. Әсәрләр: 4 томда / Разил Вәлиев. 2 т. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2006. –372 б.

3. Балачак әдипләре Биобиблиографик белешмәлек. I китап. Рәис Даутов. – Казан: Мәгариф, 2006. – 49–50 б.

***Г. М. Насретдинова***
***Казань***

## ИНФОРМАТИВНОСТЬ И ХУДОЖЕСТВЕННАЯ ЦЕННОСТЬ В ФАНТАСТИЧЕСКИХ ПРОИЗВЕДЕНИЯХ

Художественный текст выражает информацию в тесной связи с характерными особенностями участника коммуникации, его ориентацией на читателя, назначением, отбором элементов и способа осуществления сообщения. Текстовая коммуникация в рамках произведений фантастического жанра (в частности произведений Адлера Тимергалина) «детерминирована различными факторами ситуации общения», что предусматривает необходимость «связывания процессов коммуникации с многообразием функциональной реализации языка» при отражении информационной составляющей произведения (1, 87).

Главная, общая цель создания любого произведения – сообщение информации. Любой текст заключает в себе какую-либо информацию. Общее количество информации, содержащейся в тексте, – это информационная насыщенность. Однако, ценностью обладает прежде всего новая информация, полезная, т. е. прагматическая, именно она является показателем информативности текста. «Информационная насыщенность текста – абсолютный показатель качества текста, а информативность – относительный, поскольку степень информативности сообщения зависит от потенциального читателя» (5, 112). «Информативность текста – это степень его смысло-содержательной новизны для читателя, которая заключена в теме и авторской концепции, система авторских оценок предмета мысли» (5, 115).

Мера информативных качеств текста может снижаться или возрастать. Так, информативность (с точки зрения прагматики текста) снижается,

если информация повторяется, и, наоборот, она повышается, если текст несет максимально новую информацию. В связи с этим существенной оказывается проблема авторского намерения и читательского восприятия сообщения, т.е. кодирования и декодирования текста.

Авторы художественных, научно-популярных текстов обычно ориентируются на так называемого среднего читателя (условно – усвоившего программу средней школы). Но само понятие среднего читателя может меняться. Например, автор научной статьи ориентируется на специалиста данной отрасли знания. И для данного автора это тоже будет «средний читатель». Поэтому при определении меры полезности информации в тексте лучше ориентироваться на соответствие/несоответствие уровня читателя информационным качествам текста и, следовательно, уровню автора.

Информация, содержащаяся в художественном тексте фантастического произведения, оказывает влияние на познавательную деятельность читателя, и она направлена, с одной стороны, на восприятие информации, заключенной в произведении и освоение писательских целей, с другой – на совместную речевую деятельность, как проявление объединяющих творческих порывов (4, 87). Такое положение определяет востребованность фантастической литературы, которая позволяет рассматривать в совокупности реальность и целенаправленный вымысел.

Особый интерес вызывает информационная составляющая данных произведений и способы ее передачи. Информация в фантастических произведениях литературы амбивалентна: речь идет не о документальности, достоверности, исторической заданности, а о чистейшем вымысле автора-писателя и выразительности, художественности. Именно в таком произведении значительная роль отводится текстовой организации, включающей функционирование языковых единиц. «Для рассматриваемых произведений важно логико-смысловое взаимодействие указанных сторон детерминации информации, которая в подобных текстах имеет разноплановый характер и служит в первую очередь выражению авторских интенций, поэтому для анализа языковых средств как способа манифестации сообщений весьма существенен индивидуальный подход к ним», – подчеркивает И. А. Анашкина (5, 68). Такое положение требует от писателя особого отношения к языку описываемой эпохи с непременным учетом современного состояния лингвистики (норм, стилистики, жанра). Языковое выражение информативности в таких произведениях «сопряжено с функционированием текстовых категорий, обеспечивающих взаимосвязь аутентичной и креативной содержательности,

в результате которой возникает целостное представление об описываемом» (2, 251). Хорошая фантастическая идея должна быть новой, убедительной и, кроме того, рассказывать не только о «хладном мире машин», но и о человеке, который в этом мире живет. Основной критерий оценки фантастических произведений, как утверждает шкала «Фантазия» – это художественная ценность идеи. Именно этим отличается хорошая фантастическая идея от выдающегося изобретения (1, 105). Изобретение нужно точно сформулировать. А фантастическую идею не обязательно формулировать точно. Главное, – сформулировать красиво, художественно, убедительно, ярко. Например, очень популярная для фантастики идея – летающий человек. Такая идея заложена в произведении русского фантаста А. Беляева.

Самой низкой по критерию «художественная ценность» получится идея, воплощение которой вовсе лишено литературных достоинств. Кто сейчас перечитывает популярные когда-то фантастические романы А. Беляева, В. Немцова? Вроде бы и идеи были новые для своего времени, и очень даже убедительные – вполне на уровне научных знаний. Но почему их никто не перечитывает? Причина этому, как нам видится, – не совсем правильное с точки зрения «художественности» литературное воплощение. Низко оцениваются также такие произведения, в которых можно увидеть хотя бы одну чисто литературную находку. Может, что-то оригинальное в сюжете. Может, какая-то стилевая авторская особенность. Часто можно увидеть идеи, на воплощении которой лежит явная печать личности автора. Своеобразный язык, оригинальный сюжет, какая-то другая художественная придумка. «Не так много в фантастике авторов, которых узнаешь “по походке”. Например. В. Шефнер “Запоздалый стрелок” или “Скромный гений”. Идеи этих повестей по новизне и по убедительности не выше. Но его произведения переиздаются каждый год, и даже на перенасыщенном нынче рынке фантастики пользуются читательской популярностью. Литературоведы с точки зрения художественности даже произведения В. Шефнера оценивают критично» (3, 127).

Так каким же должно быть фантастическое произведение? В этом сложном вопросе почти все исследователи русской литературной фантастики сходятся в мнении: это А. Грин и его «Алые паруса», «Золотая цепь». А из западных авторов этим вниманием пользуется Рей Брэдбери. Идеи этих двух писателей стары как мир! С точки зрения убедительности они тоже не доказываются, одни лишь рассуждения авторов. Но вот по критерию «человековедческая ценность» идеи их романов

получают высокий балл. Но для оценки и выявления эталона фантастического произведения – этого мало: прочитав оба романа, и мы увидим, как много осталось за пределами этих оценок! Скажем, некоторая сухость языка, легко узнаваемая с первого же предложения. Остался удивительный привкус странной страны Зурбаган в романе А. Грина. Если не оценить чисто художественные находки авторов, разве возможно верно судить о том, хороши или нехороши идеи «Блистающего мира» и «Ариэля» А. Грина?

Таким образом, фантастическое произведение – это литература, и без литературных оценок не обойтись. Но главное, на что следует опираться при анализе таких произведений, это – художественность, информативность, и языковые особенности выражения авторского вымысла.

ЛИТЕРАТУРА

1. Азнаурова Э. С. Прагматика художественного слова. – Ташкент, 1988. – 208с.

2. Анашкина И. А. Аксиологический аспект коммуникации // Язык, культура, коммуникация: контексты современности: Материалы межрегион, науч. конф. 26–27 окт. 2000г. – Саранск, 2000.

3. Антипов Г. А., Донских О. А., Марковина И. Ю., Сорокин Ю. А. Текст как явление культуры. – Новосибирск, 1989.

4. Балдова В. А. Экспериментальное исследование влияния авторских ключевых слов на понимание специального текста // Семантика слова и текста психолингвистического исследования. – Тверь, 1998.

5. Горожанкина Л. В. Моделирование содержательной информации художественного текста // Коммуникативно-прагматическая семантика: сб. науч. ст. – Волгоград, 2000.

***Н. Ш. Насыйбуллина***
***Казан***

## БАЛАЛАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ Р. МИҢНУЛЛИННЫҢ ИҖАТ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Р. Миңнуллин шагыйрь буларак XX гасыр ахыры – XXI гасыр башы татар поэзиясендә иң күренекле, иң үзәк урыннарның берсен алып тора. Аның иҗаты күпкырлы һәмербөтен. Әдәбият галиме Ф. Галимуллин: «Ул олыларга язганда балаларны күздә тота, кечкенәләр өчен иҗат иткәндә, зурларны уйландырырлык һәм елмайтырлык сүзләр таба» дип, шагыйрь иҗатына карата бәя бирә (1, 67). «Балалар өчен язылган шигырьнең беренче вазифасы – Туган илгә, кешеләргә мәхәббәт

тәрбияләү, шул ук вакытта бала күңеленә туган телебезнең тәмен, тирәнлеген, нечкәлеген, шигърияттен сеңдерү. Биредә инде гадилек кирәк. Нәниләр өчен язылган шигырьләр туган телне өйрәнүнең беренче күнекмәләрен бирә. Шуңа күрә дә биредә сүз белән аеруча сак булу шарт. Шигырьдәге сүзләр зәвык белән сайлап алынган булырга тиеш. Сүз тезмәләре, шигырь юлларының ювелирларча эшкәртелгән булуы зарури. Чөнки бала нәкъ шул яшьтә үз теленең тәмен, кадерен белергә өйрәнә. Бу яшьтә аны үз телен яратучы, хөрмәт итүче итеп тә тәрбияләргә мөмкин, киресен дә эшләп була» дип билгеләп үтә Р. Миңнуллин «Киләчәк буын хакында» исемле мәкаләсендә (2, 81). Һәр дәвернең алдынгы әдибенә хас булганча, шагыйрь яшь буынны тәрбияләү мәсьәләсен читләтеп үтә алмый, моны үзенең намус эше итеп саный.

Бала һәм Ана, бала һәм тарих (шушында ук милли аң), бала һәм җәмгыять, бала һәм табигать дип билгеләргә мөмкин булган төп проблемаларны яктыртуга, бала психологиясен, теләк һәм хыялларын аңлап сурәтләүгә шагыйрьнең игътибары зур. Бу үз чиратында, шигърияттә оптимизм һәм патриотизм тойгысының үсешенә китерә. Р. Миңнуллин шигырьләрендәге һәр фикер баланы шәхес буларак ачу өчен тупланган. Ул әсәрдән әсәргә үзфикергә ия, үз-үзен һәм тирә-юньдәге хәлне реаль бәяләүче, тормышта актив гражданлык позициясендә торучы нәни герой, яңа кеше – нәни гражданин образын тудыра.

Шагыйрь кечкенә геройны тормышның иҗтимагый хәлләре белән аерылгысыз бәйләнештә сурәтли; бу аның әсәрләренең тәрбияви кыйммәтен бермә-бер күтәрә.

Балалар күңелен гади һәм шул ук вакытта оста итеп ачуын шагыйрьнең «Акбай цирк карый», «Җиде абый тай җигә», «Айга очтык», «Балачак бәйрәмнәре», «Җәйнең яшел аты», рус телендә тәрҗемәләрен туплаган «Глядит в окошко человек» дигән шигырь җыентыклары раслый.

Үз чоры рухында фикер йөртеп, Р. Миңнуллин шигырьләрендә еш кына бәхетле, якты балачак иле идеясен үткәрә. Бу бигрәк тә шагыйрьнең сүз уйнатуларында, төрле мәзәкләрендә чагыла. Якты балачак иленең төрле бизәкләрен – сабан туйларын, мәктәп тормышын, күңелле уеннарны, яңа ел кичәләрен, кояшлы көннәрне, киң болыннарны тасвирлап, автор сабыйда патриотизм, гаделлек, өлкәннәргә ихтирам хисе тәрбияли.

Балалар психологиясен шигъри юлларга күчерү нисбәтеннән Роберт Миңнуллин иҗаты тематик яктан караганда шактый киң: тарихи үткән, өлкәннәр тормышында бала яшәеше, табигать, балалар бакчасы, мәктәп белән бәйле вакыйгалар һ. б. Мисалга «Батыр булыгыз!», «Сабантуй бүген бездә», «Безнең гаилә» шигъри циклларын китерергә мөмкин.

Шигырьләрендә ул балаларны көлдерә дә, уйландыра һәм «чеметкәләп» тә ала, образлы тел аша бала җанына үтеп керергә, психологиясен ачарга омтыла. Чөнки психологик алым, алга таба, баланы үзгәртеп тәрбияләү өчен төп шартны ассызыклый.

Шагыйрь җиңел, аңлаешлы һәм бер үк вакытта гаять җанлы тел белән, сәнгать чаралары ярдәмендә балаларны чынбарлык һәм тормыш белән таныштыра, аларга белем биреп, зиһен һәм иҗади сәләтләрен үстерергә омтыла, кешеләргә карата гуманлы караш, гыйлем-мәгърифәткә мәхәббәт, эстетик һәм әхлакый тәрбия бирергә булыша. Р. Миңнуллин әсәрләренең идея-эстетик байлыгы зур булганлыктан аларның тәрбияви роле һәм әһәмияте дә бермә-бер арта. Шагыйрь балаларның психологик үзенчәлекләрен тирән аңлап, белеп һәм тоеп иҗат итә.

Р. Миңнуллин фантазиясе тудырган гаҗәеп дөнья – яңа теле ачылган нәниләрдән алып, мәктәп яшендәгеләргәчә булган кыз-малайларның күпкырлы һәм кызыклы тормышы: уеннары, укулары, шатлык-борчылулары, уй-хыяллары – кыскасы, **кеше һәм шәхес** буларак җитлегү процессындагы катлаулы мөнәсәбәтләре сәнгатьчә нәфис буяуларда һәм тормышчан ситауцияләрдә тасвирлана. Юмор катыш җор-йөгерек тел, шигъри тапкырлык һәм фантазия, балалар табигатен тирән тою һәм аларга карата ышаныч-хөрмәт – шушы сыйфатлар шагыйрьгә балалар белән ихлас мөгамәләгә керергә һәм, бернинди үгет-нәсыйхәтсез, иң җитди темалар турында да бала күңеленә уңай йогынты ясарлык чын сәнгати әсәрләр иҗат итәргә мөмкинлек бирә. Шагыйрьнең балалар өчен язган шигырьләре тулы мәгънәсендә олы, гуманистик фикерләр, туган халкыңа тугрылыклы булу, табигатькә һәм хезмәткә мәхәббәт хисләре белән сугарылган.

Балалар шагыйре өчен сабыйның табигатькә мөнәсәбәтен ачу әһәмиятле, чөнки ул мәңгелек проблема – яхшылык һәм явызлык төшенчәләре белән бәйләнә. Бу очракта табигать вакыйгалар барышында фон гына түгел, ә әсәрнең гомум структурасында әһәмиятле эстетик элемент та. Табигать, характерларны тулырак һәм төгәлрәк аңлау мөмкинлеген ачу белән бергә, автор талантының көчен бәяләргә дә мөмкинлекләр бирә.

Җирнең матурлыгы балалар, кош-корт, хайваннар, гомумән, табигать белән бәйләнгән. Табигать белән конфликтның начарлыкка илтүен, табигать белән бергә рухи байлыкның да югала баруын аңлаган шагыйрь әлеге проблемаларны фәлсәфи планда фикер йөртеп яктыртырга омтыла. Теманы кеше күңеле, милләт, тарих, героик үткән кебек төшенчәләр белән бәйләп карый.

Р. Миңнуллин шигырьләрендә мәрхәмәтлелек хисе күбрәк табигатьтәге җан ияләренә җылы мөнәсәбәт аша гәүдәләнә. Мәрхәмәтлелекнең

бер канаты дуслык хисенә барып тоташа. Монда да ул образларны табигатьтән ала. «Кара инде бу гөлне», «Акбай, Актүш, Актырнак», «Ашыгабыз дуслар янына!», «Дуслыкның кадерен белик», «Кар бәйрәме», «Күңелле сәфәр», «Балачак учаклары», «Сөн буенда» һ. б. шигырьләрендә матур табигать, дуслык – яшәү яме чагылыш таба. Бу шигырьләрдә, балалар әдәбиятына хас булганча, төрле характердагы малайлар-кызлар, ягымлы әби-бабайлар, хайваннар, кошлар, җәнлекләр, табигатьтәге хәлләр – кыскасы, бүгенге кайнап торган тормыш чагыла.

Шулай ук ил тарихына кагылышлы темалар да иҗатының зур өлешен ала. Аның күпчелек шигырьләре югары гражданлык һәм патриотизм рухы белән сугарылганнар.

Гражданлык, патриотик тәрбия мәсьәләләрен яктырту балалар әдәбиятында күптәннән килә. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Г. Кутуй һ. б. традицияләрен Роберт Миңнуллин уңышлы дәвам иттерә. Әдипнең патриотик темага якын килүе үзенчәлекле социаль-тарихи, шәхес иреге мәсьәләсе белән бәйле.

Мәгълүм ки, туган илне саклау идеясе, патриотик пафос сурәтләү чараларының эстетик системасы кебек үк, тамырлары белән халык авыз иҗатына, азатлыкка омтылышны үзәккә куйган тарихи-героик җырларга барып тоташа. Илне саклаучы герой үзендә фольклордан килгән алыплар сыйфатларын йөртә. «Аҗаган»чылар җыры», «Ышаныгыз безгә», «Әкият батырлары» кебек әсәрләрендә шагыйрь лирик-психологик кичерешләрне сурәтләгәгән вакытта әкият, җыр, мәкаль-әйтем, такмак-такмаза кебек жанрларның аерым элементларына мөрәҗәгать итә. Аларда татар халкына хас моң, музыкальлек, фикер төгәллеге сизелә. Шагыйрь, фольклор элементларын файдаланып, романтик рухлы балалар әдәбиятын сәнгатьлелек ягыннан югары баскычка күтәрә.

Теленең үткерлеге, тәрбияви юнәлешенең көчлелеге, сюжетларының мавыктыргыч һәм кызыклы булуы, сурәтләүдәге буяуларының куелыгы, сурәтләнә торган предметны, геройны нәкъ балаларча күрә һәм күрсәтә белүе шагыйрьгә зур уңышлар алып килде. Аның балаларга атап язган бер генә китабы да җәмәгатьчелек игътибарыннан читтә калмый. Мәсәлән, «Безнең авыл зоопаркы» (1988), «Энекәш кирәк миңа» (1990) исемле китаплары Республика конкурсларында беренче урыннарны яулады. «Дөньяда иң зур алма» (1992) исемле китабы өчен шагыйрь халыкара әдәби бүләккә – Г.-Х. Андерсен исемендәге почетлы дипломга лаек булды. Исеме атаклы әкиятченең Почетлы исемлегенә кертелде. Нәтиҗәдә, Шәүкәт Галиев белән бергә, ул да балалар әдәбиятының иң күренекле вәкилләре рәтенә күтәрелде. 1997 елда Р. Миңнуллинга

балалар әдәбияты өлкәсендә ирешкән казанышлары өчен Татарстан язучылар берлегенең А. Алиш исемендәге бүләге бирелде. 1998 елда исә шагыйрь «Мәгариф» нәшрияты чыгарган «Күчтәнәч» (1995) дигән китабы өчен Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә лаек булды.

Шагыйрьнең педагогик һәм психологик яктан төгәл уйланылган, поэтик яктан зур осталык белән иҗат ителгән шигырьләре татар урта гомуми белем бирү мәктәпләре өчен төзелгән татар теле дәреслекләренә кертелде. Ул һәрчак халык һәм ил тормышын – үз тормышы, дөнья гамен – үз гаме итеп яши һәм иҗат итә. Язучы буларак та, дәүләт эшлеклесе буларак та шагыйрь нәниләр дөньясы белән тыгыз элемтәдә. Аның иҗаты – дәвернең җанлы сулышы, яшәү мәгънәсен үз эченә алган тәрбия чарасы.

ӘДӘБИЯТ


1. Галимуллин Ф. Роберт Миңнуллин – балалар шагыйре / Ф. Галимуллин // Хәзерге татар әдәбияты һәм Роберт Миңнуллин: Татарстанның халык шагыйренә 60 яшь тулуга багышланган төбәкара фәнни-гамәли конференция материаллары (16 октябрь 2008). – Казан, 2008. –344б.

2. Миңнуллин Р. Шагыйрь генә булып калмадым...: Публицистика / Р. Миңнуллин. – Казан: Матбугат йорты, 1998.

3. Миңнуллин Р. Әсәрләр: 7 томда / Р. Миңнуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2007.



***Э. Р. Нәбиуллина***

***Казан***


## ТӨРЕК ӘДӘБИЯТЫНЫҢ XX ЙӨЗ БАШЫ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫНА ТӘЭСИР ИТҮ ЮЛЛАРЫ

XIX–XX гасыр чикләрендә татар әдәбияты үзенең үсешенең яңа этабына аяк баса. Моңа кадәр Европа, рус әдәбиятына хас булган көнбатышка йөз тоту күренеше татар әдәбиятында да арта. Дөньякүләм әдәбият барышында аерым урынны төрек әдәбияты алып тора. Ул төрки халыклар арасында беренчеләрдән булып әлеге агымга кушыла. Бу күренеш аеруча төрек прозасы һәм драматургиясенең алга китеше, газета-журналлар чыгаруның җанлануы, ватан, милләт, ирек, хатын-кыз кебек әһәмиятле мәсьәләләр күтәрелүе буларак характерлана.

Яңа чор татар әдәбияты вәкилләренең күпчелеге төрек телен яхшы белгәннәр, госманлы чоры һәм Танзимат әдәбияты белән якыннан таныш булганнар, чөнки төрекләр һәм татарлар тугандаш халыклар, бер

динне тоталар, язуда гарәп графикасын кулланганнар, этик кануннары һәм эстетик кыйммәтләре икесенеке дә шәркый мөселманлыкка барып тоташа. Патша хакимиятенең төрле каршылыкларына карамастан, татарлар белән төрекләр арасында игътисад, мәдәният ягыннан тыгыз бәйләнешләр урнашкан. Ш. Камал, Г. Ибраһимов, Г. Исхакый, Ф. Кәрими кебек башка татар язучыларының иҗат юлын өйрәнгәндә татар белән төрекләр арасында туган күпсанлы әдәби параллельләргә юлыгабыз. Бу бәйләнешләр әдәбият белемендә ике яклы өйрәнелә. Әлеге юнәлештә төрек галимнәреннән – Мустафа Өнәр, Хәлил Ачыкгөзнең һ. б., татарлардан Резеда Ганиева, Рифә Харрасова, Хатыйп Миңнегулов, Рамил Ханнановның хезмәтләре кызыклы.

Төркилекнең татарлар даирәсенә үтеп керү, мәдәнияткә, әдәбияткә тәэсир итү юлларын өйрәнү кызыклы. Бу хәрәкәт төрле юнәлештә, төрле юллар белән алып барылган.

XIX гасыр азагы – XX гасыр башларында Төркиядә булып кайткан һәр татар, аннан китап алып кайтырга тырышкан. «Төрекләрдә матбагачылык эшенә нигез салынгач чыккан барлык әсәрләр дә Идел буена килә, татар сәүдәгәрләре хәтта төрек нәширләренең абонентлары булып тора һәм басма продукцияне күп санда ала. Нәкъ менә шул китапларның шактые киләчәктә татар телендә дә дөнья күрә» (2, 166), – дип яза галим Әбрар Кәримуллин.

Бер төркем татар әдипләре Төркиядә үзләре үк укыганнар яки төрле сәбәпләр аркасында берара яшәп алганнар. Шулай ук татар мөселманнарының Мәккәгә баручы хаҗ юллары һәрвакыт Төркия аша узуын искә алырга кирәк. Төркиядә яшәп, аның төрле юнәлештәге үсеше белән якыннан танышкан Дәрдмәнд, Шәриф Камал, Муса Акъегетзадә, Фатих Кәрими кебек әдипләрнең иҗатына, карашларына төрек мәдәнияте тәэсире көчле булуы билгеле. Ияреп язулар милли әдәбиятта яңа тема, сюжетлар, жанрлар барлыкка китерә.

Бер яктан, төрек әдипләренә иярүләр, алар үрнәгендә яңа әсәрләр иҗат итү булса, икенче яктан, төрек әсәрләренең турыдан-туры тәрҗемәләре дә татарларда дөнья күрә. Мәсәлән, Галиәсгар Камал да драматургия өлкәсендәге беренче адымнарын төрекчәдән тәрҗемә белән башлый (1, 531). Ул Н. Кямалның «Zavalli cocuk» драмасын «Кызганыч бала» исеме белән тәрҗемә итә. Шулай ук, Европа тибындагы новелла жанрына нигез салучы Халид Зыя Ушаклыгөлнең иҗаты Шәриф Камал прозасында тоемлана.

Төрек әдипләре татарларны үз әсәрләре белән генә баетып калмый, ә аларны киңрәк мәйданга чыгара, француз әдәбияты белән дә таныштыра.

Мисал итеп, Гаяз Исхакыйның «Толстойның татар әдәбиятына тәэсире» («Милли юл», 1926. – № 8) мәкаләсеннән бер өзек китерергә була: «Әүвәлән минем “Тәгаллемдә сәгадәт...”, “Кәләпүшче кыз”, “Бай углы”, “Өч хатын берлә тормыш” әсәрләрем рус әдәбияты берлә таныш булмаган дәверемдә язылган. Ул вакытта минем укыган әдәбиятым госманлы әдәбияты вә төрекчә аша тәрҗемә француз әдәбиятыдыр. Жюль Верн, Виктор Гюго, Мопассан, Доде, Дюмалар белән мин төрекчәдән таныштым». Шулай ук, татарларның француз теленә Ш. Сами чыгарган сүзлек ярдәмендә өйрәнүе мәгълүм. «Бу ноктадан гына карасак та, без төрекләрне татар язучыларын француз мәдәниятенә якынайтучылар буларак танырга тиеш», – дип яза бу турыда галимә Рифә Харрасова.

Төрки халыклар мәдәнияте үсешендә аерым бер эз калдырган шәхесләрнең берсе – Тәүфикъ Әбуззыя. Ул – күренекле тәнкыйтьче, халыкка белем бирү, китаплар бастыру, дивар календарьларе чыгару белән шөгыльләнә. Әлеге календарьләр татарлар арасында да киң тарала. Төрек әдәбияты, халык авыз иҗаты, фикере татарларга мондый юллар белән дә килеп ирешә.

Татарларның ул чорда вакытлы мәтбугатта төрек әдәбияты, мәдәнияте, гомумән, төрек темасы киң яктыртыла. «Әл-ислах» газетасының 1908 елның 14 август (41 нче) санында: «Яшьләр үзара түгәрәк ясап рус, гарәп, төрек телендә язылган файдалы китаплар тәрҗемә итәргә телиләр» – диелә. «Әлгасрел-җәдид» (Нәҗметдин Саминың «Мөгаллим хикмәт» әсәре 1906, № 6), «Шура» (Т. Фикрәт әсәре «Балыкчылар» (1909, № 6)), «Вакыт», «Төрек йорты», «Йолдыз» һ. б. кебек газета-журналларының битләрендә төрек теленнән тәрҗемә ителгән әсәрләрнең урын алуы халыкка төрек дөньясы, мәдәнияте, әдәбияте кызыклы булуы турында сөйләргә нигез булып тора.

Төрек-татар мөнәсәбәтләре турында сүз алып барганда, аларны Исмәгыйль Гаспралыдан һәм ул чыгарган «Тәрҗеман» газетасыннан башка күз алдына китереп булмый. Әдип төрки халыкларны дөнья әдәбияты үрнәкләре белән таныштыруга зур өлеш кертә. Д. Дефоның «Робинзон»ының камилрәк 1904 елгы басмасын ул хәзерли (3, 105). Шулай ук гәзитне эчтәлекле материаллар белән тулыландырып торуда төрле төрки кавемнәрнең вәкилләре актив катнашалар. Алар Идел буе татарлары, Төркестаннан, кырымлылар, шул исәптән Төркиядән Ибраһим Фәһми, Фуад Күпреле, Әхмәд Мидхәт һ. б.

Татар әдипләренең тәнкыйди хезмәтләрендә, мәкаләләрдә әлеге мәсьәләгә шулай ук зур урын бирелә. Мәсәлән: Ф. Кәрими «Халидә ханым хозурында», Г. Кәримов «Яңа госманлы әдәбияты», Г. Ибраһимов-

ның Ф. Кәримигә язган хатында төрек әдипләрен олылавы турында сөйләве һ. б.

Татарлар белән төрекләр бәйләнешенең тагы бер сәбәбе – аларның үзара якыннан таныш булуы, аралашуы. Төркиядән куылган ирекле фикерле шагыйрь – Габделвәли Әмрулла Габдулла Тукайны күренекле төрек шагыйрьләре, драматурглары белән таныштыра, француз романнарының эчтәлеген сөйли. Бу факт әдәбият мәйданына аяк басканда Г. Тукай да төрек әдәбиятыннан үрнәк алган, дигән фикергә нигез булып тора. Моннан тыш, Фатих Кәрими белән Әхмәд Мидхәтнең якын аралашуын, үзара хат алышуларын да әйтеп китәргә кирәк.

Шул рәвешле, төрек әдәбиятының төрле юллар аша татар әдәбиятына тәэсир итүе әдәбият тарихында уңай күренеш буларак бәяләнә. Кызганыч ки, 1917 елгы Октябрь революциясе әлеге мөнәсәбәтләрне тараюга китерә.

ӘДӘБИЯТ

1. Ганиева Р. Көнчыгыш традицияләрен үстереп / Р. Ганиева // Татар әдәбияты тарихы. XX гасыр башы татар әдәбияты: 6 томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1986. – 3 том. – Б.530.

2. Каримуллин А. Татарская книга пореформенной России / А. Каримуллин. – Казань, 1983. – С. 166–168.

3. Харрасова Р. Ф. Әдәби бәйләнешләр яктылыгында / Р. Ф. Харрасова. – Казан: РПФ «Гарт», 2002. – 261 б.

***Р. Р. Сабиров***
***Казан***

## ГАЗИЗ КАШАПОВ ПРОЗАСЫНЫҢ КАЙБЕР ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

Милли сүз сәнгатендә ниндидер сәбәпләр белән өйрәнелми килгән язучы-әдипләр шактый әле. Армиядә хезмәт иткәндә алган җәрәхәтләреннән арына алмыйча, 1991 елда 49 яшендә бакыйлыкка күчкән язучы-солдат Газиз Кашаповның иҗат мирасы да бүгенге көн укучысына аз таныш, киңкырлы әдәби эшчәнлеге дә, поэзиясе, хикәя, повесть, романнары да өйрәнелмичә кала.

Узган гасырның җитмешенче еллар уртасында әдәбият бусагасын атлап кергән Газиз Кашаповның иҗат гомере озын түгел, нибары унбиш еллап вакытны үз эченә ала. Әлбәттә, шушы кыска вакыт эчендә сүз

сәнгате өлкәсендә үз сүзеңне әйтү, үз йөзеңне булдыру – шактый авыр эш. Ләкин Г. Кашаповның милли сүз сәнгате тарихында үз урыны бар дип ышанып әйтергә мөмкин. Ул үз иҗатында беркемне дә кабатламый, үзенә генә хас тематик өлкәсе белән аерылып тора, образ-геройлары да үзгә.

Отставкадагы офицер Газиз Кашапов татар әдәбиятында Г. Әпсәләмов, Х. Камалов, Ш. Рәкыйповлардан соң онытылып торган хәрби теманы яңартып җибәргән язучы буларак танылу ала. Бөек Ватан сугышы темасына өстенлек биргән югарыда аталган язучылардан аермалы буларак, аның әсәрләре үз чоры армиясе хакында, әсәрләрендә хәрби тормыш та бөтен каршылыгы, яхшы яклары, начарлыклары белән сурәтләнә. Һәм алар ышандыра да, чөнки реалист язучы буларак, Г. Кашапов әсәрләренә бары тик үзе күргәннәрен, ишеткәннәрен генә чыганак итеп ала. Шунлыктан аерым әсәрләрен автобиографик яки биографик характерда дип бәяләргә тулы нигез бар. Моның шулай икәненә инану өчен язучының «Сәмум җиле» һәм «Убырут» повестьларын укып чыгу да җитә. Беренчесе, язучының үз тормышын тулысынча диярлек чагылдырса, икенчесендә, бер авылдашының тормыш-көнкүреше тасвирлана.

Хәрби тематикага корылган әсәрләргә хас булганча, Г. Кашапов әлеге повестьларында хәрби темага бәйле аерым проблемаларны аерып чыгара: сугыштан соңгы тормыш, хәрби тормыш алып килгән ятимлек бәласе, батырлык, патриотизм, туган якны сагыну һәм ярату, интернациональ дуслык, ата-ана һәм бала мөнәсәбәтләре һ. б. Образлары да истә калырлык. Кашапов үз әсәрләрендә төп герой һәм ярдәмче геройларны аерып куярга ярата. «Сәмум җиле»ндә баш каһарман Рамиз Җәләев булса, «Лачын кошка күкләр кадерле» повестенда – Барый Кадерматов. Ярдәмче геройлар исә аларның холык-фигыльләрен, кичәге һәм бүгенге тормышларын, хыял-омтылышларын тулырак ачу максатында кулланыла.

Кашаповның вакыйга һәм геройларны тормыштан алып язуына игътибар итеп, язучының университеттагы укытучысы, әсәрләренә беренче фикер әйтүче Мөхәммәт Мәһдиев болай дип белдерә: «Солдат тормышын ул күргәннәрен чыгып яза. Газиз – шинельне кайсы яктан төймәләсен, винтовканы яки автоматны пирамидага ничек куясын, иртәнге “подъем” командасында ятагыңнан сикереп төшкәч иң башта нәрсә киясен яхшы белән. Китаплардан укып түгел... Дилетантлыкны теләсә кайсы өлкәдә гафу итеп була, ләкин әдәбиятта – булмый» (3, 199). Галим шулай ук Кашаповның әсәрләрендәге «салкынлыкның, нидер җитмәүлекне һәм аның сәбәбен» дә ачып сала: «Ни җитми? Соңрак

аңладым: язучының тел-тасвирлау чараларына җылылык җитми. Моның сәбәбе бар: яшьлеге формалашкан чорга туры килгән казарма, строй, наряд – рәхимсез, кырыс устав таләпләре. Шулардан башка армия буламыни?» (3, 199). Мәһдиевның әлеге фикерләре белән икенче бер олуг язучыбыз, шулай ук Кашаповның сирәк дусларыннан берсе Аяз Гыйләҗев та килешә: «Безнең язучылар күргәннәре әзлектән, кичергәннәре сайлыктан җәфа чигә. Язучының иҗат биеклеген үзе кичергән язмыш та, әлеге кичерешләренә бирә алган бәянең гаделлеге дә билгели. Газиз үз чордашлары арасында иң бай тормыш кичергән шәхес иде» (2, 350).

Татар әдәбиятында яңалык буларак яңгыраган «Убырут» повесте – Г. Кашапов иҗатында сыйфат үзгәреше барлыкка килүен раслаган әсәр. Моңа кадәр язган әсәрләре хәрбиләрчә кырыслык, үткәндәге гаепләрен өчен җәза алуга хөкем ителгән Мәүләви образын үзәккә алган «Убырут»та (мишәрләрдә шайтан таягын шулай атыйлар) беренче планга психологизм чыга. Бу әсәрдә төрле әдәби детальләр, символлар кулланылышы игътибарга лаек. Әйтик, песи образы, давыллы-яңгырлы төн, имән символы һәм әлеге меңъяшәр агачның урталай сыну күренеше, Ят Тавыш – Вөҗдан образы, үләт базы – бар да кичәге гөнаһлары өчен вөҗдан газабы кичерүче төп геройның холкын ачу өчен кулланыла. Вөҗдан темасын үз эченә алган дип әйтергә мөмкин булган әлеге әсәрдә гөнаһ-җәза-тәүбә итү эволюциясе аша рухи чистарыну мотивы беренче планга чыга.

«Убырут» повестында вакыт бирелеше кызыклы. Төп вакыйгалар бер көн эчендә бара, биредә илдә барган иҗтимагый вакыйгалар басымы астында хаталар ясаган баш геройның үз вөҗданы белән сөйләшеп, хаталарын тануы, рәнҗеткән кешеләрдән гафу үтенүе, бәхиллек соравы төсен ала. Ләкин автор ретроспекция алымын кулланып, Мәүләвине үткәнгә алып китә, төп гаепләренең яшьлегендә кылынганлыгы ачыклана. «Убырут» повесте күпмедер дәрәҗәдә Аяз Гыйләҗевның «Өч аршын җир» әсәре белән аваздаш. «Образлары автор ихтыяры буенча әзер фикер калыбы хәлендә генә калмыйча, катлаулы һәм җанлы шәхес дәрәҗәсенә җиткерелсә, вакыйгалары тормыш хакыйкатенә хилафлык китермәсә, мондый әсәрләр укучы күңелен били, аны сызландыра, шатландыра яки нәфрәтләндерә. Газиз Кашаповның «Убырут» повесте исеме белән дә, бөтен эчке рухы белән дә нәкъ менә шундыйлар исәбенә керә» (1, 205), – дип язган иде заманында Тәүфикъ Әйди.

Армиядән җәрәхәтләнеп кайтып, бераз дәвалангач, Г. Кашапов Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә читтән

торып укырга керә. Булачак язучы үзенең диплом эшен якташы Хәсән Туфан иҗатын өйрәнүгә багышлый. Эшне яклау чарасында Туфан үзе дә катнаша һәм хезмәттән бик канәгать кала. Шуннан Кашапов татар әдәбиятының классигы белән шагыйрь үлгәнчегә кадәр аралашып яши, тормыш юлын, иҗатын өйрәнә. Аны бигрәк тә дәвер фаҗигаләрен үз җилкәләрендә шактый татыган шагыйрьнең биографиясе кызыксындыра, ул ничек тә булса әдипнең гаепсезлеген, чисталыгын расларга, тормышындагы ачылмаган «ак битләр»не бетерергә тырыша. Х. Туфан үзе дә эчкерсез күңелле, нечкә җанлы яшь якташына битараф булмый, аның белән теләп аралаша, хатлар алыша, тормышын ача.

Язучының Хәсән Туфан образын яктыртуны төп максат итеп куйган «Киек каз юлы» романы ике китаптан торырга тиеш була. Г. Кашаповның әлеге әсәре биографик роман жанры таләпләренә тулысынча туры килә. Язучы төп герое Хизбулланы гаилә, көнкүреш ваклыклары эчендә күрсәтү юлына төшмичә, бер яктан, сабантуйларын, яшен ату кебек табигатьнең иләсләнгән чакларын, ат караклары тормышын, ягъни халыкның яшәеш рәвешен тасвирлауга мөһим өлеш чыгарса, икенчедән, аны татар тарихы борчый, уйландыра (татар халкының Аксубай якларына килеп чыгуы, көчләп чукындыру, янәдән мөселман диненә кайту, азатлык, дин өчен көрәш һ. б.). Татар халкын рәнҗетү, изү, кешегә санамау, киек каз юлы кебек, китап буйлап үтә. Хизбулла-Хәсән образы гына түгел, Шомчы Козгын, булачак шагыйрьнең өлкән абыйсы Сәгыйть, Сираҗетдин хәзрәт кебек геройлары да күңелләрдә уелып кала.

Кызганыч, «Киек каз юлы» романының беренче өлеше – шагыйрьнең балачагын сурәтләгән китабы гына дөнья күрә алды, анысы да язучы үзе вафат булгач дөнья күрде. Г.Кашаповның сирәк дусларыннан берсе булган Аяз Гыйләҗев болай яза: «Газиз Кашаф-Үзиле гомеренең соңгы сулышына кадәр якташы Хәсән Туфанның гыйбрәтле язмышын роман битләрендә күрергә тырышып иҗат итте. Бу әсәр Хәсән Туфанга һәйкәл буласы иде... Ул аның үзенә дә һәйкәл булыр дип кем уйлаган?» (2, 352).

Гомумән алганда, талантлы әдип Газиз Кашапов иҗаты язучының рухи дөньясын, дөньяга карашын чагылдыруда зур роль уйный. Аның хикәя, повесть, романнарында сурәтләнгән катлаулы тормыш вакыйгалары, геройлар аркылы авторның яшәешкә үзенчә мөнәсәбәте чагыла, үзе дә кешеләрне һәм кешелекне яратучы, хөрмәт итүче олы, ихлас, хакыйкатькә тугры шәхес буларак ачыла. Язучы укучыны кызыксындыра белә, үзе артыннан иялтеп, мавыктыргыч, серле әсәр атмосферасына алып керә. Кызганыч, иҗат гомере генә бик кыска булып

кала. Газиз Кашаповның күпсанлы хикәяләрен, соңрак язылган повесть-романнарын, шигъриятен (бигрәк тә мәхәббәт лирикасын), публицистика өлкәсендәге эшчәнлеген өйрәнү – әдәбият белгечләре алдында торган бурычларның берсе.


ӘДӘБИЯТ

1. Әйди Т. Уңышлы әсәр // Мәйдан. – 2002. – № 8. – Б. 205–206.

2. Гыйләҗев А. Йөртә безне язмышлар // Кашаф-Үзиле Г. Киек каз юлы (Туфан). – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – Б. 350–352.

3. Мәһдиев М. Хакыйкатькә тугрылык // Мәйдан. – 2002. – № 8. – Б. 199.



***Р. Н. Сәгъдиева***
***Казан***


## АЛТМЫШЫНЧЫ ЕЛЛАР ТАТАР ШИГЪРИЯТЕНДӘ ЯҢА ТЕНДЕНЦИЯЛӘР

«Хрущев җепшеклеге» дип аталган хәбәрдарлык, демократия күренешләре XX гасырның 60 нчы еллар әдәбият-сәнгатенә уңай йогынты ясый. Язучылар, шагыйрьләр үз фикерләрен әйтеп бирү мөмкинлеген ала. Шушы ук елларда шау-шулы эстрада поэзиясе алга чыга, шигырь сәхнәгә менә, метафора, төсле чагыштырулар күбәя, хисләр ташкыны көчәя.

Әдәби хәрәкәттә, шул исәптән шигъриятә дә, теге яки бу чор аерым иҗатчылар, аерым шәхесләр белән билгеләнә. Әгәр без алтмышынчы еллардан татар поэзиясендә яңарыш, яңа бер сыйфат үзгәрешләре башланды дип әйтәбез икән, бу очракта әлеге процессның төп көчләре, ягъни әйдәп баручылары күз алдына килә. Равил Фәйзуллин – әнә шундый шагыйрьләрнең берсе. Шигъриятебезгә язгы яңарыштай яңа сулыш өргән шагыйрьләр алтмышынчы елларны әдәбиятка тулы бер буын, көчле бер төркем булып килделәр: Ренат Харис, Рөстәм Мингалим, Рәдиф Гатауллин, Гәрәй Рәхим, Рәшит Әхмәтҗанов, бераз соңрак – Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт... Талант дәрәҗәсе, сарыф ителгән көч, хезмәт микъдары һәм, ниһаять, табигый сайланыш нәтиҗәсе буларак, Равил Фәйзуллин хаклы рәвештә бу буынның лидеры дип танылды. Тулы бер әдәби күренеш буларак, «Фәйзуллиннар буыны» дигән төшенчә туды (2).

Бу чор поэзиясе бертөрле генә бәяләнми. Бер яктан, партия, хөкүмәт карарларына, Ленинга мәдхия уку, шәһәрләшүне мактау, татар теленең

кулланылыш мәйданы тараюны күрмәмешкә салыну дәвам итә. Икенче яктан, чын халыкчан шигърият гади кеше мәнфәгатен яклап чыга, татар язмышы өчен борчылып аваз сала.

60 нчы еллар шагыйрьләре, үзләренә абый тиешле Һади Такташ, Сибгат Хәким, Хәсән Туфан, Кави Нәҗмиләр тәҗрибәсенә таянып, вакыйгаларны ил, халык, планета язмышы фонына куеп бәяләргә тырыштылар. Шулай итеп, 60 нчы еллар шигъриятендәге күптөрлелек, күптөслелекнең сәбәпләрен иҗатларның, традицияләрнең баюыннан эзләргә кирәктер. Әлеге буын белән аралашып, кирәк чакта киңәш-сабак алып, бәхәсләшеп яши алдылар. Р. Фәйзуллиннар буыны әдәбиятка килгәндә Х. Туфан әле яңарак сөргеннән кайткан, М. Әмир, И. Газилар эш башында, фронтлар кичкән С. Хәким, Ә. Давыдов, Ш. Мөдәррис, Г. Хуҗилар әдәби хәрәкәтнең алгы сызыгында, талантлары төрле дәрәҗәдә булса да, аларның һәркайсы кабатланмас шәхес иде. Өлкәннәрнең яшәү һәм хезмәт итү рәвешләре, алар тудырган әдәби байлык яшь буынга зур йогынты ясады (4).

60 нчы елларда әдәбиятыбыз ишеген шакыган бу кыю буын – хәзерге татар поэзиясенең әйдәп баручы көче. Алар замана биргән шартлардан тиешенчә файдаланып, 80–90 нчы еллардагы үзгәрешләр турында уйланып, милләт азатлыгын, татар телен, халыкның динен, гореф-гадәтләрен, меңәр еллар сакланып килгән әхлагын саклау өчен дә көрәштеләр (3).

Нәкъ шушы буын үзенең ныклыгы, һөҗүмчән көче, кыю рәвештә экспериментлар үткәрүе белән сугыштан соңгы тыныч, салмак, канәгатьлелек катыш патетика белән бер җайга агып яткан татар поэзиясенә тынгысызлык алып килде, яңалыкка, моңарчы күрелмәгән, кабатланылмаган поэзиягә сусаган яшьләргә үз позициясен, үз шигъри принципларын тага алды, аларны үз артыннан ияртеп алып китте.

60 нчы елларда әдәбият мәйданына килеп, үзенчәлекле шигырь формасы, фәлсәфи эчтәлек белән сулыш өргән шагыйрьләрнең иң беренчесе – Р. Фәйзуллин.

Р. Фәйзуллинның байтак әсәре ак шигырь яки ирекле шигырь белән язылган. Ак шигырь дә, ирекле шигырь дә татар әдәбиятында соңгы елларда юктан бар булган, күктән төшкән нәрсәләр түгел. Ак шигырь бездә Ф. Әмирханның татар хатыны турындагы хикәясеннән, гражданнар сугышы чорында М. Максуд язган нәсерләрдән, Г. Кутуйның Бөек Ватан сугышы дәверендәге иҗатыннан килә. Ирекле шигырьне С. Рәмиевтән, Һ. Такташтан, Ә. Давыдовтан теләсәң күпме табып була. Сүз биредә яңа форма ачу турында түгел, табылган форманың эчке мөмкинлекләрен файдалана

белү хакында гына бара ала. Бу Равил Фәйзуллинның кыю эзләнүләре, яңалыгы булып тора. Аның бөтен иҗаты – укучы белән әңгәмә, кешелек язмышы турында уйлану, күңелендәге хисләре белән уртаклашу. Күп шигырьләре җырга салына. «Аккошлар», «Мин сине ничек яраттым», «Менә без дә үсеп җиттек әни» – әнә шундыйлардан.

Аның мәхәббәт лирикасында да кешелеклелек өстенлек итә. Мәхәббәт турында ул тирән итеп, үз йөрәк кичерешләрен өстәп яза. «Сөйдем аны, шаштым!», «Чакырдың да».

Р. Фәйзуллин иҗатында туган иле, туган халкы, бөек шагыйребез Г. Тукай турында уйланулары тулы бер цикл булып тора. Бу темаларны әдип халыкның фаҗигале тарихы, бөек шәхесләре, бүгенгесе һәм киләчәге, туган тел, табигатьне саклау мәсьәләләре белән бәйләп үстерә (3).

Р. Фәйзуллин поэзиясе, иң беренче нәүбәттә, сугыштан соңгы алтмышынчы елларда – техник революция чорында формалашкан буынның дөньяга карашын, тормышка мөнәсәбәтен, рухи һәм әхлакый эзләнүләрен яңача, заманча чагылдырырга омтылуы белән үзенчәлекле. Шагыйрьнең күпчелек шигырьләре яңа заман кешесенә төбәп языла, интеллектуаль укучыга адреслана. Нечкә тоем, тирән уй, фәлсәфи фикер, гражданлык пафосы – шагыйрь иҗатының төп асылы.

Р. Фәйзуллин шигырьдә кыскалыкка, аз сүзлелеккә омтылучы шагыйрь. Бу юнәлештә ул Шәрыкъ поэзиясендә, бигрәк тә төрки халыклар шигърияттендә борынгыдан килгән чичәнлек традицияләрен уңышлы дәвам иттерә һәм тупланган тәҗрибәне заманча эчтәлек, яңа форма сыйфатлары белән баета бара. Р. Фәйзуллин хәзерге татар поэзиясендә кыска формаларга, әйтик, бер-ике- өчьюллыкларга, тулы гражданлык хокукы бирүчеләрнең берсе. Бүгенге яшь буын шагыйрьләре арасында аның тарафдарлары күп. Ул – бу өлкәдә үз мәктәбен булдырган шагыйрь (5).

Шагыйрь үзенең шигырьләрен психологик халәт, күңел тирбәлешләре, хис һәм фикердәге каршылыклар, көтелмәгән лирик борылышлар нигезенә кора. Аның шагыйрь буларак осталыгы һәм индивидуаль үзенчәлеге нәкъ менә кыска шигъри формага зур тормыш фәлсәфәсе, психологик киеренкелек һәм фикер тыгызлыгы сала белүендә ачыла да инде (6).

Шигырьнең асылы дөньяны яңадан ачу, яңа образлар, яңгыраш-аллитерацияләр, метафораларда чагыла. Әгәр син ачкан яңа тәгъбир, яңа сүз канатлыга әверелеп, кәгазь битеннән халык теленә сикерә икән, шагыйрь бурычы үтәлгән дигән сүз. Р. Фәйзуллин теленнән халык теленә

сикергән тәгъбирләр моны үзе сөйли түгелме? «Башны салларга салып, китәсе иде агып...», «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...», «Ә бит үлеп үлемсезлек яулау – бердәнбер юл түгел тормышта...» һәм башкалар. Милләтенең бөеклеген тумышыннан, ана сөте белән белгән шагыйрь шул ук милләтен вагайткан, кечерәйткән, хәтта хокуксыз иткән сыйфатларын каушау белми утка тотты һәм бу юнәлештә турыдан-туры «таң вакытында йоклаган татар» быргычысы Сәгыйт Рәмигә, Габдулла Тукайга барып тоташты.

«Көзге яңгыр» өчьюллыгы калын әйтелешле сүзләргә нигезләнә, әмма ике җөмләнең тезмә хәбәренә килеп кергән нечкә әйтелешле сүзләр аның яңгырашын үзгәртәләр, шул ук вакытта алар ике мөһим процессны бер-берсе белән тыгыз бәйләнгән эзлекле күренешләрне чагылдырган хәбәрләр булып торалар:

Торналар китеп бара.
Кош канатлары орынгач,
Болытларның күңеле тулды.

Бу кыска гына юлларга нәрсәдер өстәргә, аңлатырга маташу бөтенләй урынсыз эш. Чын сәнгать әсәренең һәр күзәнәге сулый, сиңа ялкын өрә, яндыра башлый. Шагыйрь иҗатына хас булган менә шундый образлылык, сәнгать көченең муллыгы табигый рәвештә шигырьләрнең һәм гомумән Равил Фәйзул-лин поэзиясенең тыгызлыгына китерә.

Күренекле шагыйребез Рәдиф Гаташ та әдәбиятта яңа жанр – газәл жанрын яңарткан әдип. Аның бигрәк тә шигырьнең ритмикасы, строфа төзелеше өлкәсендәге эзләнүләре кызыклы булды. Чордашы Р. Фәйзуллин белән бергә Р.Гаташ та ирекле шигырьнең матур гына үрнәкләрен тудырды (1).

Аның газәлләрен укучыларыбыз бик җылы кабул итте. Аларның һәммәсен диярлек гашыйк булган күңелле лирик герой бергә җыеп тора. Ул шатлана, кайгыра, куана. Әйтерсең һәр газәлдә ул рухи халәтенең бер мизгелен сөйгәненә, тирә-юньгә сөйләп бирә.

Сары яфрак – моңлы хатыдыр көзнең,
Ул – хәбәрдер... Җил, яфракны ник өздең?

Лирик герой үзенчә фикерли, үзенчә сөя, сөелә. Шагыйрь «кульяулык» кебек милли детальләрне, Хәлил, Галиябану кебек чын татар персонажларын да кертеп җибәрә.

... Нәкъ Хәлил без, алдык вәгъдә билгесе...
Галиябану өчен җанны кызганмыйк!

...Яшәү матур, Гаташ, гөлләр – мәңге яшь, –
Кулда бит Сөю әләмең – кульяулык!..

Р. Гаташ үзенә кадәрге рухи казанышларга нык таяна, аларны иҗади файдалана белә.

Әлеге агымның тагын бер күренекле вәкиле, үзенчә язу стилен булдырырга тырышкан, моңсу табигатьле, философ шагыйрь – Ренат Харис.

Ул – көтелмәгән алымнар, кыю метафоралар шагыйре. Борылышлар, ачык һәм төгәл, вакыты белән катлаулы чагыштырулар кулланып яза ул. Шигырьләрендәге сүзләр, метафоралар, сурәтләр һәрберсе үз урынында, аларны үзгәртеп тә, алыштырып та булмый. Аның шигърияте юморга, хәтта сатирага бай.

Ренат Харис – элеккеге рухи казанышлар белән таныш әдип, дөньякүләм фәлсәфи нәтиҗәләр ясый белүче шагыйрь. Туып-үскән җир, аның үткәне, киләчәге Р. Харис поэзиясенең үзәгендә тора. «Сабантуй», «Чулпы», «Ак сөлге» шигырьләрендә ул татар халкының милли йолалары, гореф-гадәтләре турында уйлана.

Син бит үзең дә халкымның
Күңеле төсле –
Сөттән сеңгән зур пакьлекнең
Бер көзгесе.
(«Ак сөлге»)

Р. Харисның остазлары турында уйланып, С. Хәким болай ди: «Мин яшь шагыйрьнең фикерләвен, шигырьдә эзләнүләрен Дәрдемәндчә-үзенчә дияр идем». Өлкән шагыйрьнең егерменче йөз башы татар поэзиясенең күренекле вәкиле Дәрдемәндне искә алуы очраклы хәл түгел. Озак еллар дәвамында тыелып, шигырь китаплары күптән түгел генә яңадан халыкка кайткан Дәрдемәнд алтмышынчы елларда, иҗатка килгән шагыйрьләрнең сурәтле фикерләвенә, шул исәптән, Р. Харис иҗатына, тирән тәэсир ясый. 1968 елда ул Дәрдемәнд шигъриятенең мотив-символларына, шигъри ачышларына таянып, «Дәрдемәндкә нәзыйрә» исемле 14 шигырьне эченә алган цикл иҗат итә. Р. Харис бер очракта Дәрдемәнд әсәрләренең исемнәрен үк саклаcа («Сыгылдырып күл камышын...», «Табып ләззәт»), күпчелек шигырьләрендә остазының сурәтлелек байлыгына, аң төпкеленә үтеп керү алымнарына, шигырь төзелешенә алып кергән үзенчәлекләренә таяна. Әмма ике чор шагыйрьләре арасында тышкы, шәкли охшашлык саклanса да, 60 нчы еллар сүз остасы шигыренә, замана алып килгән яңа эчтәлек, үзгәрәк әхлак кануны сала (3).

«Табып ләззәт» шигырендә Дәрдемәнд лирик затның матурлыкка сусавын, пакьлек эзләвен үзәккә алса, Р. Харис гомерен заяга сарыф итүченең киләчәк фаҗигасен искәртә.

Табып ләззәт уенда һәм куенда,
Калды ул гомер елгасы буенда.
Тарих ансыз китте.
(«Табып ләззәт»)

Дәрдемәндтән шигъри осталык дәресләре алса, Р. Харис шул чорда ук үзе өчен икенче әхлакый, мәгънәви сыену үзәге таба. Анысы ислам динен тотучыларның изге китабы – Коръән. «Коръән сүрәләренә нәзыйрә» дип аталган, берничә шигырьгә «Хәбәр» сүрәсеннән юллама-эпиграфлар алынган бу бәйләмдә автор ирләр («Ирләр»), хатыннар («Хатыннар»), аларның җир йөзендәге нәсел калдыру, тынычлык саклау кебек вазифалары турында уйлана. «Пакьләнү» шигырендә кешеләргә күңелне тазарту, чистарыну юлларын күрсәтә.

Кулны, битне су белән юып була...
Ә күңелне –
Туфрак белән генә...
(«Пакьләнү»)

Күргәнебезчә, «Фәйзуллиннар буыны» шигърияттә сынатмады. Безнең бай тарихлы поэзиядә һәрберсенең алыштырып булмаслык лаеклы үз урыны бар.

ӘДӘБИЯТ

1. Гаташ Р. К. Сайланма әсәрләр: 3 томда: 1 том. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 5–7 б.

2. Равил Фәйзуллин: Заман. Иҗат. Шәхес. – Казан: Мәгариф, 2002. – 20–21б., 62–63 б., 161–162 б.

3. Ренат Харис һәм татар шигърияте: Татарстанның халык шагыйре Ренат Хариска 70 яшь тулуга багышланган Россиякүләм фәнни-гамәли конференция материаллары (Казан, 21 апрель, 2011 ел). – Казан: «Идел-Пресс», 2011. – 12 б., 307–309 б.

4. Татар әдәбияты тарихы: 6 томда: 6 том: 60–90 нчы еллар әдәбияты. – Казан: «Раннур», 2001. – 332–333 б.

5. Хуҗина М. К. Равил Фәйзуллинның шигъри дөньясы.– Казан: «Сүз» нәшрияты. – 2011. – 26 б., 42–43 б.

6. Әдипләребез: библиографик белешмәлек: 2 томда: 2 том / төз: Р. Н. Даутов, Р. Н. Рахмани. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2009. – 491–492 б.

*Р. М. Фәхретдинова*
*Казан*

# Ф. БӘЙРӘМОВА ПРОЗАСЫНЫҢ ЧИТ ИЛ ӘДӘБИЯТЛАРЫ БЕЛӘН ҮЗАРА БӘЙЛӘНЕШЕ
## («Канатсыз акчарлаклар» повесте мисалында)

М. Бахтинның диалог концепциясенә ярашлы буларак, шәхесләрнең сөйләшүе аралашуның атомы – текст – ярдәмендә бара. М. М. Бахтин үзенең «Сүз иҗаты эстетикасы» («Эстетика словесного творчества») хезмәтендә кешене аның тарафыннан тудырылган яки тудырылачак текстлар аша гына өйрәнеп була дип яза. Шуңа күрә, текст төрле формаларда күрсәтелергә мөмкин: кешенең тере сөйләме буларак, кәгазьдә яки башка бер яссылыкта гәүдәләндерелгән сөйләм буларак, нинди булса да билге системасы (иконографик, әйбергә ия булган, хезмәт һәм башка). Шушы формаларның һәрберсендә текст мәдәниятләрнең аралашуы буларак кабул ителергә хаклы. Һәр текст дөньяны танып-белүгә, үз дөнья сурәтенә ия авторлар тарафыннан иҗат ителгән алда килгән һәм булачак текстларга таяна. В. С. Библер ассызыклаганча: «текст үткән һәм киләчәк мәдәниятләрнең әһәмиятен үзендә чагылдыра, ул һәрвакыт чиктә, ул икенче бер текстка юнәлтелгән булу сәбәпле һәрвакыт диалогка бара» (1, 213). Текстның бу үзенчәлеге аның контекст чолганышында булуына ишарәли. Бу үзенчәлек текстны әдәби әсәр итә. Әсәрдә адресат булган шартта гына мәгънәгә ия авторның тулысынча булмышы гәүдәләнеш таба. Әдәби әсәрләр киң куллану товарларыннан, әйберләрдән, хезмәт коралларыннан аларда кешенең булмышы һәм асылы чагылу белән аерылып тора. В. С. Библер концепциясе буенча, «текстның икенче үзенчәлеген аның төрле вакытта барлыкка килүе һәм бер-берсеннән ерак урнашкан укучы һәм авторның аралашуы барганда гына мәгънәгә ия булуы тәшкил итә. Һәм бу аралашуда әсәрләр аша беренче тапкыр дөнья барлыкка китерелә һәм төзелә. Әсәр булып җитешкән текст «контекстлар ярдәмендә яши», һәм аның барлык эчтәлеге аңарда, һәм аның барлык эчтәлеге – аңардан тыш, бары тик аның чикләрендә, яшәешнең юклыгы буларак текстта» (2, 26).

Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» повесте, Д. Дидроның «Монахиня», Ж. Перекның «Әйберләр» романнары арасында әдәбиятлар диалогын билгелибез. Әгәр схематик күрсәтергә теләсәк, аларны (әсәрләр арасындагы бәйләнешләрне) өчпочмак рәвешендә тәкъдим итү уңышлы булачак. Өске өлештә без Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар»

повестен урнаштырабыз. Аңардан ике якка уклар җибәрелә. Бер якка Д. Дидроның «Монахиня» романын куябыз, икенче якка – Ж. Перекның «Әйберләр» романын. Әдәбият галиме Д. Заһидуллина ассызыклаганча: ««Канатсыз акчарлаклар» әсәрендә текст үзе яшәеш кануннарын аңлатучы изге китап ролен үти» (4, 98). Бу әсәрләрне төрле аспекттан чыгып чагыштырып була: Ф. Бәйрәмова белән Д. Дидро әсәрләрендә ялгызлык, җәмгыять тарафыннан читкә тибәрелү, кире кагылу мәсьәләсе күтәрелә. Әгәр игътибар итсәк, «Канатсыз акчарлаклар»дагы бүтәннәргә охшамаган мәхәббәт эзләүче хатын Ф. Бәйрәмованың алдарак язылган әсәрләренең геройларын – Алсуны, Рәшидәне, кызсыман балыкны хәтерләтә. «Монахиня»дагы Сюзанна да үзенең бунтарь характеры белән бу хатынга якын тора. Ул җәмгыять тарафыннан кыерсытылган образ: монастырьга Сюзанна проблемалардан качар өчен китә. Гадәти тормышта ул үзен ирексез итеп тоя. Ләкин монастырьда да төп герой тынычлану тапмый, ә киресенчә, гаделсезлеккә һәм әхлаксызлыкка юлыгып, биредән качарга мәҗбүр була. Сюзаннаның качуы безнең өчен кызыклы: ул үзенең бу гамәле белән җәмгыятькә каршы чыга. Ф. Бәйрәмованың герое да яшәп килгән кануннарны кабул итә алмый. Аның да өйдән китүе качуга тиң. Шуны да билгеләргә кирәк: «Канатсыз акчарлаклар» – фәлсәфи әсәр. Биредә төп герой җәмгыять, анда яшәп килгән кагыйдәләр белән генә каршылыкка керми, ә каршылык шулай ук аның үз эчендә бара. Бу хакта хатынның күргән төшләре, эчке монологлары сөйли.

Перекның «Әйберләр» романы белән параллель үткәргән вакытта без авторлар тарафыннан барлыкка китерелгән тормыш модельләре хакында әйтергә тиешбез. Әлбәттә, алар төрле. Ләкин бу төрлелек безгә әсәрләрне чагыштырып карарга комачауламый. Ул модельләрнең авторлар тарафыннан әсәр тукымасына кертелүе мөһим фикерне бирергә ярдәм итә.

Д. Заһидуллина Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар»ы буенча түбәндәгене ассызыклый: «Яшәешнең яңа мифологик моделе төзелә, моңа кадәр билгеле булган мифологик мәгълүмат-модель юкка чыгарыла» (4, 98). Язучы җир һәм галәм тормышы, яшәеш хакында үзенчәлекле миф тәкъдим итә, кешеләр җәмгыятендәге төрлелекне аңлата торган модель кора. Әсәрдә бик борынгы заманнарда, кешеләр кыргый булган чакта, җиргә махсус җибәрелгән җанияләренең төшүе әйтелә. Аларның кешеләргә сиздермичә генә ярдәм итүләре искәртелә. Күп еллар үткәч, бу җан ияләре белән бергә кешеләр дә яши башлый. Алар «артык гади яши», аларда «хыял да юк, талпыну да, уйлану да» (3, 23).

Әсәрдә тагын бер шартлы символик образ – йорт бар. Бу шулай ук авторның табышы. Яшәп килгән системаның, халык өстеннән хакимлек итүнең моделе булган җиде катлы йорт – җүләрләр йорты – җәмгыятьтәге тәртипләргә тәнкыйди бәя булып аңлашыла. Бу йорт – автор уйдырмасы гына түгел, 70 ел торгынлык чорының чагылышы, ягъни моделе. Аңнары тоныкланган гади халыкны һәм «өстәге»ләрне язучы бик дөрес итеп сурәтли. Һәрнәрсәне якты киләчәк хакына башкару һәм шул киләчәк турында гына сөйләү һәм хыяллану, йортның беренче катта яшәүчеләрнең авыр мескен тормышы («аста, пычрак эчендә, гавам таптана») (3, 267), каттан катка күтәрелү күренеше, югарыдагыларның түбәндәгеләрне ишетмәве, буйсынмаучы һәм икенче төрле фикерләүчеләрне юк итү кебек сыйфатлар – мөһим күрсәткечләр. Ф. Бәйрәмовада ирреаль дөнья күбрәк яктыртыла. Автор Җир кешеләре белән Күктән төшүчеләрне чагыштырып, аларның яшәү максатларының, теләк-омтылышларының капма-каршы булуын ассызыклый.

Ж. Перекның «Әйберләр» әсәрендә шулай ук тормыш моделе күрсәтелә. Ул бары тик икенче төрле ысуллар ярдәмендә тормышка ашырыла. Автор биредә «интеллегенция»гә караган яшь парның тормышын, язмышын, эчке дөньясын социологик яктан сурәтләргә омтыла. Роман Жером белән Сильвия тарафыннан күз алдына китерелгән фатирны тасвирлаудан башлана. Аларның хыялындагы фатирда бар да алдан уйланып куелган – бүлмәләрнең урнашуы, агачның фактурасы, диван артының бөгелеше һ. б. Шарт фигыльләрне куллану актив эшчәнлекнең булмавы хакында сөйли. Ә исемнәрне автор текстка мул итеп кертә: «нефрит төпчек савыты», «киң бакыр башлы өч кадак», «көмеш кесә сәгате», «өч яктан да бакыр сызык белән инкрустацияләнгән туалет өстәле» (5, 271) – боларның барысы да безне хыяллар «структур» (6, 192) булган дөньяга алып керәләр. Биредә «тормыш аморф халәттә» (6, 192). Әдәбият галиме Л. Зонина язучыга карата мондый сүзләр әйтә: «Перек – мифолог (биредә без Ф. Бәйрәмова белән охшашлыкны күрәбез – *Р. Ф.*), ул бәхетнең якын булу тойгысы тоткынлыгындагы вак буржуаның буталган аңын өйрәнә. Бәхет байлык һәм муллык итеп аңланыла» (6, 192). Төп геройлар – Жером һәм Сильвия – цивилизациянең муллык тоткынлыгында яшиләр. Буржуаның көнкүреш моделе урта сыйныф вәкиле кешесе өчен – хыял моделе. Шуңа күрә дә инде идеаль тормышны сурәтләгән картинада да эш-хәрәкәт юк. Биредә әйберләр хаким итә. Алар матурлар, затлылар. Алар «индивидуаль» (6, 192), алар «реаль» (6, 192). Ә Жером белән Сильвиянең яшәве иллюзия дәрәҗәсендә, шартлы. Ләкин ни өчен кирәк соң бу муллык? Ул чагында «тормыш гадирәк булыр иде, җиңелрәк

булыр иде» (5, 222). Әйберләрдән эшне яки хәрәкәтне сурәтләүгә күчкәч, конкретлык юкка чыга, гомум сүзләр барлыкка килә: «Алар бик озак эшләячәкләр, нервозсыз һәм ашыкмыйча, үзләрен бетермичә. Аннан соң алар төшке ашны ашаячаклар – өйдә яки ресторанда, аннан соң танышлары белән очрашачаклар, алар белән вакыт үткәрәчәкләр» (5, 230). Алар нәрсә эшләрләр иде? Ни өчен? Моңа җавап биреп булмый. Чөнки алар чынбарлыкта тормышка ашмас максатлар белән яшиләр.

Икенче бүлектә Ж.Перек кисәк кенә хыялдан чынбарлыкта булганга күчә. Биредә Жером белән Сильвия хакында сүз бара. Алар төрле реклама агентлыклары өчен халыктан иҗтимагый сорау алу белән шөгыльләнәләр, ягъни җәмгыятьнең зәвыгын тикшерәләр. Ә үзләренең ихтыяҗлары исә шулай ук кинофильмнар, «Экспресс», «сары» пресса нигезендә төзелгән. Безнең алда үз ихтыяҗын гына канәгатьләндерүгә караган җәмгыять. Автор безгә 1960 нчы еллардагы Көнбатыш Европа илләренә хас ситуацияне сурәтли. Сильвия белән Жером – типик характерлар. Авторның романында герой, индивид юкка чыга. Ж. Перек геройлары турында «алар» алмашлыгы ярдәмендә генә бәян итә. Шулай итеп, ул иҗтимагый башлангычка басым ясый, ә психологик башлангыч тоныкланып кала. Ф. Бәйрәмова да әсәренең бүлекләрен алмашлыклар белән атый: «Ул», «Алар», «Мин», «Монда», «Без». Бу шулай ук тормыш моделен бирергә ярдәм итә.

Шулай итеп, Ф. Бәйрәмованың «Канатсыз акчарлаклар» повесте белән Д. Дидроның «Монахиня» һәм Ж. Перекның «Әйберләр» романнары арасында бик кызыклы бәйләнешләрнең булуын ассызыклый алабыз. Без ялгызлык, читләшү мотивларының әсәрләр тукымасында төп урынны алып торуларын һәм бик кызыклы тормыш модельләренең бирелүен билгелибез. Беренче карашка бу бәйләнешләр күренми дә кебек, алар «әсәр тукымасында эреп югалалар». Шуңа да басым ясарга кирәк: татар милләте белән Көнбатыш Европа халкының ике төрле үзаң, алар ике төрле мәдәни үсеш юлын үткәннәр. Ләкин шулай да бу әсәрләр арасында бик кызыклы бәйләнешләр күзәтелә.

## ӘДӘБИЯТ

1. Библер В. С. М. М. Бахтин // Поэтика и культура. – М.: Прогресс, 1991. – 176 с.

2. Библер В. С. От наукоучения к логике // Два философских введения двадцать первый век. – М.: Полиздат, 1990. – 413 с.

3. Бәйрәмова Ф. Күңел карлыгачларым: Повестьлар. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.

4. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

5. Веркор и Коронель, Перек Ж., Кюртис Ж.-Л., Ремакль А. Французские повести: Пер. с фр. / Сост. и вступ. ст. Ю. П. Уварова; Ил. В. Л. Гальдяева. М.: Правда, 1984. – 640 с.

6. Зонина Л. Потребительство – канонизация и развенчание // Критика. – 1992. – № 3. – 187–193 с.

***Б. Ю. Хайрутдинов***
***Казань***

# НОВОМЕТОДНЫЕ ПРЕОБРАЗОВАНИЯ В ТАТАРСКОМ СОЦИУМЕ И ЛИБЕРАЛЬНО-БУРЖУАЗНАЯ ПЕЧАТЬ

Начавшиеся в конце XIX века процессы интенсивного развития капитализма, индустриализации жизни Российской империи, обострения социальных и национальных противоречий привели к возрастанию роли периодической печати в идейно-политической борьбе, экономической, научной и культурной жизни. Те же самые сдвиги в обществе форсировали оформление политических направлений, пребывавших до этого в эмбриональном состоянии. На начало нового – XX – века приходится организационное сплочение партии либеральной буржуазии. В 1902 г. появилось первое издание кадетского толка – им стала либерально-буржуазная газета «Гласность», вышедшая в Санкт-Петербурге. С 1903 г. она стала выпускаться под названием «Русь». Либерально-буржуазные взгляды выражали также газеты «Русские ведомости», «Курьер», «Биржевые ведомости», «Россия», «Новости», журналы «Русское богатство» и «Вестник Европы». Лейтмотив всех этих изданий наиболее отчетливо прозвучал со страниц именно последнего журнала: его редакция в первом номере 1901 года, посвященном, что символично, наступлению XX столетия, констатировала, что большинство цивилизованных стран живет в условиях торжества капитализма и буржуазной демократии, а в России дело реформ так и не было доведено до конца. От имени либеральной общественности журнал перечислял задачи, которые требовалось решить России в XX веке: уничтожение сословного неравноправия, введение независимого от администрации суда, развитие самоуправления, юридическое облегчение положения печати, развитие частных обществ, свобода совести, введение всеобщего начального образования,

упорядочение крестьянского, земского, судебного, промышленного, брачного и других законодательств. Впрочем, у журнала не было уверенности, что в современных ему условиях возможно скорое решение этих задач (2). Не будем забывать, что робкие демократические преобразования в России начались лишь после революции 1905 года.

Что касается татарского общества, то к началу интересующего нас периода известные кадимистские образовательные центры, располагавшиеся в селах Кышкар, Мечкера, Сатыш, Саба (Казанская губерния), Тунтер (Вятская губерния), Стерлибаш, Стерлитамак (Уфимская губерния), уже не могли конкурировать с городскими джадидистскими медресе по качеству предлагаемого образования, в то время как новометодные школы, открывавшиеся в деревнях, значительно уступали по степени своей популярности старым учебным заведениям. Тормозила распространение на селе новой идеологии и агрессивность приверженцев традиционного образования, нашедшая выражение в давлении на преподавателей-реформаторов – экономическом, моральном и зачастую физическом (попросту говоря, недругов избивали). Немалую роль в вышеописанных процессах сыграло и то, что в земствах Казанской губернии состояло лишь незначительное количество татар: в иных губерниях земства со значительным числом членов-татар активно поддерживали распространение светского образования на селе, вкладывали достаточные средства в рост культурно-образовательного уровня деревенских жителей.

Вышеизложенный программный материал, достаточно полно характеризующий надежды и чаяния русской либерально-буржуазной прессы, нашел отражение и на страницах татарских газет и журналов схожей направленности, которые доминировали на рынке периодической печати начала XX столетия по вполне объяснимым причинам: многовековая колониальная политика царизма естественным образом формировала весьма настороженное отношение широких слоев татарского общества к престолу, поэтому промонархическая периодика не могла найти своего читателя и, соответственно, получить сколь-либо значительное развитие; радикально-социалистические издания были не в состоянии противостоять административно-полицейскому давлению; лишь либерально-буржуазная печать могла эффективно функционировать в социально-политических условиях 1905–1917 годов. Именно последняя стала рупором джадидских преобразований: отметим, что джадидизм в советской исторической науке не без оснований толковался как «буржуазно-либеральное, националистическое движение,

зародившееся в 80-х гг. XIX в. среди татарской буржуазии в Крыму и Поволжье, в Азербайджане, а с 90-х гг. XIX в. распространившееся в Средней Азии. Первоначально — узкое, культурническое движение за реформу старой системы мусульманского образования (обучение грамоте путём зазубривания отдельных сур Корана), за необходимость европейского образования для мусульман. В новометодных школах детей обучали по новому для мусульман звуковому методу. В Средней Азии в период Революции 1905–07 и в последующие годы джадидизм вышел из первоначальных культурнических рамок и приобрёл ярко выраженную окраску буржуазно-либерального, контрреволюционного политического движения и идеологического течения. Социальной базой джадидизма были преимущественно буржуазные слои населения. Джадидами называли тех, кто высказывался за необходимость ликвидации некоторых феодальных пережитков, стеснительных для нарождающейся буржуазии, за ограниченную реформу ислама и религиозных школ, за приспособление ислама к буржуазному развитию национальных окраин Российской империи и потребностям национальной буржуазии» (5). Джадиды критиковали религ. фанатизм, требовали замены устаревших религ. школ нац. светскими, ратовали за развитие науки и культуры, выступали за издание газет на родном яз., за открытие культурно-просветит. учреждений, что способствовало сплочению демократических сил общества (3). Со временем термин «джадидизм» начал толковаться более широко, что нашло отражение и на страницах печати начала XX века: джадидизм стали связывать с заимствованием технических достижений европейской науки, приобщением к общемировым ценностями культуры. Джадиды стали восприниматься как сторонники всего нового, прогрессивно в культуре и в общественной жизни татарского народа (4, 142). Требования преобразований, выдвинутые джадидами, затрагивали области и социально-экономических, и семейно-бытовых, и культурно-идеологических отношений (1, 3).

Джадидизм, зародившись как явление городской культуры, в конце XIX – начале XX веков начал проникать и в деревню в виде новометодных мектебе и медресе. Однако процесс этот был достаточно сложным, особенно в деревнях Казанской губернии.

ЛИТЕРАТУРА

1. Абдуллин Я. Г. Джадидизм среди татар: возникновение, развитие и историческое место. – Казан: Иман, 1998.

2. Вестник Европы. – 1901. – № 1.

3. Вильданов А. Х., Фархшатов М. Н. Джадидизм. – Режим доступа: http://www.bashedu.ru/encikl/ddd/djadid.htm

4. Ибрагимов Т. К. Татарская религиозно-философская мысль в общемусульманском контексте / Т. К. Ибрагимов, Ф. М. Султанов, А. Н. Юзеев. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002.

5. Пясковский А. В. Джадидизм. – Режим доступа: http: // www.booksite.ru / fulltext /1/001/008/025/194.

***А. Ф. Хәбибуллина***
***Лениногорск районы***

## КЕШЕНЕ ЯРАТУ ХИСЕ – КАДЕРЕ ҖУЕЛМАС ТАЛИСМАН

Марсель Галиев – күпкырлы талантлы язучы. Аның каләме бигрәк тә публицистика өлкәсендә чарланган. Язучының «Догалы еллар», «Рух» кебек китаплары шуның ачык мисалы.

Әлеге публицистик әсәрләр укучыны әдәби портретларның зиннәтле бирелеше, табигатьнең гүзәл сурәтләнеше, бай һәм зәвыклы теле белән җәлеп итә.

2010 елда М. Галиевның «Талисман» исемле китабы дөнья күрде. Китапта язучының соңгы егерме елда иҗат иткән публицистик язмалары урын алган. Алар тема ягыннан да, жанр ягыннан да төрле: монда олуг шәхесләр хакындагы әдәби портретлар, интервьюлар, әдәбият-сәнгать даирәсеннән чыгып уйланулар, авыл язмышы, игенчеләр хакындагы очерклар, тарихыбызга, сәнгатебезгә, халык язмышына караган фәлсәфи язмалар урын алган.

Китап «Гомер учаклары − аягүрә» бүлеге белән башланып китә. «Кешене ярату хисе Раббыдан бирелгән икән – ул инде күңел күгенә чигелгән, кадере җуелмас Талисман. Гомерем буена әнә шул Талисман минем күкрәгемне җылытып, рухымны саклап, язмышымны баетып бара» (1, 6), − дип, М. Галиев китапның беренче бүлегеннән үк җыентыкның төп фикерен җиткерә.

Китапның эчтәлегенә, фәлсәфәсенә яңгырашлы шигырь юллары да шушы бүлектә:

Сүз тылсымы белән сурәт үрдем,
Күңел диварына эләр идем;
Мин бит сезне шундый яраткanмын,
Шөкер, бар да исән, дияр идем!..

Их... их... дигән үкенечләр кала,
Тигез бармый гомер көймәләре.
Саклап булмый, еллар җебе өзә,
Учта – бик аз дисбе төймәләре.

Китап чын шәхесләр – халкыбызның күренекле ул һәм кызлары турында. Алар арасында Хәйдәр Бигичев, Миргазиян Юныс, Газинур Морат, Шәйхи Маннур, Фирдәвес Әхтәмова, Нәҗибә Ихсанова, Вахит Имамов, Ркаил Зәйдулла, Айрат Арсланов һ.б. бар.

Китап белән танышып чыкканнан соң, Адлер Тимергалинның М. Галиев турында әйткән: «...күркәм әдәби портретлар галереясын тудырырлык, аларга җан өрерлек кешебез (рух!)» (2, 16), − дигән сүзләре белән берсүзсез килешәсең. Әсәрләрендәге искиткеч төгәл һәм оста портретлар тууының серен язучы үзе: «Ә син кешегә карамыйча күрә бел – бөтен хикмәт тә шунда» (1, 263), − дип аңлата.

Китапта М. Галиев бигрәк тә Нәкый Исәнбәт, Айрат Арсланов һәм Эльс Гаделевларның әдәби портретларын аеруча яратып, хәтта сокланып сурәтли. «Җир читен күреп, аягын салындырып утыра алган иргетебез» Миргазиян Юныснның әдәби портреты «Талисман»да түбәндәгечә бирелә: «Кыяфәт – шәп. Чын тукымадан тегелгәнлеге сизелеп торган банан чалбар, илле кесәле, җитмеш җиде молнияле авангард модалы куртка кигән, аягында – “Пума” кроссовкасы. Җиңел-озын гәүдәле Миргазиян ага, елмаеп, аякларын аерыбрак басып тора. Аның өчен бу җир дә гел чайкалырга торган палуба шикелледер. Елмаюында – әдәбият җене кагылган безләрне дә, туган телебез аһәңнәрен сагыну да, диңгезсез ничек яшисез сез, дигән кызгану да, их, урындыкларыннан кубарып алып, олы дөньялар гиздерсәң, кем генә чыкмас иде бу егетләрдән, дигән нәүмиз хыял да бар сыман» (1, 8).

Нәкый аганы язучы, бик лаеклы, «гасыр улы» дип атый. Шунда ук үзенең борчу-соравын да бирә: «...яңа гасырда халкыбыз Нәкый ага Исәнбәт кебек мәртәбәле шәхесне дөньяга бирә алырмы?!» (1, 121). Китаптагы түбәндәге юлларда гасыр улының милләтебез өчен үзен аямыйча хезмәт итүе тасвирлана: «Нәкый ага үзе бер академия иде... Нәкый ага Исәнбәтнең титаник хезмәтләре каршында акыл чарасыз кала. Тормышның кызыктыргыч якларыннан үзен мәхрүм итеп, яшәү рәвешен тоташ хезмәткә әйләндергән, үзен киләчәк әсирлегенә дучар иткән бу гали җанның асыл мәгънәсенә төшенү, аны бәһаләү өчен әле заман әзер дә түгел...» (1, 121). Әлеге олпат шәхескә чиксез ихтирамын, соклануын белдереп, М. Галиев язмасын 1985 елда иҗат иткән «Исәнбәт тәрәзәсе» исемле шигыре белән тәмамлый:

Йокламый, бер ул йокламый,
Булсынга дип, булсынга.
Ап-ак чәчле Вакыт булып
Иелгән дөньясына.

Таң беленә. Ә ул уяу –
Чал чәчле күрәзәче.
Соңгы йолдыз кебек якты
Исәнбәт тәрәзәсе.

«...горур кыяфәт, текә маңгай. Башын артка чөебрәк йөрүендә үз бәһасен белүе, буйсынмас-үҗәт рух ныклыгы сизелеп тора иде. Мәһабәтлек чалымнарын Ходай аның бөтен буй-сынына тигез тараткан... Ә тавышы... Хәйдәрнең тавышы – Ходайның табышы булгандыр...

... Тавышында – дала киңлеге, күкләр аязлыгы, агымсу борылышлары, тау кәрваны каймалаган рәшәле офыклар...» (1, 24), − дип яза М. Галиев «Тавышында – дала киңлеге» эссесында Хәйдәр Бигичев турында.

«Могтәбәр замандашыбыз» язмасының герое – Айрат Арсланов. Язучы бу олпат шәхесне табыну дәрәҗәсендә хөрмәт итә: «Ул – татар зыялысы менә нинди була дип, Парижларда йөртерлек мәһабәт ир-егет.

Ул – телебезнең бай аһәңен бүтән милләт кешеләренә дә җиткерә алу осталыгына ия.

Ул – тышкы кыяфәт, гәүдә тотышы, эчке мәдәнилеге, зыялылыгы, кылган эше белән егерменче гасыр татар шәхесе дигән титулга ирешә.

Ул – могтәбәр замандашыбыз Айрат Арсланов!» (1, 134).

Шунысы да игътибарга лаек, «Талисман»да әдип күренекле хатын-кызларыбызның әдәби портретларын сурәтләүгә дә зур урын бирә. Бередә милләтебезнең асыл кызлары – Фирдәвес Әхтәмова, Нәҗибә Ихсанова, Алсу Гайнуллина, Вафирә Гыйззәтуллиналар белән очрашасың.

«Бибидән − Бибинургача» бүлегендә Г. Камал театры артисткасы Фирдәвес ханым Әхтәмованың әдәби портреты бирелгән: «Менә ул Фирдәвес ханым: җил белән узышып йөри торган җиңел гәүдәле, хәрәкәтләре ыспай, сыгылмалы; артистларга гына хас нәзакәтлелек – сүз сөрешендә, күз карашында һәм... без белгән сәхнә гомере агышында» (1, 6).

«Яланаяклы кыз бала»ның героинясы – яраткан артисткабыз Нәҗибә Ихсанова: «Ул – гаделсезлекне өнәми торган сагаюлы-эчкерсез карашлы. Самими беркатлылыгын яшерәсе килгәнгә, тыштан кырыс күренә.

Йөз-кыяфәте, холык-фигыленнән шуны чамалыйм: борынгы бабалары кыя таулы, япан чүлле, динле-дастанлы Шәрыкъ илләреннән кузгалып, бөек ефәк юлыннан бу яклара килеп тамырланган булырга тиеш» (1, 67) һ. б.

Язучының сурәтләү палитрасы да искиткеч бай. «Бәрхет тавышлы, инсанлы шәхес» – Эльс Гаделев, «кырыслыкны яраткан карт» – Шәйхи Маннур, «табигате белән горур ханым» – Нәҗибә Ихсанова, «җил белән узышып йөри торан җиңел гәүдәле» – Фирдәвес Әхтәмова, «дөньяга акыл, аң-белем таратучы мәһабәт кораб капитаны» – Ислам Әхмәтҗанов, «сулышына кабып ашарга яраткан» – Рафаэль Сәхәбиев, «гади урындыкны да тәхет биеклегенә менгерә ала торган эшчән затыбыздан» – Хәлим Гайнуллин, «шигъри чишмәсенә кәүсәр суы эзләп, энә белән кое казып төшкән шәхесебез» – Марсель Бакиров һ. б.

Китапның «Изүе ачык еллар» бүлегендә М. Галиевның күренекле шәхесләр: язучылар (А. Гыйләҗев, Ә. Еники, Н. Гыйматдинова һ. б.), драматурглар (Т. Миңнуллин), җырчылар (В. Гыйззәтуллина), галимнәр (Т. Галиуллин, М. Госманов), шагыйрьләр (Р. Вәлиев, Н. Нәҗми һ. б), дәүләт эшлеклеләре (Ф. Мөхәммәтшин) белән әңгәмәләре урын алган. Әлеге бүлекнең язмаларын тоташтыручы үзәк булып милләт темасы тора. Аларда татарларның тарихы, бүгенгесе, киләчәге; гореф-гадәтләребез, телебез, милләтебез турында бүген дә актуаль булган мәсьәләләр күтәрелгән. «Татар исеме – егәрле, эчендә дәһшәтле горурлык яткан яңгыравыклы сүз. Әгәр йомык, мескен авазлардан торса, тарих бу исемне күптән оныткан булыр иде. Ә ул, гасырлардан гасырларга яңгырап, көчен җуймыйча тантана итә... әгәр инде «мин татар!» дип күкрәк сугып горурлана алмыйсың икән − яшәмә!» (1, 267) − дип, язучы һәр татар кешесен милләте белән горурланырга өнди.

«Уйлы җилләр язмыш ярында» бүлегендә М. Галиев Туган ягына, газиз халкына, игенчеләргә мәдхия укый. «Туган ягым – Идел-йортның кояш чыгышы тарафында, чал Уралның соңгы дулкыннары кучкар-кучкар таулар хасил иткән манзаралы як булыр, һәр авазы табигый чиратлашып килгән *А-з-н-а-к-а-й* дигән тылсымлы аһәңгә тургайлы тугайлар киңлеге дә, тутлы каенлыкларның тымызык ак төннәре дә, бөгелә-бөгелә аккан елгалары да, шушында гомер сөргән кешеләрнең тулган ай кебек гаделнурлы карашлары да сыйган» (1, 443), − дигән юллар аша әдип үзенең Туган җиренә – Азнакай төбәгенә чиксез мәхәббәтен белдерә.

«Талисман» укучыны әдәби портретларның зиннәтле бирелеше, табигатьнең гүзәл сурәтләнеше белән генә түгел, бай һәм зәвыклы теле белән дә җәлеп итә.

Марсель Галиев үзенең «Талисман» китабы белән янәдән татар мемуар жанрын күркәм эсселары белән баетты.

ӘДӘБИЯТ

1. Талисман: публицистик язмалар. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2010. – 454 б.
2. Тимергалин А. Марсельезалы хатирәләр // Мәдәни җомга. – 2006. – окт.

***А. А. Хәйруллина***
***Казан***

## МӘХМҮТ ХӘСӘНОВНЫҢ «САФ ҖИЛЛӘР» РОМАН-ДИЛОГИЯСЕНДӘ ЗАМАН ҺӘМ ГЕРОЙ

Мәхмүт Хәсәнов күп кенә әсәрләрен хезмәт кешеләренә багышлый. Аны җәмгыятьнең әйдәп бару көчләре − эшчеләр һәм авыл эшчәннәре тормышы, көнкүреше, хезмәттәге уңышлары кызыксындыра. Алар язучыга хезмәт кешесенә багышланган яңадан-яңа, берсеннән-берсе уңышлырак әсәрләр тудырырга мөмкинлек бирә. «Кыюлар юлы» повестенда Татарстан нефтьчеләре тормышы чагылдырылса, «Кама таңнары» романы КамАЗ төзелеше эшчеләренә багышлана.

М. Хәсәнов күңеленә авыл халкы, аларның дөньяга карашлары бик якын, чөнки аның балачагы, үсмер еллары авылда үтә.

XX гасырның 50–60 нчы елларында партия авыл тормышына зур игътибар бирә. Авыл хуҗалыгы өлкәсенә кагылышлы күп кенә әһәмиятле карарлар кабул ителә. Алар игенчелек һәм терлекчелекне торгызуга зур этәргеч бирә. Шулар йогынтысында авылда, күмәк хуҗалык хезмәт уңышлары өчен янып-көеп, үзләрен аямыйча хезмәт итүче эшчәннәр үсеп чыга. М. Хәсәнов та алтмышынчы елларда замана сулышын тоеп, балачак хатирәләре белән илһамланып, үзенең «Саф җилләр» роман-дилогиясен иҗат итә. Әлеге әсәрдә автор зур осталык белән илебездәге 50–60 нчы еллар тормышын һәм аның геройларын тасвирлый.

Әсәрнең төп геройлары булып Мәдинә һәм Хәдичә тора. Бу ике образ бер-берсенә гаять охшаш, шул ук вакытта аермалы яклары да шактый, һәркемнең тормыштагы вакыйгаларга мөнәсәбәте төрлечә. Автор геройларның характер-үзенчәлекләрен, максат-омтылышларын, шәхси тормышларын зур осталык белән сурәтләп бирә.

Мәдинә − авылның алдынгы комсомолы, «боҗыр кебек җитез, чакматаш кебек чая бер кыз бала» диелә аның турында романда (1, 14 ).

Ул гармунчы егет Нәфискә кияүгә чыга. Нәфис сугышның өченче елында үзе теләп сугышка китә һәм Берлинны штурмлаганда батырларча һәлак була. Унсигез яшьтә Мәдинә тол хатын булып кала.

Мәдинә кайгыларга бирелеп, сыгылып төшми. Ул барлык яшьлек дәртен, ташып торган көчен яраткан хезмәтенә багышлый. Саубуллашканда ире Нәфис аңа: «Колхоз сезнең кулда кала, сынатмагыз», – ди (1, 8). Шушы сүзләр Мәдинәнең йөрәген җылытып, хезмәткә әйдәп торалар. Һәм ул үзенең яшьлеген, бөтен барлыгын, хыял-өметләрен авылына багышлый.

Ару-талуны белмәс Мәдинә көнне төнгә ялгап, эшләп, дошманнарны җиңүгә үзеннән зур өлеш кертә. Ул башта фермада эшли. Чын күңелен биреп, беренче урынга һәрвакыт колхоз эшен куеп эшләвен күреп, аны ферма мөдире итеп куялар. Мәдинә яңа хезмәт урынына күчкәч, тагын да зур җаваплылык тоеп эшли. Терлекчелелекне алга җибәрү, күбрәк сөт алу өчен яңа шартлар тудырырга омтыла. Укыган, ишеткән һәр яңалыкны тормышка ашырырга гына тора. Тик аның булсын дип эшләве колхоз рәисе Борһанга ошамый. Аның эзәрлекләвенә түзә алмыйча, ул районга чыгып китә, такта яру заводына эшкә урнаша. Ләкин туган авылы, аның гүзәл табигате, инеш-күлләре, болыннарында утлаучы сыерлары күз алдыннан китми аптырата, күңелен моңсу хатирәләр тырный. Мәдинәне яңа эшендә күрше совхозга командировкага җибәрәләр. Андагы авыл исе, фермадагы тавышлар аның күңелен алгысыта. Ул фермага килә, мөдире белән таныша.

Фермада эш шартларын күреп, Мәдинә шакката. Күп хезмәт автоматлаштырылган. Мәдинә аларның эш тәҗрибәсен өйрәнә.

Яңа эш урыннарында Мәдинә үзен алдынгы эшче итеп таныта. Хезмәттәге уңышлары өчен бүләкләр ала. Борһан аны каралтырга тырышса да, үзенең тырышлыгы, горурлыгы, үҗәтлеге белән хуҗаларның хөрмәтен яулый.

Райком секретаренең эчкерсез сөйләшүе Мәдинәдә авылына кайту теләген уята. Ул яңа идеяләр белән илһамланып, эш тәҗрибәсе туплап, канатланып авылына кайта. Үз тирәсенә үзе кебек булсын дип эшләүче хезмәт коллективы туплый. Хезмәт шартларын җиңеләйтеп, автоэчергечләр куела, автоматлаштырылган савуга күчәләр, азык сыйфатын яхшыртып, рационны баетып, сөт алуны бермә-бер арттыралар. Бөтен районга беренчеләрдән булып, сменалы эшләүгә күчәләр. Эшләү дәверендә төрле каршылыклар, проблемалар килеп чыга. Мәдинә аларны ирләрчә ныклык күрсәтеп, сабыр гына чишү юлларын эзли, тәҗрибәле ил картлары белән киңәшә.

Автор Мәдинә образын бары тик уңай яктан гына тасвирлый. Ул хезмәтен шәхси тормышыннан өстен куя. Ул артык горур, уңганбулган, үз көченә нык ышанган, алдынгы фикер йөртүче, авырлыклардан курыкмыйча, уңышларга сөенеп, көне-төне хезмәт куючы гади авыл хатыны. Язучы әсәрнең «Мәдинә» дип исемләнгән беренче китабын Гыйлаҗи бабай сүзләре белән тәмамлый: «Сөбханалла! Мәдинә киленне әйтәм әле. Күз генә тия күрмәсен үзенә. Кеше асыл, кеше асыл, асылында эше асыл, дип, белмичә әйтмәгәннәрдер борынгылар» (1, 202).

«Саф җилләр» роман-дилогиясенең икенче китабын М. Хәсәнов «Хәдичә» дип атый. Хәдичә − бу әсәрнең төп герое. Автор әлеге образны күбрәк шәхси тормышы аша ачып бирә. Хәдичә − якты өмет-хыяллар белән янып яшәүче авылның чибәр кызы. Үз-үзен генә яратучы Вәлигә тап булу, аның якты хыялларын җимерә. Кечкенә генә аңлашылмаучылык аның гаилә тормышын тарката. Хәдичә кечкенә кызын әнисенә калдырып, үзе көне-төне колхоз эшендә йөри. Әнисе белән генә үскән ялгыз хатынны каралтучылар, рәнҗетүчеләр табылып тора. Хәдичәнең ихтыяр көче какшый, ул тормыш төбенә тәгәри башлый. Җитмәсә, Вәли бердәнбер юанычы булган кызын алып китә. Бу инде Хәдичәне тәмам аяктан ега. Ул авылдан чыгып китә, үзенең күңел газапларын аракы сөреме белән җиңеләйтергә тырыша. Яшьлек еллары тормыш төбендә үтә. Хәдичәнең тормыш юлында яхшы күңелле кешеләр очрап тора. Шулар ярдәме белән үзенең соңгы ихтыяр көчен җыеп, ул тормыш упкыныннан өскә күтәрелә башлый. Мәдинә Хәдичәне авылга алып кайта, эшкә урнаштыра, акыллы киңәше белән авыр вакытларда һәрчак ярдәм итәргә әзер булып тора.

Хәдичә фермада эшли башлый. Аңа коллективка кереп китү, яңа тормыш башлау җиңел булмый. Конфликтлар да булып тора. Хәдичәгә хезмәттәшләре белән уртак тел табарга, намус белән хезмәт итәргә, матур тормыш алып барырга тырышып өйрәнергә туры килә. Тормыш авырлыкларыннан, килеп туган катлаулы хәлләрдән сабак алып, Хәдичә намуслы колхозчыга әверелә. Үзенең бар көчен яраткан эшенә бирә. Бозауларым, сыерларым диеп, ферма юлыннан кайтып керми. Фидакарь хезмәтен күреп, аны хөрмәт итә башлыйлар. Ул хезмәтендә зур уңышларга ирешә. Җитәкчелек керткән яңа хезмәт алымнарын кулланып, намус белән хезмәт итә. Эш урынында аны башкаларга үрнәк итеп куялар.

Хәдичәнең шәхси тормышы да җайлана. Вазих исемле кеше белән гаилә кора, кызы Вәлидә аның янына кайта.

Мәдинә һәм Хәдичә бер авылда яшәп, бер чишмә суын эчеп дус кызлар булып үсәләр. Чая, тырыш, теләсә нинди колхоз эшен үз җилкәләрендә күтәрергә әзер, кайнар йөрәкле яшь кызларны матур киләчәк, бәхетле тормыш көтә кебек. Тик аларны тормыш сынаулары төрле юлдан китәргә мәҗбүр итә.

Мәдинәнең киләчәккә матур планнарын, үз вазыйфаларыннан явызларча файдаланып, кешеләрне рәнҗетүне бернәрсәгә дә санамаган җитәкче җимерә. Ә Хәдичәнең шәхси тормышындагы проблемалар аны ялгыш юлга этәрә.

М. Хәсәнов әсәрендә шуны күрсәтә: бу хатын-кызларны тормыш сынаса да, сындыра алмый. Тормыш каршылыкларын җиңеп, хезмәт фронтында яңа көч, тәҗрибә туплап зур уңышларга ирешәләр.

Автор бу ике образ аша киләчәккә өмет белән карарга чакыра. Мәдинә белән Хәдичә хезмәттәге уңышлары белән моны раслыйлар.

М. Хәсәнов сугыштан соңгы авыр чорларда, ирләрнең юклыгы кискен сизелгән чакта, аларны алыштырырлык, алар башкарган эшне башкарырлык көчле хатын-кызлар образын тудыра. Халык тормышының иң мөһим чыганагы булган хезмәт сөйгән кешеләр генә әсәрнең буеннан-буена үсештә сурәтләнә.

Автор ике героен да яратып яза, аларга җылы мөнәсәбәте укучыга сизелеп тора. Мәдинә белән Хәдичәне ул көчле ихтыярлы, ирләр белән беррәттән эшләүче хезмәт ияләре итеп сурәтли. Сугыштан соңгы кырыс тормыш шартларында авыр физик хезмәтне иңнәренә күтәргән бу хатын-кыз образларын укучы якын итте, аларның фидакарь хезмәтенә сокланды, хезмәт уңышларына куанды. Авторның бу әсәре киң катлау укучылар тарафыннан җылы кабул ителде. Язучы Хәсән Сарьян бу әсәрне түбәндәгечә бәяләде: «М. Хәсәнов колхоз тормышын, кешеләрен, эш шартларын белеп яза. Ә белеп язылган әйбер һәрвакыт ышандыра» (2, 6).

Роман-дилогиядән аңлашылганча, Мәдинә образы хезмәт процессында ачыла. Хәдичә образы исә башта шәхси планда, соңрак хезмәткә мөнәсәбәттә тасвирлана. Хезмәтне шәхси тормыштан өстен кую совет чоры язучылары иҗатына хас күренеш булды. М. Хәсәнов та моннан читкә китә алмаган.

М. Хәсәнов үз заманы геройларының тормыш-көнкүрешен, өмет-максатларын яхшы белә, шуңа да аның әдәби геройлары – Мәдинә һәм Хәдичә – психологик яктан да оста тасвирланалар.

Һәр заманның үз герое бар. Ул үз проблемалары белән яши, чор каршылыклары белән көрәшә, шул көрәш барышында язучы аның эчке дөньясын, әйләнә-тирә кешеләре белән үзара бәйләнешне, геройның

кешелек сыйфатларын алгы планга куеп сурәтли. М. Хәсәновның «Саф җилләр» роман-дилогиясендә Мәдинә образы тормыштагы төрле каршылыклар аша үтеп, нык ихтыяр көчен күрсәтеп, укучының хөрмәтен казана. Әлеге образ һәркемне киләчәккә ышаныч белән карарга, һәртөрле каршылыкларны җиңеп яшәргә чакыра.

ӘДӘБИЯТ

1. Хәсәнов М. Саф җилләр / М. Хәсәнов. − Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. − 368 б.

2. Заһидуллина Д. Әдәби әсәр: өйрәнәбез һәм анализ ясыйбыз / Д. Ф. Загидуллина, В. Р. Аминева, М. И. Ибраһимов. – Казан: Мәгариф, 2007. – 112 с.

***Р. Р. Шарифзянова***
***Казань***

## ТВОРЧЕСТВО ФАУЗИИ БАЙРАМОВОЙ В АСПЕКТЕ ТЕОРИИ «ВОЗМОЖНЫХ МИРОВ» (На основе рассказа «Күл балыгы»)

Семантика возможных миров на протяжении долгого времени развивалась и изучалась в эпистемической логике финского философа Я. Хинтикка. В интерпретации Я. Хинтикки возможные миры – это понятие не онтологическое (нечто отличное от реального мира), а эпистемологическое (другой вариант видения реального мира). И если у Я. Хинтикки возможный мир выступает в качестве логико-семантической основы его философских исследований, то в художественной области возможный мир предстает в поэтически-образном воплощении. Правомерность использования понятия возможного мира относительно творчества Ф. Байрамовой исходит из ее отличительной манеры литературного повествования. Повышенный психологизм, сознательная субъективизация возможных миров, воссоздание неправдоподобных, иногда нанизанных один на другой возможных миров, слияние позиций автора и персонажей, изобилие философских и нравственных идей – вот основные выдающиеся черты произведений Ф. Байрамовой.

Материалом для исследования семантики возможных миров в прозе Ф. Байрамовой мы избрали рассказ-фэнтези «Күл балыгы» (1984). Небольшой по содержанию, но глубокий по смыслу рассказ повествуется от первого лица, где главным героем выступает ирреальный персо-

наж – Күл балыгы кызы. Сюжет однолинейный. Хронотоп ограничен несколькими элементами: Мир озера (Күл дөньясы) – Земной мир (Җир дөньясы) – Мир голубого тумана (Зәңгәр томан иле). Это есть объекты, вокруг которых локализуются основные события. (При осмыслении они принимают символичную нагрузку). В экспозиции Күл балыгы кызы по воле судьбы оказывается в Мире озера, завязкой является появление в ее жизни Человека из Земного мира, конфликт назревает от возникшего чувства любви к Человеку, что вызывает внутреннее и внешнее противостояния, напряжение нарастает при осознании чувства безысходности и внутреннего одиночества, кульминацией становится предательство Человека, следует развязка – не в силах противостоять природе реального мира – природе Человека, главного героя постигает необратимая погибель.

Варианты возможных миров, созданных автором, можно определить как действительные-возможные миры, это Мир озера, Земной мир, Мир голубого тумана. Таким образом через коллизею главного героя, являющегося интегратором всех трех миров, через психологический поток его мыслей, через преломления событий его сознанием создается возможный мир – Мир мыслей (Сурәтләр дөньясы): «Зиһенемә кинәт сурәтләр дөньясы кереп тулды... Сурәтләр дә өзек-өзек, бик буталчык, ләкин минем хәләтемә бик якын... Шул сурәт су өстендә чайкалып тора, шул сурәт су төбенә төшә, шул сурәт минем аңыма үтеп керә... » (1, 209, 211). Разделение действительных миров довольно контрастно, они в корне отличаются по типу своего существования. Күл балыгы кызы дает оценку каждому из них исходя из своего мировоззрения.

«Мин үземнең бу күлгә ничек килеп эләгүемне хәтерләмим... Мин әле башта үземнең балык икәнемне дә белмәдем. Мин башта аларның барысы кебек идем. Салкын күл төбенә төшеп ятулар, үлән арасыннан уйнаклап йөзеп узулар миңа бик ошый иде» (1, 209), – так Күл балыгы кызы вспоминает первые моменты своего существования. Да, вначале присутствует внутреннее спокойствие духа, Мир озера кажется вполне привычным и родным до тех пор, пока Мир Мыслей новой волной не переполняет внутенний мир героя: «Ләкин бу юлы башка сурәтләр, мин бөтенләй күрмәгән, белмәгән сурәтләр иңде... Бу минем өчен искиткеч тын, искиткеч шомлы дөнья иде. Агачлар арсыннан кинәт... балык та түгел, мин кем икәнне белми торган, ләкин шулкадәр гүзәл бер зат йөгереп килеп чыкты». Картина Земного мира и встреча с людьми еще больше пробуждает Мир мыслей героя, тем самым проявляя его оценку человеческому миру в эмоционально-образной форме: «Җир өстендәге

тормыш та бик сәер икән. Бераз гына күл балыклары тормышына да охшаган. Алар да, безнең кебек, вакыты җиткәч, җыелышып ашыйлар, без йөзәбез, ә алар һаман каядыр ашыгалар, йөгерәләр. Уйларындагы сурәтләрдә алар гел парлы, алар балыклардан җүләррәк, хислерәк, бәхетлерәк, ахры» (1, 211).

События вокруг героя развиваются динамично. Неожиданно обнаружив отличность от других обитателей мира, в котором фактически существует, Күл балыгы кызы начинает осознавать свое одиночество: «Нигә кешеләр уйларны күрә белмиләр икән?! Аларда бит минем ялваруым, сагышым, куркуым, теләкләрем, минем җаным. Мин алар кебек сөйләшә белмим, мин уйлыйм гына, мин яшим генә, саташа-саташа, сагына-сагына, күлегез төбендә яшим мин, кешеләр!.. Ләкин... минем янга беркем дә төшми» (1, 217). Уникальность проявляется как во внешних очертаниях: «Юк, мин кешегә охшамаганмын. Куркыныч зур яшькелт күзләр, ялварулы караш... Һәм бөтенләй чит тән. Күккә таба сузылган куллар. Һәм... балык койрыгы. Йа Күгем!» (1, 213), так и во внутреннем поведении, в частности в умении мыслить и видеть Мир мыслей: «Мин балык та түгел, кеше дә түгел. Мин уйлый беләм, аларның уйларын күрә беләм, тик араларында яши алмыйм...» (1, 212). Дисгармония героя с окружающим миром рождает в ее сознании – в возможном мире – Мир голубого тумана, где среди себеподобных она могла бы спастись от удушающего ее одиночества: «Бер мизгелдә караңгы күкне, андагы якты нокталарны күреп алам. Хәтеремне телгәләп, кинәт аңымда яшен яшьни. Күктәге якты нокталар бер якынаялар, бер ерагаялар, кинәт зураеп, зәңгәрләнеп, тоташ бер күлгә әйләнәләр. Юк, ул күл дә түгел, ул тоташ зәңгәр томан, шунда ук минем кебек үк балыклар йөзә. Ләкин алар мин күреп өйрәнгән күл балыклрына охшамаганнар. Йөзләре нәкъ теге җир өстендәге затларныкы кебек, әле алардан да гүзәлрәк, нәфисрәк. Ап-ак куллары да бар. Әнә мине дә үзләре янына чакыралар...» (1, 210).

Идея того, что возможный мир всегда предполагает оппозицию действительного мира, очень важна. Благодаря этому признаку, можно выделить и некоторые другие явления и литературные формы, например, такие как прием потока сознания. Поток сознания, воплощающий возможный мир – Мир мыслей главного героя, создает возможность для читателя как бы «подслушать» свой опыт в сознании персонажей. Отклик внутреннего мироощущения и сопереживание динамичному развитию потока чувств героя являет перед нами его образ архетипа. Как объясняет швейцарский философ и основоположник аналитической психологии

Карл Густав Юнг, архетипы «не имеют определенного происхождения... архетипы вплывают в наш практический опыт, – они одновременно образы и эмоции... заряженный эмоцией образ приобретает сакральность (нуминозность) или психическую энергию, он становится динамичным, вызывающим существенное последствие… это не просто имена и даже не философские понятия. Это куски самой жизни, образы, которые через мост эмоций интегрально связаны с живым человеком» (6).

Противостояние и в то же время переплетение действительных миров и возможного мира в полной мере раскрывает личную трагедию героя, которая в определенной мере и окраске отражается в общечеловеческом бытие. Герой проходит путь прозрения духа от утраты былых идеалов до надежды на обновление духа: «…Җаным күккә тарта... Бу салкын Җирдән, кешеләрдән, гомеремә хуҗа булып торган күл төбеннән һаман ераклашам, китәм. Биредә узган гомердән бер генә сурәт кала – Ул. Мин аңа кайту өчен китәм. Язларында – тамчы булып, җәйләрендә – дулкын булып, төннәренә наз булып кайтырмын әле мин аның... Җирдәге бердәнбер кешенең... зиратына сандугач булып кайтырмын... Барыбер кайтырмын...» (1, 228–229).

Проза Ф. Байрамовой обладает огромным оценочным потенциалом, тем самым позволяя читателю воссоздать личное отношение к глубинным проблемам бытия. Исследование рассказа-фэнтези «Күл балыгы» в аспекте теории «возможных миров» подводит к выводу, что любое живое существо, будь то Человек или животное, является частью природы Бытия. И жить ему необходимо сообразно со своим предназначением, сохраняя гармонию и баланс, как внутри себя, так и в природе.

ЛИТЕРАТУРА

1. Байрамова Ф. Күнел карлыгачларым: Повестьлар / Ф. Байрамова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. – 272 б.

2. Нигматуллина Ю. Г. Национальное своеобразие эстетического идеала / Ю. Г. Нигматуллина. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1970. – 211 с.

3. Хинтикка Я. Логико-эпистемологические исследования / Я. Хинтикка. – М.: Прогресс, 1980. – 445 с.

4. Целищев В. В. Философские проблемысемантики возможных миров / В. В. Целищев. – Новосибирск: Наука, 1977. – 189 с.

5. Шамсутова А. А. Фаузия Байрамова прозасы (фәлсәфи-эстетик карашлар, образлар системасы, психологизм һәм мотивлар). / А. А. Шамсутова – Казан, 2005. – 100 б.

6. Янг К. Г.: http://jungland.ru/arhetip

*А. Я. Янмурзина*
*Болгар*

# ЖАНРОВАЯ СИСТЕМА ПОЭЗИИ МУСЫ ДЖАЛИЛЯ И ИЗУЧЕНИЕ ОДНОЙ ИЗ ЕЕ ОСОБЕННОСТЕЙ

Вопрос о литературных жанрах является одним из самых сложных в теории литературы. На сегодняшний день в науке не существует единого, принятого всеми учеными определения литературного жанра: работы различных теоретиков содержат в себе разные, не идентичные друг другу формулировки этого понятия.

В «Литературном энциклопедическом словаре» дается следующее понятие жанра: «Жанр литературный (от французского – род, вид), исторически складывающийся тип литературного произведения (роман, поэма, баллада и т. д.); в теоретическом понятии в жанре обобщаются черты, свойственные более или менее обширной группе произведений какой-либо эпохи, данной нации или мировой литературы вообще» (7, 106–107).

Определение термина жанра излагают различные литературоведы: Б. Томашевский, Г. Л. Абрамович, Л. И. Тимофеев, Г. Н. Поспелов, Н.А. Гуляев, В. В. Кожинов, И. В. Стеблева и др.

«Понятие жанра объединяет группу текстов, имеющих общую поэтическую систему, которая фиксирует стабильную связь постоянных признаков формы и определенного содержания в одну и ту же эпоху», – определяет И. В. Стеблева (9, 3–8).

«Изучение лишь отдельных жанров, вне попытки создать их систему, не может привести к положительным результатам. Без сопоставления одних жанров с другими трудно выяснить своеобразие каждого из них» (8, 271). Это и объясняет необходимость изучения стихотворных жанров в комплексе, как целостной системы.

«Любая система, как целостность, имеет свои элементы, которые настолько тесно связаны друг с другом, что выступают по отношению к окружающим условиям и другим системам как нечто единое. Элемент системы суть минимальная единица в составе данного целого, выполняющая в нем определенную функцию.

Каждая система может выходить, как известно, на более обширную организацию и становится ее подсистемой (компонентом, элементом), так же как любая подсистема может, при необходимости, рассматриваться как самостоятельная система с присущей ей внутренней целост-

ностью составляющих ее частей, устойчивой упорядоченностью, автономностью и своими собственными связями со средой», – пишет А. Шарипов (10, 194).

Существует понятие «жанровое мышление» и жанровое восприятие». Жанровое мышление требовало от автора выполнения в своем произведении всех нормативов, предусмотренных поэтикой данного жанра. Муса Джалиль, продолжая традиции татарской литературы с древних времен, писал в таких жанрах, как газель, касыда, рубаи, кытга, парча, мадхия, марсия, насихат, хикмат, баллада, поэма, песня. Жанр, являясь системой, составляет не только формальные структуры, образованные по иерархии, но и организует особенную композицию, архитектонику, ансамбль произведения и творит музыкальную тональность звука.

Если все так сложно и проблематично, почему писатели не могут писать свои произведения без жанра, то, что они хотят поведать читателям в своих книгах? Возникает такой недоуменный вопрос.

Основным критерием системы жанров является целостность, единство цели. Если поэт в стихотворении не отразил целое, как каплю из океана, то без целого, как в круге, не будет центра.

«Поэзия есть высший род искусства», – писал В. Г. Белинский... – Всякое другое искусство более или менее стеснено и ограничено своим материалом, в котором оно проявляется (живопись, архитектура, скульптура, музыка и т.д.), поэзия же выражается в слове, которое и звук, и картина, и представление, и мысль... Поэтому поэзия заключает в себе все элементы других искусств... представляет собой ценность искусства... и, объемля собой все его стороны, заключает в себе ясно и определенно все его различия. Все элементы жизни и поэзии слиты в живое единство» (16, 9).

Когда изучается и анализируется система жанров поэзии Мусы Джалиля, надо исходить из вышесказанного. Исследователь творчества М. Джалиля Н. Г. Юзеев пишет: «Поэт, раскрывший в своем творчестве душу народа своим искусством, подтвердил жизненность поэтического мира называемой «традицией Джалиля» (5, 65).

Традиция Джалиля… В чем его суть, особенность, точка зрения системы жанров? Чтобы это понять приходят на помощь слова самого поэта: «Песни мои остались, разматываясь от клубка жизни на моем пути» (построчный перевод) (4, 32).

Если уместно такое сравнение, жанр, как единая система, настроена на музыкальную тональность. Произведение упорядочивается,

пройдя свой процесс развития. Необходимо изучение этих закономерностей в процессе исследования системы жанров поэзии Мусы Джалиля, обращая внимание на его различия от других поэтов, на его особенности. Особого внимания заслуживает его стремление к синтезу, соединение конкретного обыденного явления с образом мечты (но не вымысла), творение гармонии. Поэтическое мышление поэта нужно изучать теоретически на научной основе. Жанр поэзии творился в его стихах не по готовым штампам (калып), а в самой гуще обыденной жизни. Обычно его поэзию представляем в героическом ореоле. Но были у него трудные времена…

Ночной простор. Я жгу костер.
Вокруг туман... я одинок – ...
Огонь, светящийся во мгле,
Заметят ли, найдут ли?
На звук, летящий по земле,
Ответят ли, пройдут ли? (3, 102).

Это стихотворение 1930-ых годов «Одинокий костер». Во мгле одинокий поэт зажег огонь… «Сама это способность задуматься над окружающим, ощутить дыхание бытия, говорила о глубине его поэтического «Я». Он создал свой образный мир, создав «круг света», высветив из обыденной жизни то поэтическое, которое обычно не замечается. Особенно в жанре песни умел увидеть образно невидимый обычному взгляду. Это был человек художественного склада и темперамента, именно поэтически отзывающийся на все впечатления бытия» (1, 24). Его поэтическая отзывчивость, как струна музыкального инструмента отзывалось на все вокруг его. В нечеловеческих условиях фашистского плена и перед ожиданием смертной казни Джалиль не утратил способность поэтически отзываться на все происходящее вокруг него и внутри своей души. Этим мы обязаны, что имеем «Моабитские тетради». Ведь птицы, даже соловей в неволе не поет. Само поэтическое творчество он воспринял, как способ победить смерть, чтобы песни могли жить и после смерти на родной земле.

Что значит мыслить жанром и ориентироваться на его законы? Предписательной силы жанр не имеет, но тогда какой смысл приобретают традиционные определения? Наибольшую сложность в этом предоставляет поэзия. Исследователи недостаточно четко определились, какова роль жанра внутри лирического произведения, как только внимание перемещается на уровень текстов, красиво написанные жанровые ярлыки

отказываются работать – становятся очевидными отсутствие внятного понимания, что такое жанровый анализ, и неадекватность наполнения категории жанра задачам такого анализа. Потому что жанр стихотворения для автора является не исходной точкой, а итогом творчества.

Стихотворение, двигаясь от первого слова к последнему, может включать в лирический сюжет самые разные жанровые элементы – ведь в качестве жанровых могут опознаться как определенные лирические, ситуации, так и отдельные мотивы. Но когда лирический сюжет завершен и стихотворение состоялось как целое, всегда оказывается, что этот сюжет завершен определенным способом, по которому опознается жанр. Жанр как бы инструмент прочтения текста.

«Жанровый анализ стихотворений – сложная задача... Нет готовых жанров. Поэтому главная творческая проблема – дорастет ли личное, случайное, мелкое до всеобщего, универсального, жанрового. Именно жанр типологизирует, обобщает частный опыт, делает из мимолетного взгляда на вещь ракурс взгляда, способ мировидения. Контакт с жанром заставляет поэта более глубоко вглядываться во внутренний мир лирики, исключать из него случайные элементы.

Поэт не начинает с выбора жанра, а приходит к жанру через выбор предмета высказывания в ряду себе подобных, в результате чего «включается» своеобразный механизм подсказки жанром следующего слова и способа завершения в целом.

…Каждое произведение должно быть не отнесено к жанру, не втиснуто в классификационную ячейку… Каждый жанр – это особый тип, способный строить и завершать целое. Важно увидеть в этом явлении главный принцип функционирования жанров, на основе которого во многом и строится современная жанровая теория», – пишет исследователь теории жанров, литературовед В. Козлов (6, 216–221).

Изучение творчества поэта на научной основе, в системе жанров позволяет охватить все в целостности, т.е. «увидеть лес, а не только отдельные виды деревьев». Поэзия Мусы Джалиля – это целый мир. Идеал образа поэта по традиции идет от Г. Тукая, который писал в стихотворении «Булмаса» («Что за цена красе твоей?»):

Сурәтеңнең иң чыны, бел, шагыйрьнең күңлендәдер,
Көзгедән чын төсеңне күрмисең, ул булмаса.

(Лишь в пламенной душе поэта твой образ истинный сокрыт –
В холодном зеркале, поверь, твоих живых примет не будет) (11, 178).

«Что такое поэт? Человек, который пишет стихами? Нет, конечно... Он пишет стихами, т.е. приводит в гармонию слова и звуки, потому что он – сын гармонии, поэт. Что такое гармония? Гармония есть согласие мировых сил, порядок мировой жизни... Космос – устроенная гармония, культура. Мировая жизнь состоит в непрестанном созидании новых видов... Гармония дает им образы и формы.

Поэт – сын гармонии; и ему дана какая-то роль в мировой культуре. Три дела возложены на него: во-первых, освободить звуки из родной безначальной стихии, в которой они пребывают, во-вторых, привести эти звуки в гармонию, дать им форму, в-третьих, внести эту гармонию во внешний мир (2, 162).

«Исходя из требований жанра (например, в поэме “Письмоносец”), необходимо найти “точку освещения”... Форма жанра связана с содержанием поэмы. Форма упорядочивает, отсекая как лишнее, то, что напрямую не связано с главными героями, высвечивая главный поэтический замысел». Обращая особое внимание на поиск закрепленный традицией систему жанра, связь сюжетной линии с поэтическими образами произведения», – писал Н. Юзеев в монографии (12, 197). Этого поэт достигает, сделав народные песни лейтмотивом всей поэмы.

Песни в поэзии М. Джалиля в его целостной системе жанров составляют особую подсистему. Г. Кашшаф в своей монографии «Муса Джалиль» подробно проанализировал его песни и отметил, что они являются определяющим жанром. Песни в его последних стихах достигают высоты и объема симфонического звучания («Последняя песня», «Мечта», «Любимой», «Мои песни»:

Песни, в душе я взрастил ваши всходы,
Ныне в отчизне светите в тепле.
Сколько дано вам огня и свободы,
Столько дано вам прожить на земле.

«Поэта именуют «хикмэт иясе» – творцом мудрого слова в стихах (в таком смысле можно передать это татарское выражение о поэте импровизаторе – *А. Я.*), – отмечатает Н. Юзеев (14, 15). Муса Джалиль в стихотворении «Последняя песня» выражая свое состояние, пишет «Я знаю...» (4, 100). Поэт сначала осознает, познает все это разумом, а потом в ощущениях, переживаниях и, опираясь на жизненный опыт, в этом пламене страстей и переживаний творит свой особый поэтический мир. Многие его стихи загорелись из искры раздумий, озарений. И эти поэтические мысли сами воспламенялись из искры чувства любви.

«Слово рождается у поэтов «мудрым разумом» (хикмәт белән) (подстрочный перевод наш), писал поэт-просветитель Акмулла» (16, 87). В этом древнем восточном жанре хикмет творили такие поэты, как Ясави, Бакыргани, Мауля Колый и др. Так в виде предварительной гипотезе можно выделить в поэзии М.Джалиля стихотворения, написанные в жанре хикмэт: «Один совет», «О героизме», «Дуб», «Четыре цветка», «Поэт», «Рубашка», «Волшебный клубок». Жанр – это как бы инструмент прочтения текста как целое (т. е. как в каждой капле отражается океан). Чтобы попытаться понять суть жанров поэзии – его жизненность, то само слово «стихотворение» это раскрывает: стихо – творение, творение стихов. Необходимо теоретическое изучение на научной основе этих закономерностей в процессе исследования системы жанров поэзии М. Джалиля, обращая внимание на различия от других поэтов, на его особенности.

В жанровой системе поэзии М. Джалиля есть такая определенная особенность, которую он сам выделил в предисловии «От автора» к своей драматической поэме. Он написал: «Элементы реальности, сливаясь с элементами фантастическими, образуют синтез. Это и есть особенность, отличие данного произведения... Синтез, взаимодействие реальности и фантастического... Объединяя эти два момента, я стремился к гармонии» (13, 125). Так в своих произведениях поэт, организуя систему жанров в целостность, объединяя реальные и легендарные образы с помощью синтеза жанров, находит точку освещения и, как лучом света, дает сияние всему вокруг. «В песне зажег я огонь...» (3, 294). Уходя, поэт оставляет свет.

Итак, система жанров поэзии Мусы Джалиля служит одной цели, главной цели поэта – рождению, «достижению гармонии».

ЛИТЕРАТУРА

1. Воздвиженский В. Поэзия Мусы Джалиля. Литературный портрет. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1981. – 120 с.

2. Блок А. Собрание сочинений. Т. 6. – М., 1971.

3. Джалиль М. Сочинения. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1962. – 607 с.

4. Джалиль М. Сочинения в пяти томах. Т. II. – Казан, 2006, – 382 с.

5. История татарской литературы в шести томах. Т. V. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1989. – 544 с.

6. Козлов В. О жанровом анализе поэтического произведения // Вопросы литературы, 2011. – № 1. – С. 208–237.

7. Литературно-энциклопедический словарь. – М.: Советская энциклопедия, 1987 . – 751 с.

8. Поспелов Г. Н. Теория литературы. – М.: Высшая школа, 1978. – 349 с.
9. Стеблева И. В. Введение // Теория жанров литератур Востока. Сб. статей. – М.: Наука, 1985. – С. 3–8.
10. Шарипов А. Зарождение и становление системы стихотворных жанров в древнетюркской и тюрко-татарской литературе (VII–XIV вв.) – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 2001. – 364 с.
11. Тукай Г. Стихотворения: Пер. с татар. – Л.: Советский писатель, 1988. – 432 с.
12. Юзеев Н. Современная татарская поэзия. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1973.
13. Юзеев Н. Поэмы Мусы Джалиля. – Казан: Изд-во Казан. ун-та, 1960. – 341с. (на тат. яз.)
14. Юзеев Н. Искусство татарского стиха. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1991. – 304 с.
15. Акмулла М. Стихи. – Казан. – 1981. (на тат. яз.)
16. Белинский В. Г. Полное собрание сочинений. – Т. V. – 1954.

# ФОЛЬКЛОРИСТИКА

***А. М. Гайнетдинов***
***Казан***

## ТӘҺСИ ТАРАФЫННАН КУКМАРА РАЙОНЫНА ОЕШТЫРЫЛГАН ЭКСПЕДИЦИЯЛӘР

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә Кукмара районына караган күп кенә фольклор, музыкаль, археографик материаллар саклана. Алар, нигездә, төрле елларда оештырылган фәнни экспедицияләр вакытында халыктан җыелган. Институт оешканнан алып бүгенге көнгә кадәр анда эшләүче галимнәр Татарстанның бөтен районнарында һәм татарлар яшәгән һәр җирдә диярлек булырга өлгерделәр. Кайбер төбәкләргә бер генә түгел, ә бик күп мәртәбә экспедицияләргә баралар. Шул исәптән, гүзәл Кукмара якларына да.

Кукмара районына Институтның иң беренче фольклор экспедициясе 1951 елның июнь-июль айларында оештырыла. Аны атаклы галим Хәмит Ярми җитәкли. Экспедициядә түбәндәге Институт хезмәткәрләре катнаша: Халидә Гатина, Эдуард Касыймов, Наил Гыйззәтуллин, Салих Гарипов, Сания Шәмсетдинова, Мәрва Богданова.

Районга поезд белән килеп җиткәч, фольклор материал җыю эшен алар Кукмараның үзеннән башлыйлар. Кукмара бистәсендә яшәүчеләрдән күп кенә материал җыялар (барлыгы 679 кыска һәм сюжетлы җырлар, 2 бәет, 2 экият, 1 истәлек) (1, сак. бер. 1–6).

Шуннан соң фольклорчылар төркемнәргә бүленеп, авыллар буенча таралалар. Экспедиция җитәкчесе Х. Ярми хатыны Х. Гатина белән Туембаш, Мәмәшир, Мәчкәрә, Янил, Чура, Кушкетбаш авылларында булып, барлыгы 628 кыска җыр, 14 сюжетлы җыр, 6 уен җырлары язып алалар (1, сак. бер. 2).

Э. Касыймов, Н. Гыйззәтуллин һәм М. Богдановалар бер үк авылларда йөриләр. Алар Зур Кукмара, Янсыбы, Байлангар, Янил, Ядегәр авылларында булалар. Э. Касыймов белән Н. Гыйззәтуллин барлыгы

7 әкият, 4 истәлек, 1 бәет, 549 кыска һәм сюжетлы җырлар, 7 уен язып алып кайталар (1, сак. бер. 6). М. Богданова берүзе генә 245 кыска һәм сюжетлы җырлар, 2 халык уены, 5 балалар уены язып алырга өлгерә (1, сак. бер. 5). Экспедиция барышында алар халык арасында төрле темаларга әңгәмәләр уздыралар, комсомол оешмаларына агитация-пропаганда эшләрен алып баралар. Колхозчы картлар арасында Э. Касыймов тарафыннан алты, Н. Гыйззәтуллин тарафыннан дүрт лекция укыла. Шулай ук бу вакытта печән өсте булганлыктан, кайбер кешеләргә печән әзерләүдә дә ярдәм итәләр (1, сак. бер. 6). Димәк, Институт хезмәткәрләре фольклор материалларын җыю белән генә чикләнмичә, авыл халкы арасында агарту эшләрен дә алып барганнар, эшләрендә ярдәм итешкәннәр.

С. Гарипов Туембаш, Зур Сәрдек, Чишмәбаш, Купка, Янил, Чура, Вахит авылларында булып, барлыгы 445 кыска һәм сюжетлы җырлар, 3 әкият язып ала (1, сак. бер. 4). С. Шәмсетдинова шулай ук бу авылларда булып һәм Күшкетбаш авылына да кереп, барлыгы 231 кыска һәм сюжетлы җырлар, 1 бәет, 1 әкият, 1 истәлек, 1 җырлы уен язып алып кайта (1, сак. бер. 3).

Шулай итеп, Институт хезмәткәрләре ике ай буе, коеп яуган яңгырларга, кыздырып торган кояшка карамыйча, фән өчен бик кыйммәтле күпсанлы халык авыз иҗаты әсәрләре җыеп йөриләр. Киләчәктә, алар алып кайткан фольклор материалларының күбесе «Татар халык авыз иҗаты» томлыкларында дөнья күрә.

Г. Ибраһимов исемендәге ТӘҺСИ хезмәткәрләре Кукмара районында фольклор гына түгел, археографик материаллар җыю өчен дә күп тапкыр фәнни экспедицияләргә чыгалар.

Хисаплардан күренгәнчә, иң беренче мәртәбә бу районга археографик материал җыю өчен Институт хезмәткәре Рафис Әхмәтов тарафыннан 1977 елда оештырыла. Ул Югары Өскебаш авылында йөреп, шактый гына борынгы кулъязма һәм басма китаплар җыеп кайта.

1978 елның июль аенда Әнвәр Шәрипов Кукмара районының Күкшел, Мәчкәрә авылларына бара һәм күп кенә археографик материал таба.

Шул ук елда Р. Әхмәтов кабат Кукмара районына юл тота. Бу юлы ул Битләнгер авылында фәнни экспедициядә була һәм, әлбәттә, буш кул белән генә кайтмый.

Шулай ук 1978 елда Г. Гыйниятуллин Түбән Өскебаш авылына бара. Ул да берникадәр борынгы кулъязма һәм басма китаплар табу бәхетенә ирешә.

Институтта эшләүче күренекле галим Марсель Әхмәтҗанов 1984 елда Кукмараның үзендә, Өлге, Пычак авылларында булып, күп кенә борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар таба, борынгы кабер ташларын өйрәнеп кайта. 1985 елда ул тагын Березняк (Бучирмә), Камышлы, Киндеркүл, Адай авылларына бара һәм бик күп «хәзинә» җыеп кайта.

1985 елның май аенда Р. Ягъфәров Кукмара районының Адай авылына барып, борынгы кулъязмалар һәм сирәк китаплар җыя.

90 нчы елларда әле тагын тел белеме галимнәре дә Кукмараның кайбер авылларында диалектология буенча шактый күп материал җыеп кайталар.

2011 елның июлендә Институт тарафыннан кабат Кукмара районына экспедиция оештырыла. Шуны да әйтергә кирәк: әлеге фәнни экспедиция комплекслы була. Анда фольклор, археография, тел, сәнгатькә караган материалларны җыючылар да чыга. Шуңа күрә шактый күп материал җыела. Борынгы кулъязма һәм сирәк китаплар гына 300гә якын берәмлек табыла.

Барлык материаллар да Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә бик кадерләп кенә саклана. Чөнки, беренчедән, алар татар халкының кыйммәтле мирасын тәшкил итә, икенчедән, бу материаллар Институт хезмәткәрләре тарафыннан бик күп авырлыклар, тырышлыклар белән, тир түгеп җыелган.

ӘДӘБИЯТ

1. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәге: 41 ф., 42 колл., 1 папка.

***К. Р. Идрисова***
***Казан***

## «СУГА БАТКАН ГАЙШӘ» БӘЕТЕНЕҢ ВАРИАНТЛАРЫ

Бәет – профессор М. Бакиров биргән билгеләмә буенча, – гарәп сүзе: аның ике мәгънәсе бар: 1) гарәп-фарсы һәм төрки халыкларның язма поэзиясендә ике юлдан тора торган строфа; 2) татар фольклорында ул халкыбызның үзенә генә хас булган һәм аннан башкортларга да кергән лиро-эпик жанр атамасы. Монда шуны да искәртеп үтәргә кирәк: төрки халыкларның үз телләрендә дә «бәй» – «бой» һәм «эт» – «өт» дигән сүзләрдән кушылып ясалган «бәй-эт» («бой-эт») дигән термин бар. Ул да

«көйләп әйтү» яки «көйле хикәят» дигәнне белдерә. Димәк «бәет» жанрының атамасын төрки җирлектә дә аңлатып була икән.

Бәет фаҗигале һәм гыйбрәтле вакыйгалар, шулай ук гадәттән тыш хәлләр уңае белән чыгарылган шигъри әсәр. Ул телдән әйтелә яки көйләп башкарыла. Эчтәлекләренә карап бәетләр фаҗигале, героик һәм комик төрләргә бүленәләр. «Рус-француз сугышы бәете» , «Урта Тигәнәле бәете». « Аючы Дәүли», « Суга баткан Гайшә» бәетләре моңа мисал булып торалар (1, 28; 2, 84).

Күрүебезчә, без тикшерә торган «Суга баткан Гайшә» бәете хәтта кыска сүзлек билгеләмәсендә дә атап үтелә. Бу факт әсәрнең бәет жанрының типик үрнәкләре рәтендә йөрүе турында сойли.

Бәет, дөрестән дә, татар халкы яши торган барлык төбәкләрдә дә киң таралган. Татарстан турында инде әйтеп тә торасы юк. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә әсәрнең фольклор экспедицияләре вакытында Мордва Республикасында, Оренбург, Ульянов, Горький, Новосибирск, Пермь, Свердловск өлкәләрендә, Иркутск, Алматы шәһәрләрендә язып алынган (еш кына көе белән), яисә җыр дәфтәрләреннән күчерелгән текстлары саклана (6, 324–325). Ә матбугатта аны моннан бер гасыр элек (төгәлрәге, 1913 елда) Хуҗа Бәдигый үзенең «Халык әдәбияты: Бәетләр» җыентыгында «Баткан Гайшә» исеме белән бастырып чыгарган (3, 144–145). Менә ул текст:

«Чәһәршәнбә көн кер юарга ник җибәрдең, әнкәем?
Барма, Гайшә! дигән булсаң, бармас идем, әнкәем.
Кулымдагы көмеш йөзек көнгә каршы эридер,
Тал чыбыктай зифа буем су төбендә черидер.
Өстемдәге камзулымны элеп куйдым казыкка;
Зифа буем үскән икән балыкларга азыкка.
Баткан чакта итәкләрем батадыр да калкадыр,
Муйнымдагы йитмеш тәңкәм су төбенә тартадыр.
Аучы мылтык атадыр да тотене җиргә ятадыр;
Гайшә матур батты дигәч, туе егълап кайтадыр.
Чәһәршәнбә көн мунча яктым, башым-күзем юарга;
Чәһәршәнбә көн кер чайкадым газиз башым җуярга».

Бу әсәр Бәдигый җыентыгыннан соң дөнья күргән барлык бәет китапларында урын алып килә. Аларның соңгысы Ф. Әхмәтова-Урманче әзерләгән «Татарский эпос: Баиты – Татар эпосы: Бәетләр» томы. Әлеге ике бәетне чагыштырып карасак, текстларда аерма юк диярлек. Икеөч фонетик үзгәреш: чәһәршәнбә – чәршәмбе, йитмеш – җитмеш, егълап – җылап һәм «йитмеш тәңкә» сүзләре «тәңкәләрем» дип алышты-

рылган. Чөнки «җитмеш тәңкә» гыйбәрәсе бүгенге укучыларга инде аңлашылмый. Электә хатын-кызларның муенса, изү, күкрәкчә, калфак һ. б. ш. бизәнү әйберләренә энҗе-мәрҗән кебек асылташлар белән рәттән көмеш тәңкәләр дә тагыла торган булган. Җитмеш тәңкә кыз бирнәсе булып саналган, шәригать, мәхкәмә кануннары буенча ул бүленергә тиеш булмаган (7, 219; 3, 144–145).

Бәетнең сәнгатьчә камиллеге күзгә ташлана. Анда «көмеш йөзек», «тал чыбыктай зифа буй», «газиз баш» кебек тыйнак, ләкин татар кешесе өчен традицион булып әверелгән сурәтләр, чагыштырулар, эпитетлар бик урынлы кулланылган, ритм төзек: баштан ахыргача 15-15 иҗекле үлчәм (әгәр икеюллыктан дүртьюллык итеп язсаң 8-7-8-7 иҗеклегә әйләнә). Рифмалар тулы аһәңлелеккә корылганнар: эридер – черидер, казыкка – азыкка, калкадыр – тартадыр һ. б. Кыскасы, бәет беренче ишетүдә үк тыңлаучы күңеленә сеңеп бетә. Авылның иң матур кызы суга батып үлү, әлбәттә, кешеләрне тетрәндерә. Һәм әле фаҗигане тагын да тирәнәйтә торган фактор бар: кыз иртәгә туем була дип дәртләнеп, канатланып йөргәндә һәлакәткә юлыга..

Фольклор традицияләре буенча, көчле гашыйклар еш кына бер вакытта һәлак булалар. «Таһир – Зөһрә» дастанын гына искә төшерик. Тыңлаучылар Гайшә вафаты турында уйлаганда, билгеле инде, аның сөйгәне турында да уйланалар. Тормышта шундый хәл булгандырмы-юктырмы, безнең халык иҗатында «Гайшә матур белән гашыйк Камил бәете» дигән тагын бер әсәр барлыкка килә. Аны 1960 елда күренекле фольклорчы Илбарис Надиров Оренбург өлкәсенең Абдуллин районы Габдрахман авылында бер кульязма дәфтәрдән күчереп ала. Дөрес, Г. Ибраһимов исемендәге Институтның фольклор фондында бәетнең 1940 елда ук язылган варианты да бар. Ләкин И. Надиров варианты иң тулы һәм шигъри яктан иң матур булып санала. Шуңа күрә дә унике томлык «Татар халык иҗаты» җыелмасының «Бәетләр» томында әнә шул вариант урын алырга тиеш дип табыла (6, 325–326).

Табигый, ике бәеттә дә күп кенә сюжет элементлары кабатлана. Соңгы бәет беренчесеннән өч мәртәбә диярлек озынрак (15 әр иҗекле 17 юллык). Ул болай башланып китә:

«Гайшә матур үсә торгач Агыйделнең буенда
Басма сынып суга аккан язгы сабан туенда...
...Чәршәмбе кон кер юадыр, атна кичкә туй икән,
Озын чәчле, кара кашлы, нечкә зифа буйлы икән.
...Алтынланган яфрак алка елтыр-елтыр калкадыр,
Артындагы чулпы авыр, су төбенә тартадыр...»

Су буенда балаларның «Гайшә апа суга батты!» дип кычкыруларын ишеткәч, фаҗига урынына Камил йөгереп төшә. Гайшә белән туйлашырга тиеш егет шул үзе икән.

«...Килеп җиткәч, зирәк егет чумган җирен күзлидер,
Тәвәккәлләп суга кереп, чумып-чумып эзлидер.
Мескен егет күп йөргәч, арып талды хәлендин,
Җан сөйгәнен эзли-эзли аерылды җаныңдин.
Зирәк егет Гайшә кызны алыр өчен мал биргән,
Үлсәм дә бер күреп калыйм, диеп суда җан биргән».

Бәеттә, бер яктан, гашыйкларның фаҗигале һәлакәте өчен, кешеләргә хас булган әрнү, үкенү чагылдырыла,икенче яктан, аларның мәхәббәтен романтик биеклекккә күтәрү тенденциясе дә сизелә. Моны бәетнең вакыт ягыннан иң борынгы вариантында тасвирланган җан өшеткеч реаль картиналар фонында тагын да тирәнрәк күрәсең.

Иң беренче вариант дигәнебез 1840 елда төзелгән бер кулъязма җыентыкка теркәлгән. Аны, шуннан алып, профессор Хатип Госман һәм борынгы әдәбият белгече Зәйнәп Максудова үзләре төзегән «Татар әдәбяты тарихына материаллар» исемле җыентыкка керткәннәр (5, 42–44). Аңлашыла инде, андагы барлык текстлар гарәп графикасында, ләкин алар төзүчеләр тарафыннан кириллицага да күчерелгәннәр. Безне кызыксындырган текст «Илаһи бәет» дип атала, әмма кирилл язуында аңа «Суга баткан Гайшә бәете» исеме бирелгән. «Бәетнең бу редакциясе моңа хәтле (ягъни 1967 елга кадәр. – *К. И.*) матбугатта чыкмаган» дигән мөһим искәрмә дә ясалган. 1967 елдан соңгы бәет китапларында да ул күренми. Шулай булгач, бәет белгечләре тарафыннан әсәр әле әйләнешкә кертелмәгән дип уйларга да мөмкин. Хәзер Г. Ибраһимов исемендәге институтта 25 томлы фольклор җыелмасы әзерләнә. Аның 2 томы бәетләргә биреләчәк. Шуны да истә тотып, борынгы текстны биредә тулысынча бирү максатка ярашлырак булачак. Күзәтү уңайлы булсын өчен, строфаларга номерлар куйдык:

1. Зәбид берлән Хәлидкә
Керләр жуып менгердем.
Агун суга төшкәндин соң
«Алла!» диеп тилмердем.

2. Дүшәнбе көн керләр жудым,
Атна кичкә туй гынам,
Агун суга төшкәндин соң
Тимәде лә буйгынам.

3. Әткәемнең туры аты
Тауга каршы жигешле
Без фәкирләр кер жуган көн
Йаман җилләр килешле.

4. Кулымдагы беләзегем
Су төбендә йалтырый,
Әткәй домдан төшкән чакта
Йәш йөрәкем калтырый.

5. И туганым Габделгазиз,
Күрми калдым бән сәне,
Исеңә төшкән вакытларда
Йад әйләгел сән бәне.

6. Кулымдагы йөзек кенәм
Көнгә каршы эридер.
Ак көмештәй сүәк кенәм
Су төбендә черидер.

7. Башымдакы йаулыгымны
Йаман йилләр сүткәндер.
«Бәбкәм кер жуып кайта» дибүк
Әткәем, әнкәем көткәндер.

8. Хәсрәт өчен үскән икән
Бәнем зифа буйларым,
Шадлык белән күрми калдым
Язгы сабан туйларын.

9. Тал чыбыктай зифа буем
Фәлән йергә йеткәндер,
Йефәк берлән үргән сачым
Дулкын бәреб сүткәндер.

10. Кара кытат йөйатымны (?)
.......................... кимәңез.
Бәнем асыл сүәгемне
Каргалыдан эзләгез.

11. Агун суга төшкәндин соң
Бәнем урыным тар булды,
Кәфен сарыб куймак өчен
Әткәйем, әнкәйем зар булды.

12. Йалгыз кызны кер җуарга
Ник җибәрдең, әнкәйем?
«Китмә» дибүк әйткән булсаң,
Китмәс идем, әнкәйем.

13. Өстемдәге бишмәтемне
Салыб элдем ындырга
Ходай насиб итмәгән икән
Өйгә кайтыб йитмәгә.

14. Агун да суда агыб бара
Гайшәбикә башлары,
Әткәем берлә әнкәемнең
Түгеләдер йәшләре.

15. Дүшәнбе көн керләр жудым
Агун суның йанында,
Хәбибҗамал илереп җылый
Дулкын суккан чагында.

16. Башымдагы ак калпагым
Су өстендә йөридер,
Тулган ай тек нурлы йөзем
Су төбендә черидер.

Шулай итеп борынгы вариантның 16 строфадан торуын күрәбез. Беренчесе бүгенге текстта юк. Керләрне Гайшәнең Зәбид һәм Хәлид исемле кешеләргә юганы әйтелә – әмма аларның кемнәр икәне билгесез.

Икенче строфа шулай ук безгә билгеле түгел иде. Анда кер юган көн чәршәмбе түгел – дүшәнбе. Соңрак күрербез: унбишенче строфа да «Дүшәнбе көн керләр жудым» дип башлана. Димәк, элекке заманда чәршәмбе көндә кер юуга табу булмаган. Ә менә яңарак чорга караган «Гайшә матур белән Камил гашыйк» вариантында «Чәршәнбе көн кер юадыр, атна кичкә туй икән» диелә. Строфадагы «Тимәде лә буй гынам» дигәнне суны буйлый алмадым, чөнки аягым төпкә тимәде, дип аңларга кирәктер.

Борынгы строфаларның өченчесе дә «чәршәмбе көн кер юарга ярамый» дигән шомлану булганын расламый. Фәкыйрьгә кайсы көнне кер юса да, яман җил исә икән. «Хәерчегә җил каршы» мәкалендәге сыманрак.

Дүртенче строфа бик ук аңлашылып бетми. Әткәйнең өйдән (домдан) чыгып су буена төшүе турында сүз барамы?

Бишенче строфа бүгенге текстта юк. Гайшәнең Габделгазиз исемле туганы булган икән, ул аның белән бәхилләшә, бәетләргә хас булганча, васыятен әйтә.

Кайбер үзгәрешләр белән алтынчы строфа бүгенге текстның икенче строфасында кабатлана: су төбендә тал чыбыктай зифа буй түгел, ә ак көмештәй сөяк чери. Ике чагыштыру да бик тәэсирлеләр.

Сигезенче строфада Гайшәнең «шадлык белән күрми калдым язгы сабан туйларын» дип уфтануы өлешчә «Гайшә белән Камил»дә дә кабатлана: «Басма сынып суга аккан язгы сабан туенда».

Тугызынчы строфаның «Тал чыбыктай зифа буй» тәгъбире хәзер дә саклана. Аннан соң килә торган строфада танылмый торган сүзләр бар. Ә «бәнем асыл сөягемне Каргалыдан эзләгез» дигәндә Каргалы исемле елга күздә тотылса, андый бер елга Оренбургтан 18 чакрым төньяктарак, Каргалы бистәсе урнашкан урында Сакмар елгасына коя...

Унберенче строфада Гайшә, үзенең гәүдәсе табылмагач, әти-әнисенең аны кәфен сарып күмәргә зар булуларына кызгану белдерә.

Уникенче строфа тулысы белән диярлек бүгенге бәетнең беренче строфасында кабатлана. Ләкин мөһим бер момент: анда «чәршәмбе көн» бөтенләй телгә алынмый. Акцент Гайшәне кер юарга **ялгызын гына җибәрүгә ясала.** Логика буенча, бу чыннан фаҗиганең төп сәбәбе булырга мөмкин бит. Күрәсең, бәетнең йөзләгән тыңлаучылары, укучылары да шулай уйлаганнардыр, алар хыялда гына булса да ситуацияне «төзәтеп» караганнардыр. 1948 елгы экспедиция вакытында Татарстанның Мөслим районы Октябрь авылында З. Мөэминовтан мондый бер бәет язып алына. Аны шартлы рәвештә «Гайшә белән Фатыйма» дип атыйбыз (4, 353–354).

«Көннәр бик ямьле булса да,
Суның болганган чагы;
Бу ике яшь йөрәкнең дә
Бик тә дәртләнгән чагы.
Гайшә кергәрне чайкады,
Фатыйма бәләкләде;
Фатыйма кер меңгергәндә
Калын бозлар шартлады.
Гайшә чумды боз астына,
Аны бозлар каплады;
Фатыйма керләр күтәреп
Елый-елый атлады».










«Гайшә бәете» 1840 елда төзелгән кулъязма җыентыктан алынды (Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә саклана)

Сәнгатьлелек ягыннан бу вариант төп варианттан нык калыша, билгеле. Гайшә кер чайкарга үзе генә төшмәсә дә, финал шул ук: ул су төбенә китеп һәлак була. Күрәсең, бу вариант Гайшәнең «Ялгыз кызны кер җуарга Ник җибәрдең, әнкәем?» дигән үпкәле мөрәҗәгатенә бәйләнештә чыгарылгандыр. Анда «язмыштан узмыш юк» дигән нәтиҗә ясаладыр. Хер, фаҗига булмаса, бәет үзе дә туа алмас иде шул.

Борынгы вариантны күзәтүне дәвам итик. Аның унөченче строфасында «өстемдәге бишмәтемне салып элдем ындырга» түгел, «читәнгә» кирәктер. Мәгънә дә, рифма да шуны сорый. Ундүртенче строфа бүген сакланмаган. Унбишенче строфа да шулай. Ул Гайшә кебек суга батып үлгән Хәбибҗамал исемле башка бер кыз турындагы бәеттән килеп кергән булырга мөмкин. Уналтынчы строфа бүгенге икенче строфаның бик образлы, җан әрнеткеч варианты: су өстендә Гайшәнең ак калфагы йөзеп йөри, ә тулган ай күк йөзе су төбендә чери.

Шушы рәвешчә, кыскача чагыштырулар да «Суга баткан Гайшә» бәетенең вариантлары арасында эчтәлек җәһәтеннән дә, текстологик һәм поэтик яктан да бик күп уртаклыклар һәм үзгәлекләр булуын күрсәтә. Аерым бәетләрнең вакытлар үтү белән ничек үзгәрүен, эволюция кичерүен аңлауда бу бик гыйбрәтле мисал.

ӘДӘБИЯТ

1. Әдәбият белеме сүзлеге / Төз.-ред. А. Г. Әхмәдуллин. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1990. – 238 б.

2. Бакиров М. Х. Үзенчәлекле жанр буларак бәетләр / М. Х. Бакиров // А. Г. Яхин, М. Х. Бакиров. Фольклор жанрларын система итеп тикшерү тәҗрибәсе. – Казан ун-ты нәшр.,1972. – Б. 82–198.

3. Бәдигый Х. Сайланма хезмәтләр: Татар халык иҗаты әсәрләре / Хуҗа Бәдигый. – Казан: Иман, 2001/1422. – 256 б.

4. Бәетләр / Текстларны әзерләүче, аңлатмалар һәм кереш сүз авторы, төзүче Х. Ярми; СССР ФА КФ ТӘТИ. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1960. – 388 б.

5. Татар әдәбияты тарихына материаллар: Татар әдәбияты тарихыннан студентларның практик дәресләре өчен уку материалы / Әзерләүчеләр Х. Госман һәм З. Максудова. – Казан ун-ты нәшр., 1967. – 99 б.

6. Татар халык иҗаты. Бәетләр / Төзүчеләр, кереш мәкалә һәм искәрмәләр әзерләүчеләр Әхмәтова Ф. В., Надиров И. Н. һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 340 б.

7. Татарский эпос: Баиты. Автор вступительной статьи, комментариев и словаря Ф. В. Ахметова-Урманче. Тексты на татарском и русском языках. –Казань: Фән, 2005. – 544 с.

8. Урманче Ф. Лиро-эпос татар Среднего Поволжья: Основные проблемы изучения баитов / Фатых Урманче. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2002. – 256 с.

***И. Я. Илаев***
***Казан***

## ТАТАР ТЫЛСЫМЛЫ ӘКИЯТЕНДӘ ЕЛАН ОБРАЗЫ

Тылсымлы әкияттәге персонажлар гаять күптөрле. Алар барысы бергә образлар системасын тәшкил итә. Фантастик затларның күбесе – мифологик персонажлар. Шулар арасында әкият героеның ярдәмчеләре сыйфатында катнашучылар да (тылсымлы ат, күгәрчен, аккош, бөркет, ак бүре, сәмруг кош һ. б.), геройның дошманы буларак сурәтләнүчеләр дә бар (убырлы карчык, шайтан, дию, җен, пәри, җалмавыз һ. б.). Ләкин, ике табигатьле персонажлар да була, ягъни алар геройның антиподы сыйфатында да, ярдәмчесе сыйфатында да очрый (мәсәлән, елан, убырлы карчык, дию һ. б.). Фольклорчы Л. Җамалетдинов фикеренчә, татар әкиятләрендәге мифологик персонажлар арасында елан, популярлыгы буенча, диюдән генә калып, икенче урынны били (9, 18). Биредә без нәкъ менә елан образын тикшерәбез (1).

Күренекле фольклорчы Ф. Урманче үзенең хезмәтләрендә елан персонажына зур игътибар бирә, аны мифологик образ буларак тикшерә. Үзенең өч томлык энциклопедик сүзлегендә еланны халыкара мифологиянең һәм фольклорның иң борынгы, үз тарихында капма-каршы үзгәрешләр кичергән үзенчәлекле, катлаулы һәм каршылыклы персонажы; җирнең уңыш бирү, хатын-кызларның бала табу көче символы, ир-егетләрнең киләчәк буын вәкилләрен дөньяга китерү мөмкинлеген тәэмин итүче көч дип бирә (2, 32–38).

Елан образының әнә шундый күренешләр символы буларак барлыкка килүе кайчандыр Африка, Азия, Америка, Австралия илләрендә яшәүчеләрнең югары палеолит чорында (б. э. к. X меңьеллыкта) таралган дини карашлары белән бәйләнгән. Дөнья халыклары әкиятләрендә, мифларында елан образы күп төрле символлар буларак чагыла. Мәсәлән, еланны уңыш символы дип санауның башы б. э. к. VI–IV меңьеллыкларга карый һәм иң элек Көньяк-Көнчыгыш Европа илләрендә тарала. Зур акыллылык, хикмәт иясе символы булуы исә Крит-Микена мәдәниятенә барып тоташа. Борынгы Һинд мифологиясендәге Дөнья еланы Шеша Җирне үз җилкәсендә тотып тора. Шуңа якын карашлар Борынгы Мисыр һәм Скандинавия халыклары мифларында да бар. Борынгы Грециядәге дәвалау алласы Асклепий дә елан рәвешендә булган. Борынгы халыклар мифологиясендә елан – Җир асты һәм Су асты патшалыкларының, Үреләр дөньясының да хуҗасы. Шул рәвешчә, елан һәм аның образы

гасырлар буена дөнья халыкларының мифологиясендә һәм әкиятләрендә яшәп килгән. Һәрбер халыкның иҗатында елан үзенә күрә бер символны тәшкил иткән, мәгънәгә ия булган.

Бик күп халыкларның әкиятләрендә елан, бары тискәре персонаж буларак, кешенең дошманы итеп сурәтләнә, һәм әкият герое, әлеге елан белән аяусыз көрәшкә чыгып, аны һәлак итә.

Рус халык әкиятләрендәге елан образын В. Пропп дүрт төркемгә бүлә: урлаучы елан (змей-похититель), ришвәтче елан (змей, занимающийся поборами; «поборы змея»), чикләрне саклаучы елан (змей – охранитель границ), йотучы елан (змей – поглотитель) (3, 199–201).Ләкин татар әкиятләрендәге елан образына карата бу күренеш туры килми, чөнки аларда еланның функцияләре башка. Урлаучы елан вазифасын татар әкиятләрендә дию (аждаһа) башкара. Ришвәтче елан, татар әкиятләрендә булса да, бик сирәк (мәсьлән, «Алтын башлы, көмеш беләкле» исемле әкияттә). Чикләрне саклаучы елан вазифасы да диюгә йөкләнгән, йотучы елан татар әкиятләрендә, гомумән, очрамый. Шулай итеп, татар әкиятләрендәге елан образын рус, украин һәм белорус әкиятләре өчен характерлы булган әлеге биш төркемнең берсенә дә искәрмә ясамый гына кертеп булмый (9, 19).

Татар әкиятләрендәге еланнарның түбәндәге билгеләрен аерып күрсәтергә була: мәсәлән, тылсымлы әкиятләрдә төсләре буенча түбәндәге еланнар очрый: ак елан, кара елан, кызыл елан, яшел елан һәм ут еланы. Ләкин шактый гына әкиятләрдә аларның төсләре күрсәтелми. Шулай ук әкият героеның елан белән очрашу урыны да төрле булырга мөмкин: суда, урманда, агач төбендә, агач башында, юлда, шәһәр янында, җир астындагы дөньяда, анадан туган вакытта. Ә кайбер әкиятләрдә еланнар – эпизодик персонажлар, аларның очрау урыннары да аталмый.

Елан образы күп очракта иран мифологиясеннән кергән аждаһа образы белән кушылган. Шуңа күрә бу персонаж кайбер әкиятләрдә аждаһа-елан дигән кушма исем белән дә йөртелә. Аждаһа – геройның дошманы. Ул күбесенчә берничә башлы итеп сурәтләнә (әкиятләрдә ике, өч, дүрт, алты, тугыз, унике башлылары очрый). Аждаһа әкиятләрдә бары тик дошман персонаж итеп сурәтләнсә, елан уңай да, тискәре дә була. Уңай тип еланнар күбрәк очрый һәм алар башлыча бүләк бирүче, ярдәм итүче буларак сурәтләнә («Елан патшасы Шаһмара», «Ярлы егет белән патша кызы», «Аучы егет белән асрау кыз», «Ак елан» һ. б.).

Гомумән, татар тылсымлы әкиятләрендәге елан образларын вазифалары ягыннан нигездә өч төркемгә бүләргә мөмкин: ярдәмче елан, сак-

чы елан, кыз таләп итүче елан. Елан образын шушы бүленешкә таянып карап үтик.

Ярдәмче еланга килгәндә, әлеге төркемгә кергән еланнар бәлагә тарган геройга ярдәм итә яки аңа бәладән котылырга булыша торган тылсымлы әйберләр бирә, я булмаса, «Елан патшасы Шаһмара» экиятендәге кебек, кешегә биологик яктан да файдалы булуын раслый. Герой, ак еланны кайнатып, суын эчә һәм хайваннар телен аңлый башлый. Ә авыру патша, елан итен ашагач, сәламәтләнеп, «элеккедән дә тазара төшә». Биредә хайваннар өстеннән хакимлек итү өчен , шулай ук төрле авырулардан савыгу өчен тотем итен авыз итү кебек бик борынгы йола чагыла (4, 37).

Ярдәмче елан ролендә экиятләрдә еш кына ак елан күренә. Мәсәлән, «Ак елан» дигән экияттә геройга хан үзенең төшен юрарга куша, әгәр юрый алмаса, аның башын кисәчәген әйтә. Юлда очраган Ак елан геройга, ул хан янына барганчы ук, ханның нинди төш күргәнлеген әйтеп җибәрә, шулай итеп аны үлемнән коткарып кала. Бу хәл өч мәртәбә кабатлана һәм Ак елан үзенең хезмәте өчен сораган алтыннарын да алмый.

Ак елан персонажының һәрвакыт уңай образ итеп сүрәтләнүе турында Каюм Насыйриның шушындый фикере бар: «Татар экиятләрендә еланнар түбәндәге сыйфатларда биреләләр: барлык еланнар кара төстә булып, аларның патшалары гына ак була. Кара еланнар аларга дошман булалар, аны яратмыйлар. Ак елан аны яклый, ярата, алдан хәбәр биреп, аңар төрле файдалар китерә» (5, 46). Белгәнебезчә, фольклорда ак төс изге, илаһи нәрсәләрне билгеләү өчен кулланыла.

Ярдәмче елан турындагы сюжетлар башка төрки халыкларда да бар. Мәсәлән, башкорт экияте «Быжыр Мәргән»дә (6, 101; 102; 128; 135). башкорт халкының «Көтүче егет» экиятендә, еланны бәладән коткарган өчен, еланның атасы егетне кошлар һәм хайваннар телен аңларга өйрәтә (7, 244; 252). Әлеге мотив казакъ халкының «Таласпай Мерген» экиятендә дә очрый. «Сылубикә белән Яркәй» экиятендә Сылубикә этисе тарафыннан үтерелгән Яркәйне Үле һәм Тере еланнар ярдәмендә терелтә. Казакъ халкының «Ер-Төстик» дип аталган дастани экиятендә дә Канатлы елан батырны төпсез упкыннан алып чыга (8, 152; 154).

Тискәре тип еланнар татар экиятләрендә күп очракта – эпизодик персонажлар, һәм алар башлыча сакчы вазифасын үтиләр («Утыз ул», «Нурсылу» һ. б.). Сакчы еланнар – диюнең шәһәрен, ныгытмасын яисә аның үзен саклаучы булып сурәтләнә. Сакчылык вазифасы һәм шуңа бәйле рәвештә кешеләргә куркыныч тудыру үзе генә әле бу еланнарны кешенең дошманы итеп санарга хокук бирмәс иде. Чөнки алар, дию яисә аждаһа

кебек, кешене урлап китмиләр, ашар өчен дә таләп итмиләр. Әлбәттә, алар усал, рәхимсез. Әмма сакчы шундый булырга тиештер дә. Сакчы еланнарның кешегә дошманлыгы бары бәхетле финалның булмавы белән раслана, чөнки алар кешенең явыз дошманы – диюгә хезмәт итәләр, һәм әкият героена еланны үтерергә яисә буйсындырырга туры килә. Шулай итеп, геройның антиподы буларак, сакчы еланнар тискәре типлар рәтенә керә.

Эпизодик елан сакчы булмаска да мөмкин. Мәсәлән, «Серле дага» дигән әкияттәге еланнар гади ерткычлар итеп кенә сурәтләнә. Ләкин бу – татар әкиятләрендә үтә сирәк күренеш.

Эпизодик булмаган елан исә еш кына кыз таләп итә. Әмма, кызны нинди максат белән таләп итүгә карап, бу төркем еланнар икегә бүленә. Аларның беренчесе – әкиятләрдә сирәк очрый торган кыз ашаучы елан («Алтын башлы, көмеш беләкле»). Бу очракта елан кешенең явыз дошманы итеп сурәтләнә. Мәсәлән, «Алтын башлы, көмеш беләкле» дигән әкияттә, өч башлы елан һәр көнне бер кызны ашый. Чират патша кызына җиткәч, герой аларның шәһәренә килеп юлыга һәм кызны коткарырга юнәлә. «Шуннан тотыналар болар сугышырга. Егет җыланны турый да, башын кисеп, аска куя, койрыгын – өскә. Бик зур өем була бу».

Кыз таләп итүче еланнарның тагын бер төре – әкиятләрдә шактый еш очрый торган хатынлыкка кыз таләп итүче елан («Өч бүләк», «Зөһрә», «Җыланчай» һ.б.). Бу тип еланнар соңыннан һәр очракта егеткә әвереләләр һәм, әлбәттә, тискәре образ булудан туктыйлар. Шушы җәһәттән «Өч бүләк» дигән әкият үзенчәлекле. Бу әкияттә елан, беренче чиратта – сакчы. Алма өзеп алучы кешедән алма бәрабәренә аның кызын таләп итә. Соңыннан елан егеткә әверелә. Егет белән кыз, килешеп, бергә гомер итә башлыйлар, һәм елан уңай образ булып кабул ителә. «Зөһрә» әкиятендә дә елан, кызны ата-анасыннан көчләп алып китсә дә, асылда игелекле, гаилә җанлы булып чыга. Соңыннан елан кызның энисе тарафыннан хаксызга үтерелгәч, аның хатыны һәм өч баласы кайгырып елашалар, еланны җирлиләр, аннан соң үзләре төрле кошларга әвереләләр.

Шулай итеп, татар тылсымлы әкиятләрендә елан һәм уңай, һәм тискәре тип була ала. Елан образының әнә шулай сурәтләнүенә аның, бер яктан, борынгы заманнарда изгеләштерүе сәбәп булса, икенче яктан, чынбарлыкта кеше өчен куркыныч, зарар китерүче зат булуы да чагылган. Татар әкиятләрендә уңай тип еланнар күбрәк очрый. Геройга кыз ашаучы, ә кайвакыт сакчы еланнар белән сугышырга туры килсә дә, тулаем алганда еланнар белән сугышу татар әкиятләре өчен хас түгел.

ӘДӘБИЯТ

1. Фактик материал чыганагы итеп, түбәндәге китаплар файдаланды: Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Беренче китап / төз.: Х. Гатина, Х. Ярми. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1977. – 482 б.; Татар халык иҗаты: Әкиятләр. Икенче китап / төз.: Х. Гатина, Х. Ярми. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1978. – 447 б.

2. Урманчеев Ф. И. Татар мифологиясе: Энциклопедик сүзлек. 3 томда. – Т. II. – Казан, 2009. – 360 б.

3. Пропп В. Я. Исторические корни волшебной сказки. – 1946. – 509 с.

4. Соколова З. П. Культ животных в религиях. – М., 1972.

5. Насыйри К. Сайланма әсәрләр. ике томда. – Т. II. – Казан. – 1975.

6. Башкорт халык иҗады: Әкиәттәр: 1 нсе китап / төз.: М. Минһаҗетдинов, Ә. Харисов. – Өфө, 1976. – 435 б.;

7. Башкорт халык иҗады: Әкиәттәр: 2 нсе китап / төз.: М. Минһаҗетдинов, Ә. Харисов. – Өфө, 1976. – 453 б.

8. Каскабасов С. А. Казахская волшебная сказка. – Алма-Ата. – 1972.

9. Җамалетдинов Л. Тылсымлы әкиятләрдә елан белән бәйле мифологик образлар // Борынгы татар фольклоры мәсьәләләре. – Казан, 1984. – Б. 17, 36.

***Н. Н. Насыйбуллин***
***Казан***

# ПӘЙГАМБӘРЛӘР. КЕМНӘР АЛАР?

Пәйгамбәр (фарс.) – Аллаһы Тәгаләнең илчесе, алдан хәбәр итүче, Аллаһы Тәгаләнең хөкемнәрен, әмерләрен, хәбәрләрен, тыюларын кешеләргә тапшыру өчен үзе белән коллары арасында арадашчы сыйфатында җибәрелгән һәм әхлакның барлык гүзәллекләренә ия булган гадәттән тыш заттыр (1). Пәйгамбәрләрнең санына килгәндә, галимнәрнең фикере төрле. Күп кенә галимнәр дөньяда барлыгы 124 мең пәйгамбәр булган дигән фикердә торалар. Әмма бары тик 25 пәйгамбәрнең исеме генә изге «Коръән» китабында чагыла. Беренче пәйгамбәр булып Адәм, ә соңгы пәйгамбәр Мөхәммәд дип санала. Шунысы бик мөһим, дөньяга килгән барлык пәйгамбәрләр дә ир-ат булганнар. Шулай ук хәдисләрдә тагын Шис һәм Хыдр пәйгамбәрләре искә алына. Изге «Коръән» китабында Үзәер, Локман һәм Зөлкәрәен турында аятьләр бар, әмма алар пәйгамбәр булганмы яки ислам диненең изге хәлифләреме, билгесез. Һәрбер пәйгамбәр исеменнән соң *галейхиссаләм (г. с.),* ә Мөхәммәд пәйгамбәрнең исеменнән соң *саллаллаху галейхи ва салләм (с. г. в.)* дип әйтү кирәк дип санала.

Пәйгамбәрләрнең барысы кешеләрне дөрес юлга өндәгәннәр. Аларның әйткән сүзләре хак, дөрес һәм беркайчан да ялган булмаган. Аларга хас тагын бер сыйфат ул – ышанычлылык. Кешеләр узләренең малларын, пәйгамбәрләргә ышанып калдырып китә торган булганнар. Пәйгамбәрләрнең күбесе халык тарафыннан кабул ителмәгәннәр. Аларны рәнҗеткәннәр,кыйнаганнар һәм мыскыл иткәннәр. Ибраһим пәйгамбәрне утта яндырмакчы булганнар, Йосыф пәйгамбәрне туган абыйлары коега ташлыйлар, Мөхәммәд пәйгамбәр намаз укыганда аркасына дөя эчәгеләрен куялар һ. б. Барлык авырлыкларга да карамастан, алар Аллаһ Тәгаләнең бөтен хәбәрләрен дә халыкка җиткергәннәр. Акыл ягыннан да пәйгамбәрләр галимнәрдән өстен торган. Күп кенә галимнәр алар янына киңәш сорап килә торган булганнар. Шулай ук пәйгамбәрләргә гөнаһсызлык сыйфаты да хас. Әмма шуны әйтергә кирәк: Аллаһ хәбәрчеләрнең иң соңгысы булган Мөхәммәд, башка пәйгамбәрләрдән тагын түбәндәге сыйфатлары белән аерылып торган. Беренчедән, ул дөньяга килгән барлык пәйгамбәрләрдән дә өстен тора. Икенчедән, ул кешеләр өчен генә түгел, ә җеннәр өчен дә пәйгамбәр. Өченчедән, ул барлык дөньяга мәрхәмәт таратучы булып җибәрелгән. Дүртенчедән, аның аша җибәрелгән шәригать һәм дини кануннар кыямәт көненә кадәр саклаcard һәм башкарылачак. Мөхәммәд пәйгамбәрнең кыяфәтенә килгәндә, Али (р. а) түбәндәгечә аңлата: *«Ул озын да, кыска да буйлы түгел иде. Чәчләре бик бөдрә дә, бик туры да булмаган. Балкып торган түгәрәк матур йөзле иде, күзләре кара, керфекләре калын һәм озын булган. Җилкәләре киң, сөякләре каты иде. Кешегә борылган вакытта, башы белән генә түгел бөтен тәне белән борыла торган булган...»* (2). Һәрбер пәйгамбәр дә кешеләрдән төрлы сыйфатлары белән аерылып торган. Бу сыйфатларның берсе – могҗиза күрсәтү. Мәсәлән, Ибраһим пәйгамбәрне утка ташлаганнан, ут аның өчен матур бер җәннәт бакчасына әверелә. Муса пәйгамбәр таякны еланга әвереләдергән. Гайсә пәйгамбәр балчыктан кош формасын ясап, аңа өргеч ул чынга әверелеп очып китә торган булган. Мөхәммәд пәйгамбәр айны икегә ярган, кешеләрне терелткән һ. б.

Коръәндә һәм башка изге дини китапларда пәйгамбәрләр бик еш кына искә алына, алар соңыннан халык иҗатының, язма әдәбиятның популяр персонажларына әвереләләр. Шулай ук алар турында күп кенә фильмнар да төшерелгән. Мәсәлән, Америка режиссёры Ричард Ричның 2002нче елда *«Мөхәммәд, сонгы пәйгамбәр»* дигән фильмы дөнья күрә. Ә инглиз режиссёры Джон Хэйман 1979 нчы елда *«Гайсә»* исемле фильмны төшерә. Әлеге кино 1000 артык телгә тәрҗемә ителә. Шулай ук татар

теленә тәрҗемә ителгән варианты да бар. 1995нче елда режиссер Роджер Янгның *«Муса пәйгамбәр: коткаручы патша»* дигән фильмы, ә 1999 елда Роберт Марковицның *«Давут: идеал җитәкче»* исемле кинолары төшерелә (3). Мостафа Аккада 1977 елда *«Мөхәммәд – Аллаһның илчесе»* дигән фильм чыга. Бирердә, башка фильмнарда кебек үк, Мөхәммәд пәйгамбәрнең йөзе күрсәтелми, чөнки шәригать кануннары рөхсәт итми. Тагын бер кызыклы факт: әлеге фильмга көй язучы Морис Жарр «Оскар» премиясенә тәкъдим ителгән кандидатларның берсе була (4). Пәйгамбәрләрне өйрәнүчеләрнең саны шактый. Аларның күбесе аерым китап яза, шулай ук югарыда әйтелеп киткәнчә, пәйгамбәр образларын күренекле режиссёрлар үзләренең фильмнарында да күрсәтәләр. Дөнья күләмендә популяр булган Сами Йосыф һәм Йосыф Ислам дигән нашид (5) җырчылары пәйгамбәрләр, бигрәк тә Мөхәммәд пәйгамбәр турында җырлар башкаралар. Шулай ук «Раян» исемле татар төркеменең дә Мөхәммәд пәйгамбәргә багышланган җырлары бар.

Шуңа да карамастан, пәйгамбәрләр турында иң төп һәм иң мөһим мәгълүматны бирүче – ул изге «Коръән» китабы. Күп кенә язучылар һәм галимнәр пәйгамбәрләр турында язганда «Коръән» китабын чыганак итеп алалар. Мәсәлән, бөек шагыйребез Г. Тукай үзенең «Мираҗ» (1910) исемле шигырен язганда «Коръән» китабының 17 нче сүрәсенең беренче аятен һәм Рабгузыйның «Кыйссасел-әнбия» китабын куллана. Шагыйрьнең кайбер башка шигырьләре дә («Тә’сүр», «Кадер кич») «Коръән»нең аятләренә нигезләнеп язылган. Чит ил галимнәренә тукталсак, Габдел Хәмид Җуда Ал-Саххарның рус теленә тәрҗемә ителгән *«Пәйгамбәрләр тарихы»* дигән китабы мәгълүм. Әлеге әсәр мавыктыргыч сюжетлы, җиңел укыла. Шулай ук Шәех Тарик Ас-Сувайдан дигән башка авторның *«Пәйгамбәрләр һәм хәбәрчеләр тарихы»*дигән китабы билгеле. Безнен татар язучыларыннан Ф. Яхинның *«Пәйгамбәребез», «Олуг пәйгамбәр»* дигән китаплары бар. **Ниязеддин мулла Миңлеәхмәт әл-Хәнәфи**нең *«Балаларга пәйгамбәрләр тарихы»* исемле китабы 2010 елда басылып чыкты. *«Бу пәйгамбәрләр кыйссасын, кадерле вә газиз балалар өчен җиңел вә аңлаешлы итеп һәм дә булдыра алганча кыскартып язылды. Һәрбер пәйгамбәр кыйссасы азагында, балаларның аңлауларын ныгытыр өчен сораулар куелды вә кыйссадан алынган кайбер файдалар һәм гыйбрәтләрне билгеләп уздырылды»* – дип яза автор (6).

Гомумән әйткәндә, пәйгамбәрләрне безнең татар авторлары да, чит ил галимнәре дә бик күп өйрәнгәннәр. Әмма шунысы кызганыч, татар телендә бастырылган әсәрләр бик аз. Соңгы вакытта башка телләрдән тәрҗемә ителгән китаплар чыга башлады. Бигрәк тә, төрек авторларның

әсәрләре бик популяр. Киләчәктә, татар телендә дә пәйгамбәрләр турында китаплар басылыр дип көтеп калабыз.

ӘДӘБИЯТ

1. Arikan H. Ilmihal / H. Arikan. – Istanbul: «Din», 1995. – 134 s.
2. Золотой родник. – Москва, 2010. – № 2. – С. 33–34.
3. http://www.kinopoisk.ru/level/1/film/81279/
4. www.ru.wikipedia.org
5. Нашид – ир-ат тавышы белән башкарыла торган дини җырлар.
6. http://www.islamhouse.com/pr/330713

***А. Ф. Низаметдинова***
***Казан***

## ТАТАР ҺӘМ ИНГЛИЗ МӘКАЛЬЛӘРЕНДӘ «ИР» ҺӘМ «ХАТЫН» КОНЦЕПТЛАРЫ

Һәр халыкның үз аңында дөньяның сурәте яки дөнья моделе төрле мәгънә белдергән төшенчәләр ярдәмендә тудырыла һәм телдә дә шулар аша белдерелә. Логика күзлегеннән караганда, *төшенчә* – ул предмет яки күренешләрне һәм аларның сыйфатларын, үзара мөнәсәбәтләрен гомумиләштереп чагылдыра торган фикер берәмлеге. Телне мәдәният белән бәйләп өйрәнә торган лингвокультура фәнендә исә төшенчә урынына *«концепт»* дигән термин кулланыла (*conceptus* – латинча «фикер», «төшенчә», «төшенчәнең мәгънәләре»). Әдәбият белемендә, фольклористикада исә мондый фикер берәмлеге еш кына «тематика», «тематик төркем», «төшенчә төркеме», «образ» кебек терминнар белән белдерелеп килде. Әмма соңгы вакытта әлеге фән тармакларына тел гыйлемендә туган «концепт» сүзе дә үтеп керде һәм шактый актив кулланыла башлады.

Дөнья сурәте яки моделе күптөрле мәдәни һәм рухи-эмоциональ концептлар берлегеннән тора: дөнья һәм вакыт, халык һәм кеше, хезмәт һәм йола, мәхәббәт һәм гаилә, яхшылык һәм яманлык, акыл һәм наданлык һ. б. Бу концептлар бөтен халыклар өчен уртак булса да, милли культурасы һәм тәҗрибәсе, этник психологиясе һәм менталитеты белән бәйләнешле үзенчәлекләре чагылыш таба.

*Кеше* суперконцепты, үз чиратында, кешенең эшчәнлеге, рухи дөньясы, әдәп-әхлагы һәм башка өлкәләргә бәйләнешле ваграк концептларга бүленә. Гаилә тормышына «ир» белән «хатын» концептлары да шундыйлар рәтенә керә. Яшәү һәм үлем, бәхет һәм бәхетсезлек, үзеңнеке һәм

читнеке шикелле дуалистик капма-каршылыкка корылган төшенчәләр кебек үк, әлеге концептлар да ике төрле җенестән торган пар тәшкил итә. Безне бу очракта татар һәм инглиз мәкальләрендә ир белән хатын образларының ни рәвешле гәүдәләнүе һәм ничек бәяләнүләре кызыксындыра. Әлеге очракта сүз, асылда, ике милли-этник культурага караган гаиләләрдә ике затның тоткан урыны һәм бер-берсенә мөнәсәбәте, ата-анасы һәм җәмгыять алдындагы статусы турында бара.

Табигый инде, Бөек Британиядә яшәүче инглиз халкында да, шулай ук татарларда да өйләнешеп, гаилә корып яшәү хуплана һәм ир белән хатын, бербөтен итеп, бер-берсен тулыландыручы затлар итеп карала: «Ир белән хатын куш тирәк, төбе бер дә тамыры бер», «Ирләр хатынга мохтаҗ, хатыннар иргә мохтаҗ», «Ир – беләк, хатын – терәк»; «Marriages are made in heaven» («Никахлар күктә укыла»), «Men make houses, women make homes» («Ирләр йорт төзи, хатыннар өй бизи»).

Әлеге мәкальләрдә ир белән хатынның тормышта һәм гаиләдә тоткан урыны, статусы да күпмедер дәрәҗәдә сизелеп тора. Паремияләрнең бер өлешендә ике арадагы вазыйфа бүленешенә, кемнең күбрәк нинди роль үтәвенә яки үтәргә тиешлегенә аеруча басым ясала һәм турыдан-туры яки кинаяле, образлы итеп әйтеп бирелә: «Ирләр икмәк пешермиләр, хатыннар кала кормыйлар», «Ир таба, хатын тота», «Ир – келәт, хатын – йозак», «Ир – ат, хатын – арба», «Ир китерә белсен, хатын җиткерә белсен», «Ызба күрке – хатын, йорт күрке – ир»; инглизләрдә: «The grey mare is the better horse» («Соры бия – иң яхшы ат», ягъни «Өйдә хатын баш»). Хатын-кызлар белән ир-атлар өстенә йөкләнгән вазыйфаларның менә шулай икегә бүленеп каралуы һәм шуның фольклорда да чагылыш табуы күп гасырлардан килгән хезмәт бүленеше һәм яшәү нәтиҗәсе булып тора. Бу, әлбәттә, ир-егетләрнең физик яктан көчлерәк булуы белән бәйләнгән.

Гаилә бәхете һәр ике халыкта да яратышып торуга, мәхәббәткә бәйләп карала: «Сөеп алу, сөеп бару – Ходай язган эш», «Яратышкан ир белән хатын балта сабына ятып та йоклыйлар», «Мәхәббәтсез семья – тамырсыз агач»; «It is love that makes the world go round» («Дөнья белән мәхәббәт идарә итә»), «Love lives in cottages as well as in courts» («Мәхәббәт сарайларда да, алачыкларда да яши»).

Ләкин, Л. Толстой әйткәнчә, бәхетле гаиләләр бар да бер-берсенә охшаган була, ә бәхетсез гаиләләр – һәркайсы үзенчә бәхетсез. Моның сәбәпләре күбрәк тәрбиядән килә. Бөтен кеше дә яратырга, ныклы гаилә корырга сәләтле түгел. Син сайлаган, өмет баглаган кеше холыксыз яки үтә булдыксыз булып чыгарга да, эгоист яки деспот булырга да, гаиләсе

белән санашмыйча, күрәләтә яки астыртын рәвештә гаиләсенә хыянәт итү кебек гамәлләр кылырга да мөмкин. Мондый иргә яки хатынга карата тикшерү объекты булган һәр ике халык та үзенең мәкальләрендә тиешле хөкемен чыгара: «Усал хатыннан аждаһа курыккан», «Хатының яман булса, Газраилең шул», «Хатын бер ай чәчәк, гомер буе тигәнәк», «Ирем китте калага, мин киттем далага», «Ир көченә таяна, хатын теленә таяна», «Яман ир яхшы хатынны җир итәр», «Ирләр – сөекле дошманым», «Исерек ирне ир димә», «Уңмаган ир – уҗым бозавы», «Иргә бардым – имгәк алдым», «Иделгә таянма, иргә ышанма». Мондый мәкальләр тууында объектив сәбәпләр генә түгел, субъективлык та катнашкан.

Шушындый ук типтагы мәкальләрне инглизләр дә чыгарган: «I rather would a husband wed with a beetle drow than a beetle head» («Тинтәк ирдән ямьсез ир яхшырак»), «Better be an old man's darling than a young man's slave» («Яшь ир белән тәмугта яшәгәнче, карт ир белән җәннәттә яшәү яхшырак»), «It is a sad house where hen crows louder than the cock» («Тавык әтәчтән катырак кычкырган кетәклек яман», ягъни «Хатын баш булган өйдә хәл мөшкел»), «Better to live on the roof than share the house with a nagging wife» («Теңкәгә тиючән хатын белән иркен йортта яшәгәннән берүзең өй түбәсендә яшәвең артык»), «All are good lasses, but whence come the bad wives?» («Бөтен кәләшләр дә әйбәт, кайдан килә икән усал хатыннар?»).

Ләкин, безнең ачыклавыбызча, инглизләр һәм татарларның гаилә һәм ир белән хатын концептларына багышланган мәкальләренә арасында тарихи мохит һәм яшәү рәвеше белән бәйләнешле аерымлыклар да бар. Бу аерымлыкларның берсе – өйләнү, кияүгә чыгу вакыты. Феодаль тәртипләр өстенлек иткән элгәреге татар мохитендә ир-егетләр еш кына иртә өйләнә торган булган, чөнки ата-бабадан килгән традиция буенча ата кеше өлкән ир балаларын, мал бүлеп, һәм, кулыннан килсә, өй салып, башка чыгара һәм өйләндерә торган булган. Читтә акча эшләп кайта алса, өй салышуга егет кеше үзе дә өлеш керткән. Татар телендәге «өйләнү» сүзе менә шушы йоладан алынган һәм, димәк, «өйле булу» дигән мәгънәне дә белдергән. Кече, төпчек ул гына яки гаиләдә бердәнбер ир бала гына ата-ана йортында калган. Иртә өйләнүне хуплаган мәкальләр бездә шактый: «Ир өйләнми тәүфыйк тапмый», «Өйләнсәң, яшьли өйлән», «Иртә өйләнгән улыннан, кызыннан игелек күрер» яки:

Өйләнгәннең өе бар,
Баласы бар, көе бар,
Хатыны бар, ише бар.
Өйләнмәгәннең нисе бар?

Ә менә XVIII йөздә үк урбанизация, промышленность һәм шәһәрдә яшәүчеләр үсеш алган Бөек Британиядә, демократия һәм культура үсешенә бәйле рәвештә, гаилә кору вакыты, акрынлап, соңрак чорга чигерелә. Өйләнү ныклап аякка баскан, карьера ясаган дәвергә туры килә башлый. Мондый аерма күпмедер дәрәҗәдә мәкальләрдә чагылыш тапкан: «First thrive and then wive» («Башта йорт төзе, аннары өйлән»), «Hasty love is soon cold» («Ашыгыч мәхәббәт тиз суына», ягъни «Өйләнергә ашыккан соңыннан үкенер»), «Marry in haste and repent at leisure» («Өйләнергә ашыккан соңыннан үкенер»), «Bed her, but don't wed her» («Аның белән йокла, ләкин аңа өйләнмә»).

Һәм тагын бер аерма – монысы инде хатын кешенең җәмгыятьтәге һәм гаиләдәге хокуклары белән бәйләнгән. Бөек Британиядә хатын-кыз, чагыштырмача булса да, ирекле булган. Моны шагыйрь Р.Кеплингның хатын-кызны хакимлек һәм сугыш кебек куәтле төшенчәләр белән янәшә куеп сурәтләвеннән дә сиземләргә була: «Four things greater than all things are, – Women and Horses and Power and War» («Барысыннан да дүрт нәрсә куәтлерәк: хатын-кызлар, атлар, хакимлек һәм сугыш»).

Патриархаль тәртипләр сакланган элгәреге татар җәмгыятенә килсәк, анда хәл бөтенләй башкача. Авыл җирендә яшәгәнлектән, хатын-кызның җилкәсенә төшкән эш һәм вазыйфа ифрат күп, ә хокуклары юк дәрәҗәсендә булган. Патша хөкүмәте тарафыннан да ул авыр хәлгә куелган: яңа туган ир балага, киләчәктә гаилә башлыгы буласын исәпкә алып, аз булса да җир бүлеп бирелгән, ә кыз балага бирелмәгән. Шулай ук элек улны өйләндерү крестьян семьясы өчен гаиләгә яңа эшче кабул итүне дә күздә тоткан. Килен кешене караңгыдан караңгыга кадәр ат урынына эшләткәннәр һәм күп кенә гаиләләрдә үзенә кимсетеп караганнар. Килен кайнана белән яшәгән гаиләдә бу аеруча сизелгән. Өстәвенә, хатын иренә буйсынып, баш иеп яшәргә тиеш булган. Мондый карашның урнашуына, билгеле, консерватив карашлы кадими муллалар да йогынты ясаган. Шуны чагылдырган мәкаль үрнәкләре: «Иргә итәгать фарыз», «Ир хакы – Алла хакы», «Килен кеше – ким кеше, ана – байга тиң кеше», «Килен кеше чит булыр», «Килен салмасы килбәтсез була», «Кайнанага киленнең корсагы зур булып күренә». Хатын-кызлар элек менә шундый авыр хәлдә булганга күрә дә XX йөз башында татар җәмгыятендә аларның хокукларын ирләрнеке белән тигезләү өчен иҗтимагый хәрәкәт җәелдерелеп җибәрелүе бик табигый.

ӘДӘБИЯТ

1. Бабушкина А. П. Типы концептов в лексико-фразеологической семантике языка. – Воронеж: Изд-во ВГУ, 1996. – 104 с.

2. Воробьев В. В. Лингвокультурология. Термины и методы. – М.: Изд-во РУДН, 1997. – 331 с.

3. Добровольский Д. А. Национально-культурная специфика во фразеологической семантике языка // Вопросы языкознания. – 1997. – № 6. – С. 37–48.

4. Исәнбәт Н. Татар халык мәкальләре. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1963. – Т. 2. – 959 б.

5. Модестов В. С. Английские пословицы и поговорки и их русские соответствия / В. С. Модестов. – 5-е изд., стереотип. – М: Рус. яз. – Медиа, 2005. – 467, [13] с.

6. Ощепкова В. В. Язык и культура Великобритании. – М.: Наука, 2006. – 332 с.

7. Романов Ю.И. Культурология. – М.; СПб., 2006. – 287 с.

***Р. Р. Нургалиева***
***Казан***

## ЙОЛАЛАРДА ҺӘМ МӘКАЛЬЛӘРДӘ «КЫРЫК» САНЫНЫҢ ВАЗИФАЛАРЫ

Барлык халыкларның мәкаль-әйтемнәрендә, йола-ышануларында саннар һәм эчтәлек, һәм шигъри төзелеш җәһәтеннән бик әһәмиятле урын алып торалар. Фольклорда аеруча еш кулланылган хикмәтле саннарның берсе, һичшиксез, *кырык* саны. Аның конкрет мәгънәләрен күзәтүгә күчкәнче, бу санның этимологиясе, ягъни ничек барлыкка килү турындагы кайбер фикерләр белән танышып үтик.

Акад. В. А. Гордлевский борынгы төрки халыкларда *кырык* төгәл сан белдермичә, әйберләрнең күп булуын гына күрсәткән, һәм сүз ахырындагы «*к*» авазы күплек кушымчасы булырга мөмкин дип карый. Аныңча, борынгы төрки шаманнар тормышында *кырык*, дини сүз буларак, зур роль уйнаган һәм бара-тора, дини мәгънәсен югалтып, тик күплек төшенчәсен белдерүче булып кына калган (3, 101).

Проф. Л. Җәләй *кырык – кырк – хырых* сүзен *кыр+ык* рәвешендә ике өлешкә аерып карарга тәкъдим итә. *Кыр* – тамыр сүз, ә *-ык* – кушымча. «*Кыр+ык* сүзенең күплек төшенчәсендә йөргәнлеген искә алганда, – дип яза ул, – без аның тамырын хәзерге телдәге ялан мәгънәсендә йөри торган *кыр* «поле» чик мәгънәсендәге *кыр+ый* «крайний» сүзләре белән бәйли алабыз» (3, 102).

Язучы һәм фольклорчы М. Мәһдиев тә Л. Җәләй карашын куәтли: «*Кырык* саны татар халкының авыз иҗатында күпчелек очракларда «бик күп», «чиксез» мәгънәсен белдерә. Күрәсең, борынгы халыклар арифметикасының билгеле бер этабында *кырык* санау чиге булган. Шуңа ба-

рып җиткәне яки артып киткәне – исәпсез-хисапсыз, бик күп, санап бетергесез дип уйланылган. Әгәр шулай икән, ихтимал, *«кыр»* сүзенең дә тамыры *кырык* белән уртактыр. *«Кыр»* да бит иксез-чиксез иркен басу, ялан мәгънәсен аңлата» (4, 48).

Күплек мәгънәсен белдерүче мәкальләрдән түбәндәгеләрне күрсәтергә мөмкин. Аларның күчерелмә мәгънәләре Нәкый Исәнбәт җыелмасында (6) бирелгән:

*Кызлар күңеле – кырык карта* (ягъни, кызлар күңеле күп катлы булып, сиңа бер катын гына күрсәтер, ниятләрен белеп бетерү авыр эш, дигәне);

*Өйләнмәгән егет кырык кызны алыр* (тегене алам, моны алам дигән хыялы күп булыр);

*Кырык бала тапкан, керер капка тапмаган* (күп бала үстереп тә, берсе дә кеше булмаган, игелек күрсәтмәгән була);

*Кырык ач әрвахка бер бөтен икмәк каян җитсен?* (варислар күп булып, мирас малы аз булганда әйтелә).

Шулай ук аз белән күп мәгънәләрен кискен төстә каршы куеп күрсәтү максатыннан *кырык* саны кулланылу очраклары да бар. Мәсәлән:

*Кырык ел тавык булганнан бер көн әтәч булганың артык;*

*Матурлыктан кырык көндә туялар, матур холыктан кырык елда да туймыйлар.*

*Өйне кырык ир тутырмый, бер хатын тутыра;*

*Ир бер сүзле, хатын кырык сүзле;*

*Бер балык башын кырыкка бүлеп булмый.*

Мәкальләрнең күбесендә чиктән тыш арттыру (гипербола) алымы кулланыла, һәм *кырык* саны әлеге алымны тагын да көчәйтеп җибәрә:

*Каты агач шарт сынар, черегән агач кырык ел чыдар;*

*Уңган кеше кылны кырыкка ярыр.*

*Кырык* саны татар фольклорында сакраль сан буларак, ягъни дини эчтәлекле тестларда да бик актив кулланыла, төрле ышануларда, ырымнарда очрый. Ул кешенең бер дөньядан икенче дөньяга күчүе – тууы һәм үлүе дәвам иткән вакыт исәбе. Туганда кешегә җан кырык көн эчендә иңә һәм үлгәндә кырык көн эчендә китә. Кырык көнлек күчеш чорында кеше тәненә мөнәсәбәттә бик сак булырга кирәк икән.

Бала тугач та кырык көн үтмичә, төнлә ут сүндерергә, баланы үзен генә калдырырга ярамый, чөнки аны җен алыштыра, диләр (зарурият туганда бишеккә пычак яки бүтән әйбер салып калдырырга кирәк). Бала кырык көне тулмас борын бик каты борчылса, моны йә авырый, йә исеме ошамый диләр. Бу очракта баланы өшкертеп, бөти яздырып алганнар

да, шуны түшенә такканнар. Аннан соң да борчылуы бетмәсә, исемен алыштырганнар. Шулай ук кырык көне тулганчы баланың чәчен кыркырга кушалар... (8, 118).

Ф. С. Баязитова «Гомернең өч туе» исемле хезмәтендә балага кырык көн тулгач үткәрелә торган йолаларны *кырыкламасын койу, кырыклату* дип атый:

– Кырыкламасын койа балаларына, кырык кашык су белән койондыра. Җанга айактан койа суны кыркламасына, кырык кат койа. «Кырыкламасын койган айак йахшы айак, үземә торсын, үзем үлгәндә ул айак белән су койарсыз өстемә», – дип алып куйа кырыкламасын койган айакны.

Үлгән кешенең рухы кырык көн буена өенә килеп-китеп тора. Мәрхүмне искә алу хөрмәтеннән аның «өчесен», «җидесен», «кырыгын», «елын» укыталар. Кырыгын укытканда үткәрелә торган кайбер йолаларны галимә түбәндәгечә сурәтли:

– Кырыгына кырык күмәч пешерәбез, койаш чыкканчы хәерен бирәсен, тугисын да коймак пешереп хәер кертәсен. Табакка саласын кырык күмәчне...

– Кыркысына кырык гәрдә эвәлиләр, җәйләү-җәйләү кәдәре була ул. Кырыгына ничә кеше килә, тәлинкәгә саласың инде.

*Кырык* саны ислам кануннарына да киң үтеп кергән. Шәригать мөлкәтнең кырыктан берен ярлыларга өләшүне хуплый. Мөхәммәд пәйгамбәр Аллаһы Тәгалә сүзен кырык яшендә ишеткән. Коръәндә «Мәетне күтәреп баручының кырык адымда кырык гөнаһы төшеп калыр» дигән сүз бар. Шуңа күрә мәет озатканда аны һәркем, кырык адым гына булса да, чиратлашып күтәреп барырга тырыша.

*Кырык* саны кергән мәкальләр, кагыйдә буларак, җитди йола, кагыйдә, канун хөкемендә кабул ителәләр. Хәлбуки, алар арасында сатира-юмор катнашканнары, ирония, киная белән әйтелә торганнары да аз түгел:

*Кырык төшнең берсе – пигамбәр төше, имеш* (кырыклаган булгач, ялганның да берсе дөрескә чыкса, гаҗәп түгел дигән мәгънәдә);

*Иң туры әйбер манара, аның да эче кырыкка кәкре;*

*Кыз егет башыннан бүреген алып кисә, кырык көнлек хатыны була, имеш* (элек кичке уеннарда кайбер үткен кызлар, егетләрнең башларындагы бүрекләрен үз башларына киеп шаярганнар);

*Бер балык башын кырык кат чәйнәмиләр* (бер үк сүзне күп тапкыр кабатлап әйтергә яратучыларга карата әйтелә);

*Эт бер сөренгәндә, кырык сөренер* (әрсез, битсез кешеләрнең эше бер рәтсезгә китсә, бәхетсезлеге дә бер-бер артлы була, дигәнгә мисал йөзеннән әйтелә);

*Сарымсакны килен иткәннәр – кырык көн исе чыкмаган* (начар кеше озак вакыт әйбәт булып кылана алмас, мәгънәсендә).

*Кырык* саны «күп» дигән көчерелмә мәгънәдә бик еш кулланылса да, ул үзенең туры (дүрт унга тигез) зурлыгын да «онытып бетерми». Мәсәлән, яңгыр теләү йоласы вакытында күпер өстенә кырык чиләк су сибү тиеш саналган. Кешене яше зурлыгы ягыннан сыйфатлаганда да төп-төгәл кырык ел турында сүз бара:

*Кырык яшьнең үз яме бар;*

*Яшем җитте кырыкка, эшем китте шырыкка;*

*Кырыктагы эшен кырып йөртер* (ягъни, нык тотар);

*Корышкан кырыкта ук карт булыр, җегәрле җитмештә дә яшь булыр.*

Мәрхүмнәрне җирләү, аларны искә алу йолаларында да (без аларга алдарак тукталып үттек) *кырык* саны үзенең реаль зурлыгында күздә тотыла: җеназаны нәкъ кырык адым күтәреп бару, вафатына кырык көн тулуны билгеләү, бу табынга кырык данә коймак пешерү һ. б.

Көнкүрештә еш кына шундый вәзгыять туып тора. Зиһенсез, онытучан, игътибарсыз кеше әле генә тоткан, үз тирәсенә генә куйган әйберен җир бетереп эзләсә дә таба алмыйча изалана. Андыйлар турында көлеп йә шелтәләп *«Кырындагын кырык көн эзләгән»* диләр. Ягъни, бик озак эзләгән. Ни өчен нәкъ менә *кырык көн, ә биш көн, җиде көн* түгел? Бу саннарның да бик озак дигән мәгънәләре бар бит. Чөнки монда доминант сүз *кырындагын*. Аңа эчке рифма кирәк. Ә моңа иң кулай сан – *кырык.* Шушы ук мәкальнең «Астындагын алты ай эзләгән» дигән синонимы да бар. Бу очракта рифманы *алты* саны тудырган. *Кырын-кырын ятсаң, кырык кеше бер сәкегә сыя; кырын эш кырык елдан соң да беленер* кебек мисалларда да *кырык* санына тукталу рифмалаштыру ихтыяҗы белән аңлатыла.

*Кырык* саны башка халыклар мәкальләрендә еш кулланыла, һәм ул башлыча күплек мәгънәсен белдереп килә:

*Бер көн сыйлаган өчен кырык көн рәхмәт укырга кирәк* (казакъ);

*Бер көн талашкан кырык көнлек дошман* (каракалпак);

*Начарлык кырык көннән соң да беленер* (кыргыз);

*Бер акылсыз ташны коега аткан, ә кырык акыллы аны тартып чыгара алмаган* (төрек);

*Арба җимерелер алдыннан кырык көн алдан шыгырдый башлый* (төрекмән);

*Йөрәгең киң булса, бер җимеш белән кырык кешене туендырырга мөмкин* (үзбәк) һ. б.

ӘДӘБИЯТ

1. Баязитова Ф. С. Гомернең өч туе (Татар халкының гаилә йолалары) / Ф. С. Баязитова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1992. – 295 б.

2. Баязитова Ф. С. Татар халкының бәйрәм һәм көнкүреш йолалары / Ф. С. Баязитова. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1995. – 158 б.

3. Җәләй Л. Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар) / Л. Җәләй. – Казан: Фикер, 2000. – 287 б.

4. Мәһдиев М. Кырыкның кырык мәгънәсе / М. Мәһдиев // Сайланма әсәрләр: 5 томда / төз. Г. Хәсәнова.– Казан: Татар. кит. нәшр. – Т. 5. – 2009. – 431 б.

5. Муратова Р. Т. Символика чисел в башкирском языке: Автореф. дис. ... канд. филол. наук / Р. Т. Муратова. – М., 2009. – 24 с.

6. Пермяков Г. Л. Пословицы и поговорки народов Востока / Г. Л. Пермяков. – М.: Наука, 1979. – 671с.

7. Татар халык мәкальләре / Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. Өч томда. – Казан: Татар. кит. нәшр., Т. 1. – 1959. – 913 б.; Т. 2. – 1963. – 959 б.; Т. 3. – 1967. – 1013 б.

8. Хадыева Р. Н. Башкорт теленең этнолингвистика сүзлеге / Р. Н. Хадыева. – Өфе: Башкорт. кит. нәшр., 2002.–176 б.

***Р. Ф. Хәкимов***
***Казан***

## ДАСТАН ҺӘМ ТАРИХИ ҖЫР: ЖАНРАРА БАГЛАНЫШЛАР

Татар фольклорында тарихи җырлар Идел-Чулман Болгарстаны, Алтын Урда дәүләте чорларында барлыкка килгән, яңа жанрның формалашуында дастаннар сизелерлек роль уйнаган дип санала. Тарихи җырларда конкрет реаль шәхесләр: күренекле ханнар, әмирләр, батыр яугирләр, Шәһре Болгар, Шәһре Кашан, Сарай Бату, Сарай Бәркә кебек атаклы калалар, күпсанлы сугышлар, әсирләр, коллар тормышы бәян кылынган. Аларны иҗат итүдә, халык арасында таратуда җырау-чичәннәр зур активлык күрсәткән. Җырауларның үз шәхесләре, үз язмышлары җырга нигез булган очраклар да бар. Гадәттә ханнар хезмәтендә булсалар да (Чыңгыз ханның олуг җырчысы, Туктамышның Субра җыравы һ. б.), аларның барысы да үз туган җирләрен басып алучыларны мактарга ашкынып тормаганнар һәм башларын да җуйганнар. Татар халык иҗаты җыелмасының «Тарихи һәм лирик җырлар» томында «Кунак бабай җыруы» дигән әсәр урын алган. Аны 1916 елда Новосибирск өлкәсенең Тара шәһәрендә Хафиз Рәхмәтуллин Гаффар исемле бер карт авызыннан язып алган була. Заманында партизан да булган, «Азат Себер» газетасын да җитәкләгән, мәктәп директоры да булып эшләгән бу кеше үзенең якташларыннан күп кенә фольклор әсәрләре дә язып ал-

ган. Шулардан «Атаклы кыз Тукбикә» дастаны һ. б. кайбер хезмәтләре М. Әхмәтҗанов тарафыннан нәшер ителгән (1, 23 сан).

«Моннан күп йөз еллар элек, – диелә "Кунак бабай җыруы"на Х. Рәхмәтуллин язган аңлатмада, – Аксак Тимер... Туктамыш ханга каршы сугыш ачкан. [Аның] яулары Туктамыш яуларын җиңеп, бик күп әсирләр алып кайтып киткәннәр. Әсирләр арасында Туктамыш кулында хибестә (төрмәдә) яткан Кунак исемле бер болгар җырчысы булган. Кунак Туктамышка каршы баш күтәргән болгар халкыннан икән. Ул Идел һәм Җаек буенда яшәгән халык арасында атказанган җырчы булган» (6, 7).

Ихтимал, Аксак Тимер Кунакны, үз каршына китертеп, аның кемлеге белән кызыксынгандыр. Чөнки әсәр сюжеты җырчының эпик автобиографиясе кебек төзелгән:

Йөз туксан биш яшь яшәдем,
Азу тешләрем ашадым,
Күпне күреп, күпне белеп
Гомер сөргән карт мин.
Иделдә үтте тугыз хан,
Җаекта үтте сигез хан.
Шул ханнарның барысын да
Күреп белгән карт мин.
Илне йоткан Туймас хан,
Юмарт булган Исәк хан,
Берсен сүгеп, берсен мактап,
Күп җырлаган карт мин».

«"Кунак бабай җыруы" эчке рухы, төзелеше, сурәтләре белән урта гасырларда туган шигъри дастаннарны хәтерләтә», – дип фараз итә И. Надиров (6, 8). Без моңа өстәп: «аерым строфалары, эпик клишеләре, уртак урыннары белән хәтта тәңгәл килә», – дип тә әйтер идек. Менә «Кунак бабай»ны «Идегәй» дастанындагы Субра җырау белән чагыштырып караудан күренә торган кайбер мисаллар (3, 55, 59, 60, 64):

Субра ерау анда әйтте.
... Йөз туксан биш яшәгән,
Җаны сөяге какшаган,
Азауларын тездереп,
Ак ефәк белән бәйләгән
Бер алҗыган картыңмын.

Камалның улы Киң Җанбай
Җавап биреп аны әйтте:
– Ак калада уйга бай
Йорт агасы Субрай,
Йөз туксан биш яшәдең,
Күпне күреп байкадың...

Анда әйтте Идегәй:
– Ак калада уйга бай
Йорт агасы Субратай,
Йөз туксан биш яшәдең,
Азау тешең ашадың,

Күпне күреп байкадың...
Субра аны җырлыйдыр:
Мин картыңмын, картыңмын,
– Күпне күргән картыңмын,
Ни күрмәгән картыңмын...

Әлбәттә, гаять озын гомер кичергән җырчының күргәннәрен аның үз заманында яшәгән төрле-төрле ханнарның мактаулы яки кыңгыр эшләренә шаһит булып, аларга халык, ил мәнфәгатьләреннән карап мөнәсәбәт белдерү тәшкил итә. Кунак бабай җырында конкрет тарихи шәхесләр

аталмый, аларның күплегенә генә ишарә ителә: Иделдә үтте тугыз хан, Җаекта үтте сигез хан һ. б. Инде «илне йоткан Туймас хан, юмарт булган Исәк хан»нар, күрәсең, эпитетлар йә кушаматлар булып торадыр. Билгеле, нибары алты строфалы җыр өчен болар да җитәрлек. Киң колачлы «Идегәй» дастанының исә мондый чикләүгә мохтаҗлыгы юк. Субра җырау анда 20 гә якын ханның исемен атый (шулардан бары дүртесе турында гына тарихта мәгълүматлар юк). Хәлбуки, Кунак бабай җыруында да, исеме аталмаса да, Аксак Тимергә турыдан-туры ишарә ясала.

Алда китерелә башлаган риваять болай дәвам итә. Көннәрдән бер көн Аксак Тимер Кунакны чакыртып әйтә:

– Әгәр мине мактап җырласаң, сине үтермим, – ди.

Кунак исә аның тәкъдименнән, хәзер анализлана торган җыру юллары аркылы, баш тарта:

«Энҗү дәрьяң киң дәрьядыр,
Бәңгиз дәрьяң мул дәрьядыр.
Мактыйм дисәм телем йөрми, –
Туры сүзле карт мин».

Энҗү, Бәңгиз (Бәнҗү) – Аму-Дәрья һәм Сыр-Дәрья елгаларының борынгы исемнәре. Ә Урта Азиядәге шушы ике елга аралыгындагы җирләрнең фактик хуҗасы нәкъ менә Сәмәрканд әмире Аксак Тимер булган. Башкача әйтсәк, бу елгаларның хуҗасына эндәшү бу инде Аксак Тимергә – тарихи шәхескә мөрәҗәгать итү булып чыга.

Хәер, риваятьнең әле үзендә дә тагын бер җыру (аның бер куплеты) китерелә. Ул строфа төзелеше, рифмалашу өлгесе, иҗек үлчәме белән, хәзер без күзәтә торган җыр текстыннан аерыла, ягъни фрагмент кына булса да, аны да китапларга мөстәкыйль әсәр буларак кертергә мөмкин. Анда Аксак Тимернең төп дошманы – көндәше Туктамыш та телгә алына:

«Илне йоткан Туктамыш,
Мактаганым юк аны.
Син дә илне йоткан хан –
Мактый алмыйм мин сине».

Шуннан соң, риваятьтә хәбәр ителгәнчә, Аксак Тимер җырчының башын кистергән (6, 8).

Аксак Тимернең үзе басып алган илләрдә яшәгән җырау-чичәннәр, гыйлем-хикмәт ияләре белән кызыксынуы, алардан файдаланырга тырышуы турында һәм легендар, һәм тарихи чыгынакларда телгә алына. Аның шәхси сәркатибе дә булган һәм аңа әмирнең барлык батырлыкларын теркәп, тарихка кертеп калдыру бурычы йөкләнгән. Үзен мактау өчен кирәкле кешеләрне Аксак Тимер, алда әйтелгәнчә, әсирлеккә төшкәннәр

арасыннан да эзләгән, аларның җырларын тыңлаган. Андый риваятьләрнең Алтын Урда чорына караганнары да бар. Менә шуларның берсе:

Аксак Тимер Идел буйларына һөҗүм итеп, Болгар шәһәрен алганда бик күп алтын-көмеш хәзинәләр һәм әсирләр кулга төшергән. Аннан ул: «Бу кулга төшкән кешеләр арасында хикмәт иясе кешеләр бармы?» – дип сораган. Аңа бу шәһәрдә бик хикмәт иясе сукыр бер шагыйрь бар икәнен сөйләгәннәр. Аксак Тимер аны үз каршына чакырткан. Сукыр шагыйрь *думбрасын чалып, аңа Болгарның данлы батырлары, байлыклары турындагы хәлләрне хикәя кылып җырлаган* (Курсив безнеке – *Р. Х.*). Аксак Тимер гаҗәпләнеп тыңлап торганнан соң, аның исемен сораган. [Җырчы]:

– Минем исемем Дәүләт, – дигән.

Аксак Тимер тапкыр телле кеше булган, көлгән дә:

– Шулай итеп, Дәүләт сукыр булды мыни?– дигән икән, сукыр шагыйрь аңа шунда ук җавап кайтарган:

– Әгәр Дәүләт сукыр булмаса, Аксак кулына кермәс иде, – дигән (7, 322).

Монда тарихи җырлар җәһәтеннән караганда игътибарны җәлеп итәрлек момент бар. Сукыр шагыйрь (чичән) думбрада уйнап, Болгарның данлы батырлары турында җырлый. Бераз фантазиягә ирек бирсәк, бу илдә «Шәһре Болгар газилары» дигән җыр да булганлыгын искә төшерергә мөмкин бит. Дөрес, әлеге әсәрне (аның исемен) борынгы Болгар чорына кертергә туры киләдер. Ләкин Аксак Тимер, шул җыр күздә тотылган тәкъдирдә, аны Алтын Урда составындагы Болгарда тыңлаган була түгелме соң?

«Кунак бабай җыры» да, Дәүләт чичәннең Болгар батырлары турындагы җыры да татар халкының патриотик хисләрен, яулап алучыга нәфрәтле-мыскыллы карашын чагылдыралар.

Татар фольклорындагы тарихи җырларны өйрәнүнең пионерлары М. Нигъмәтҗанов, Ф. Урманче, М. Бакиров, И. Надировлар тарихи җыр жанрының барлыкка килүендә дастаннарның билгеле бер роль уйнавын күрсәтәләр. Кайбер рус фольклорчылары рус халык аваз иҗатында тарихи җырларга карата моңа охшаш рольне *былина* жанры үтәгән дип саныйлар. Без дә шушы уртак карашка кушылабыз. Бу бигрәк тә «Идегәй» дастаны мисалында ачык күренә. «Кунак бабай җыруы»н күзәткәндә моңа инде игътибар ителгән иде. Әлбәттә, «Кунак бабай» үзенчәлекле сюжетлы, төп герое Субра җыраудан нык аерылып тора торган мөстәкыйль әсәр. Ул нәкъ менә җыр формасына салынган, күләме ягыннан кыска (алты гына строфалы), «Идегәй»гә, башлыча, үзендә кулланылган эпик килешләр, эпосларга хас уртак урыннар булуы белән генә якын.

Зур күләмле дастан эчендә, әлбәттә, тарихи җыр булып яңгырый ала торган, эпос тукымасыннан аерылып та яшәргә сәләтле өзекләр бар. Алар, гадәттә, җыраулар, чичәннәр авызыннан «сарнады», «тулгады», «җырлады» кебек синоним сүзләрдән соң әйттереләләр.

Дастанда Идегәйнең (Кобыгылның) бик күп сыйфатлары санала, шул җөмләдән аның чичән булуына да игътибар ителә (ирене юка күренә – чичән икән Кобыгыл). Менә, безнеңчә, «Идегәй җыруы» дип атарга мөмкин булган бер өзек. Ул Идел-Җаек буйларын сагынып кайткан Идегәй тарафыннан тулгана (3, 132–133):

– И Идел-йорт, Идел-йорт,
Идел эче имин йорт,
Атам кияү булган йорт –
Иелеп тәгъзим кылган йорт;
Анам килен булган йорт –
Иелеп сәлам әйткән йорт;
Кендегемне кискән йорт,
Керем-коңым юган йорт...

Идел – Җаек арасы
Елкы белән тулган йорт,
Казан – Болгар арасы
Кала белән тулган йорт;
Ашлы белән Ибраһим
Ашлык белән тулган йорт,
Ата-бабам токкан йорт,
Котлы булсын туган йорт!

Шәһре Болгар, Шәһре Кашан кебек мәшһүр калаларны данлаган мәдхияләр фольклор галимнәре тарафыннан тарихи җырлар рәтеннән күралалар. Дастанның хәзер китерелгән өзеге әле XIX йөз урталарында ук Әстерхан татарлары арасында җыр-тулгау буларак башкарылып йөргән. Күренекле тюрколог И. Н. Березин (1818–1816) аны үзенең ике томлык «Турецкая хрестоматия»сенә дә урнаштырган (7, 64).

Бу шигъри текстның бүгенге яңа язмышы турында да әйтми калу мөмкин түгел. Җыр жанры буенча танылган белгеч К. Миңнуллин «Һәр чорның үз җыры» монографиясендә болай яза: «Идегәй дастаныннан Идегәйнең:

«И Идел йорт, Идел йорт,
Идел эче имин йорт...» –

дип башланган кабатлауларга бай монологы, композитор Р. Әхъярова көйгә салганнан соң, бик популяр лирик, шул ук вакытта патриотик җырга әверелде» (4, 248). Әлбәттә, бу цитатадагы «патриотик» дигән сүзне халкыбызның тарихи хәтерендә борынгы Болгар, Алтын Урда дәүләтләре чорыннан ук сакланып килә торган кайнар ватанчылык хисе дип тә аңларга кирәк.

Аерым дастаннарның фрагментлары тарихи җырлар репертуарына күчеп яшәүгә мисалларны башка кайбер эпик әсәрләрдән дә табарга мөмкин.

ӘДӘБИЯТ

1. Әхмәтҗанов М. Фольклорчы Хафиз Рәхмәтуллин / М. Әхмәтҗанов // Татар иле. –2005. – 23, 24 саннар (июнь).

2. Бакиров М. Х. Татар фольклоры. Югары уку йортлаы өчен дәреслек / М. Х. Бакиров. – Казан: Мәгариф, 2008. – 359 б.

3. Идегәй. Татар халык дастаны / Кереш мәкалә язучысы И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1988. – 254 б.

4. Миңнуллин К. М. Һәр чорның үз җыры / К. М. Миңнуллин. – Казан: Мәгариф, 2003. – 400 б.

5. Нигъмәтҗанов М. Ерак чыганаклар / М. Нигъмәтҗанов // Совет әдәбияты. – 1963. – № 2.

6. Татар халык иҗаты. Тарихи һәм лирик җырлар / Төзүче, кереш мәкалә һәм искәрмәләр язучы И. Надиров. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1988. – 488 б.

7. Татар халык мәкальләре: өч томда / Җыючысы һәм төзүчесе Н. Исәнбәт. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1967. – Т. 3. – 1014 б.

8. Урманче Ф. Татар халык иҗаты / Ф Урманче. – Казан: Мәгариф, 2002. – 335 б.

***Т. И. Усманова***
***Казан***

## ФӘНИС ЯРУЛЛИННЫҢ «ҖИЛКӘННӘР ҖИЛДӘ СЫНАЛА» ПОВЕСТЕНДА ФОЛЬКЛОР МОТИВЛАРЫ

Билгеле ки, һәр әдәбият халык авыз иҗатыннан башлана. Нәкъ менә шунда теге яки бу милләтнең тарихы, яшәү рәвеше, идеаллары, күңел дөньясы, омтылышлары, дөньяны үзенчәлекле күзаллавы чагылыш таба. Әкиятләр, мәкаль-әйтемнәр, җырлар, халык авыз иҗатының башка жанрлары язма әдәбият әсәрләренә дә халыкчанлык рухын бирүдә бик әһәмиятле роль уйныйлар. Шуңа күрә фольклорны милли компонент сыйфатында куллану халык рухын, аның яшәешен сурәтләгән әсәрләрдә мөһим чара буларак карала. Фольклор мотивлары әсәрнең идея-эстетик үзенчәлеген арттыра, аның телен баету белән беррәттән әсәрне чынбарлыкка якынлаштыра, персонаж-геройларның психологиясен, характерын тагын да тирәнрәк, милли рухтарак ачарга мөмкинлек бирә.

Шуңы күрә дә Татарстанның халык шагыйре Фәнис Яруллин үз иҗатында аңлы рәвештә фольклорга мөрәҗәгать итә, әсәрләрендә үткәнгә әйләнеп карый, андагы иң уңышлы алым-чараларны файдаланырга омтылды. «Ул халыкның, милләтнең сулышын тоеп, әсәрләрен үзенең кайнар каны, тынгысыз һәм серләргә бай җанының лабиринтлары аша уздырып, кырыс чынбарлык белән бай фантазиясен кушып иҗат итте» (2, 5). «Фәнис Яруллин гади яза, халыкчан яза»; аны «яшәткән, каләмен

йөрткән, иҗатына көч биргән нәрсә – үз халкының язмышы белән бер булып яшәве, хезмәт итүе» (2, 17) дип язалар аның турында каләмдәшләре.

Ф. Яруллинның фолкьлорга битараф булмавы, аның шигъриятендә үк күзәтелә. Ул балачактан ук халыкның яшәү рәвешен күзәтә, җыргамоңга, күмәк уеннарга соклана белә. Истәлекләреннән күренгәнчә, кече яшьтән үк туган авылы – Кызылъярга килгән артистлар, сәнгать әһелләре белән кызыксына. Ф. Яруллин әсәрләренең милли рух, моңга бай образлар тудыра алуы әдипнең киң эрудицияле булуы, әхлакый эзләнүләре нәтиҗәсе булып тора. Чыннан да, халык тормышының һәм яшәешенең ерактан килүче әхлакый чыганакларын автор үзе үткән юлда очраган кешеләрнең типик сыйфатларын гомумиләштерү һәм индивидуальләштерү аша ачып сала. Бу Ф. Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» автобиографик повестендә урын алган фольклор мотивларында аеруча калку күзәтелә.

1973 елда дөнья күргән әлеге повесть яшәү өчен, тормышта үз урынын раслар өчен көрәшкән кеше язмышын сурәтләүгә багышланган. Әсәр авторның үткәннәргә сәяхәтен хәтерләтә: ул уй-фикерләрен үз язмышы аша уздырып аларны әсәр тукымасына төшергән. Повестьның өске катламында Кызыл Кыя авылының, Ык буйларының хозур табигате, кичке уеннар, җырлар стихиясе белән уратып алынган төп герой – Фәнияр Гатауллинның язмышы тасвирлана. Фольклор әсәрләре безгә повесть геройларына карата мөнәсәбәтне билгеләргә, автор позициясен аңларга, теге яки бу күренешкә карата нәтиҗә чыгарырга ярдәм итәләр.

Әсәр текстына үрелгән халык мәкальләре, әйтемнәр, канатлы сүзләр повесть теленә җанлылык өсти, фикерне җыйнак итеп бирүгә хезмәт итә, әсәрдә сурәтләнгән тормышның халыкчанлыгын арттыра. Автор әлеге тәкъбирләрне башлыча төп герой – Фәнияр Гатауллинның әнисе Гөлсәйдә апа авызыннан әйттерә: «Мине яучылап йөргәндә иптәш кызларым: “Әнә, киявең алтмыш тешле атына атланып килә, каршыларга чык”, – дип үртиләр иде» (3, 194). «Китик, мин әйтәм, энә кайда – җеп шунда» (3, 199). «Чыкмаган җанда өмет бар, – диде ана нык ышанып» (1, 205) һ. б. Геройларның психологик портретына мөнәсәбәтле фикерләрне җыйнак итеп бирү максатыннан кулланылган мәкальләр аеруча уңышлы. Халыкның аң төпкелендә яткан әлеге гыйбарәләр геройны төрле яклап аңларга, аның эш-гамәлләренә карата нәтиҗә чыгарырга ярдәм итәләр. Фәниярның сөйнәне – Фәүрия турында автор: «Таулар күчерер – арымас, көннәр буе йөгерер – ялыкмас» дип яза (3, 196).

Күп кешеләр исменнән, халык авызыннан әйтелгән мәкальләр авторга гомумиләштерүләр ясарга, нindидер мәсьәләгә карата үз позиция-

сен ачыкларга ярдәм итәләр. «Ни килсә – бердәнбергә килә» (3, 249), «Аш белән атканга таш белән ату шушы буладыр инде» (3, 260), «Ашаган табагына төкергән нәрсә», «Бүре баласын бүреккә салсаң да урманга карый, ди», «Ит яхшылык, көт явызлык» (3, 261). Картлар, аксакаллар сүзләренә колак салу, аларның киңәшләренә таяну элек-электән тормышкөнкүрештә югары бәяләнгән. Әлеге матур сыйфатны Ф. Яруллин үзенең геройларының гамәлләренә дә, сөйләменә дә салган. Гөлсәйдә гасырлар дәвамында тупланган халык байлыгын сөйләмендә еш куллана: «Ана күңеле балада, бала күңеле далада», – дип юкка гына әйтмиләр шул» (3, 204), «Башыңа төшсә, башмакчы буласың, диләр» (3, 265), «Чынлап торып еласаң, сукыр күздән яшь чыга, дигәннәр бит картлар» (3, 267).

Ф. Яруллин эзлекле рәвештә геройларның эчке дөньяларын тормыш вакыйгалары белән үреп ача. Мәсәлән, Фәнияр кичке уеннарга – су буена яшьләр җыела торган җиргә барып, гармун тавышы яңгыраганын тыңларга, такмак әйтә-әйтә арыганчы биергә ярата:

Бас, бас, бас әйдә, Тыпыр-тыпыр берәү бии,
Ярам, борчак түгелсен; Аягында чабата;
Чакырганда биемәскә Чабатасы да чабата,
Аксак-туксак түгелсең (3, 215). Аны кемнәр ярата? (3, 216)

Фәнияр ялындырып тормыйча биеп китә. Түгәрәктәге яшьләр такмак әйтеп тора. Берсе артыннан берсе шаян җырлар, тапкыр сүзләр, өрләнә такмаклар агыла. Фәнияр «заказ белән шигырь язу» уенында аеруча теләп катнаша, баштагы юлларын халык җырларыннан ала да, ахыргы ике юлын үзе чыгара:

Агыйдел тугай гына, Тыпыр-тыпыр биегәндә,
Йөзәргә уңай гына; Чабаталарың туза;
Синең кебек сайрый ала Үзеңә тиң яр тапмыйча
Һавада тургай гына. Гомеркәйләрең уза (3, 216).

Күренә ки, әсәрнең буеннан буена агылган җыр, моң халык рухын ачу өчен отышлы чара булып тора, әдипнең халык авыз иҗатын тирән белүен ассызыклый. Гомумән, җыр һәм көй әсәрнең буеннан буена кызыл җеп булып сузылалар.

Халык рухын тирәнтен аңлап яшәүче Фәнияр образы ярдәмендә автор укучылар алдында татар авылларында сакланып калган күркәм гадәт-йолаларны ачып сала. «Кызыл Кыя авылында шундый гадәт яши: армиягә китәсе егетләр кыңгыраулы пар-ат җигәләр. Тройка түгел, нәкъ менә пар ат. Билгеле, атларны каеш чуклар, җиз төймәләр тезелгән шлеяләр белән матурлап бизиләр. Кыңгырауның иң моңлы тавышлысы сайлап алына, чыңы ераккарак ишетелсен өчен, ул бик шәп итеп чистартып,

ялтыратып куелган була» (3, 265). Әлеге күренеш язучы тарафыннан яратып, кадерләп сурәтләнә, аңа татар халкы гореф-гадәтләрен укучының күңелендә тергезергә, җанландырырга мөмкинлек бирә.

Ф. Яруллин сюжет корганда текст төзүнең төрле чараларына мөрәҗәгать итеп карый. Шулардан интертекстуальлек, ягъни әсәр эчендә әсәр бирү мөмкинлеләрен дә оста файдалана: мәсәлән, повесть тукымасына әкият мотивын кертеп җибәрә. Сөйгәне Фәниярның шигырьләренә карата Фәүрия үз фикерен «карaурманда кыр тавыгы астында чыккан нәни, көчсез, хыялый чебеш турында әкият» сөйләп җиткермәкче була. «Борын-борын заманда матур яшел аланда, җәйнең аяз көнендә, шәп куаклык төбендә бер чебеш дөньяга килгән» (3, 211), дип башланып китә аның әкияте. Чебеш урманның киңлегенә, аланнарның ямьлелегенә, дөньяның зурлыгына сөенгән мәлдә халык әкиятләренә хас көтелмәгән хәл була – аның янына тилгән очып килә һәм болай ди: «Синең, чебеш, очканың, киңлекләрне кочканың юк. Канат җилпеп күккә менсәң, гүзәллекне өстән күрсәң, әйтер идең: кояшны зур алтын диеп, офыкларны ялкын диеп» (3, 211). Чебеш тилгәннән аны һавага күтәрүен сорый. Өскә күтәрелгәч ул «хозурлыкка хәйран калып, бик күп итеп сулыш алып, очып китмәкче булган. Канаты югын онытып бер талпынган, бер кагынган. Тилгән аны шулчак ялгыш ычкындырган...» (3, 212).

Фәнияр, әлбәттә, кызның фикере белән килешми, канат чыгармаган чебеш шикелле үз тормышы бәрабәренә булса да, аның теләгенә ирешәсе, югарыга күтәреләсе, очу тәмен татып карыйсы килә. «Бер очып караганнан соң тирестә актарынып яшисе килмәс иде», – дигән нәтиҗә ясый ул. Әдип халык әкиятләренә хас традицион башлам белән керешеп, образлы һәм мавыктыргыч сюжетка корылган, йөгерек, шигъри телгә ия булган кыска гына әкият тудыра. Шул рәвешле автор үз позициясен билгели, ә ул исә Фәниярның тормыш девизы белән тәңгәл килә. Алга таба да Фәүрия Фәниярга язган хатларында үзе ишеткән әкиятләрне язып тора. Алар арасында «Бик горур патша кызының кияү сайлавы» турындагы тормыш-көнкүреш әкияте кызыклы. Ахыр чиктә патша кызы «үзен мактаучы, ләкин кулыннан һичбер эш килми торган егет аламасы»на кияүгә чыга. Әлеге әкият Фәүриянең асылын ачып бирә, әдипнең әлеге образга карата мөнәсәбәтен билгеләргә ярдәм итә. Повесть эчендә тәкъдим ителгән әкиятләр Ф. Яруллинның фольклор сюжетларын әсәр кысасына кертеп җибәрү осталыгын, халык җәүһәрләрен «әсәр эчендә әсәр» тудыру өчен файдалана алуын күрсәтә.

Күргәнебезчә, Фәнис Яруллин иҗатында халыкның җанлы сөйләше, теле һәм стиле белән бергә фольклор традицияләренең художестволы ча-

гылыш табуы кызыклы әдәби күренеш. «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре, кичке уеннарда җырланган кыска җырлар, персонажлар авызыннан чыккан мәкаль-әйтемнәр автор тарафыннан бик вакытлы һәм урынлы кулланылуын күзәтергә мөмкин. Шул рәвешле, фольклор поэтикасын яхшы белгән, аның стилен нечкәләп тойган әдип үз әсәрләрендә, сюжет кору, геройларның рухи халәтен өчен, халык авыз иҗатының төрле жанрларыннан, мотивларыннан оста файдалана, аларга нигезләнеп, халык күңеленә тирән үтеп керә.

ӘДӘБИЯТ

1. Гаташ Р. Шагыйрьнең йөз аклыгы / Р. Гаташ // Яруллин Ф. Сайланма әсәрләр: 3 томда / Ф. Яруллин. – Казан: Татар. дәүләт «Мирас» кит. нәшр., 1994. – 3 т.: Шигырьләр, поэмалар, балладалар, җырлар. – 669 б.

2. Хәкимова С. Г. Намуска тугрылык / С. Г. Хәкимова // Фәнис Яруллин: Тормыш юлы һәм иҗаты. – Казан : Мәгариф, 2006. – 167 б.

3. Яруллин Ф. Сайланма әсәрләр: III томда: Повестьлар, кереш сүз / Ф. Яруллин. – Казан: «Мирас» нәшр., 1994. – 616 б.

***Р. С. Эгамшукурова***
***Ташкент, Узбекистан***

## ОДНА ТРАДИЦИЯ, СВЯЗАННАЯ С ЖЕЛЕЗОМ В ЭПОСЕ «АЛПАМЫШ»

В народных сказках и дастанах существуют такие скрижали, которые отражают в себе мировоззрение и народные традиции, связанные с металлом. Их правильная оценка с историко-социальной точки зрения открывает нам древнюю сущность человечества.

В сказках и дастанах успехи героя так или иначе связаны с металлическим оружием и отношением к нему. Средневековые европейские алхимики верили в связь семи металлов с семью основными планетами и с семью божественными персонажами, в том числе думали, что железо касается Марса (1, 146). В литературе железо зафиксировано как пятый элемент (2, 11). В устном народном творчестве герой использует такие орудия шитья, как металлическая игла, большая игла (жуволдиз), нож, меч (копье, кинжал), стрела, лук.

В варианте Берди бахши (сказатель) дастана «Алпамыш» отражается одна народная традиция, связанная с металлом, а именно ножом: Им (Байбури и Байсари – *Р. Э.*) исполнилось тридцать три года, но у них не было детей. Однажды какой-то человек праздновал обрезание своего

сына. Все пришли, накрыли на стол и перед ним поставили казы-карта (колбаса из сырой конины, карта – толстая кишка лошади, приготовленная особым способом). Когда пришли Байбури и Байсари поставили длинную (пустую) кишку и **тупой нож** (3, 7) (подчеркнуто мной – *Р. Э.*). В прошлом бездетного человека считали не имеющим место в обществе, поэтому его не приглашали к празднованию обрезания (4, 41–45). Если бездетный человек приходил без приглашения, его унижали. Унижение проводили во время празднования обрезания, именно в обряде инициации.

В дастане «Малика айяр» (дословно: хитрая малика (царевна)), встречается фраза *«ердан темиртак (темир) топган қулдай бўлиб»* (5, 108) (дословно: быть как раб, который нашёл кусок железа (или тупой нож)), соответствующая значению «радостный». Известный фольклорист Х. Зарифов написал специальную статью об этой фразе. Но в нем нет конкретного заключения имеющейся исторической основы (6, 65). Слово «темиртак» имеет два значения: 1. кусок железа; 2. тупой нож (7, 159). Независимо от того, что означает слова «темиртак», по-нашему мнению, эта фраза соответствует следующему значению: раб, нашедший кусочек железа, владеет каким-нибудь правом, которым не обладают другие рабы.

В целом, посредством любого металлического предмета выражается могущество, владычество мужчины. К примеру, в варианте сказателя Саидмурад Панах угли дастана «Алпамыш», когда скончался падишах Юсуфхан, мудрецы ставят условие: кто хочет стать новым падишахам, тот должен поднять восьмидесяти батманный чугун. Все мужчины постарались поднять, но не смогли. Хакимбек, которому только исполнилось десять лет, поднял этот чугун и метнул в восьмидесяти аршинную даль. После этого он стал обладать и царством, и богатырским именем Алпамыш (8, 8).

По своей сущности все металлические оружия – меч, стрела (лук) и нож (9, 192), которые означают честь мужчины, связаны с железом, которое «является символом могущества» (10, 541). Известно, что с появлением железа ознаменовано начало патриархата. С началом изготовления орудия труда из железа, прежде всего, стало расцветать земледелие, потом скотоводство, кустарный промысел и мужчины заняли значительное место в семье и в обществе.

В выражениях благожелания (айтим-олқишлар), связанных с узбекским детским фольклором, ребенок (сын) сравнивается с ножом: *Отасининг қўш пичоғи* (дословно: парные ножи своего отца), *Онасининг ош пичоғи…* (Кухонный нож своей матери) (11, 46).

У узбеков, когда новорождённого ребёнка в первый раз привязывают к колыбели, в сторону головы (под подушки) кладут небольшую лепёшку, лук, Коран и нож (12, 216–218), а в другом источнике отмечается, что в сторону ноги, вместе с другими вещами, кладут бритву (13, 20). М. Пайзиева оценивала это как свойство железа, защищающее от злых духов. Она также отмечает, что когда умирает человек, на его живот кладут металлические инструменты, такие как нож или ножницы (12, 220–222). В колыбельных песнях мать мечтает о золотой, то есть металлической колыбели: *Булбул қушимнинг боласи, Олтиндандир қалъаси, алла-ё, алла…* (11, 38) *(Мой ребёнок соловушка, У него золотая колыбель, баю-баю…).*

В героических эпосах и сказках (14, 6–13; 32–38) очень оберегается нож, кинжал, меч, сделанные из железа или стали, послужившие средством победы в испытаниях главного героя. После клеветы мачехи молодой человек страдает и однажды находит заржавевший меч. Он очищает этот меч и начинает свою героическую деятельность (14, 32–38). В народных сказках «Килич батыр» и «Бектемир батыр» имя и жизнь героя описывается в связи с этими металлическими предметами (15, 118–124; 144–159). В сказке «Эрназар и Кимяназар» у Эрназара вечный спутник нож, который был унаследован от отца, а Кимяназар (16, 119–135) – название этого ножа. В прошлом узбеки в дом невестки вместо жениха присылали его нож (17; 18, 96), а эмир свой кинжал (19, 223–228). У бурятов на свадьбе невестка держала в правой руке лук (1, 76). Эти обычаи, связанные с металлическими принадлежностями, исполнялись в радостные дни человека. Был обычай и в печальные дни: человек опирался на металлические принадлежности (на свое оружие). Это мы видим в дастане «Рождение Гуругли». Когда Гуругли разыскивает отца и дядю с материнской стороны, извещая о смерти своей матери, его дядя Гаждумбек опирается на копье и плачет с причитанием: «*О, бедная сестрёнка*!» (20, 80). В некоторых русских народных сказках тоже можно встретить металлические предметы как спутник и защитник героя (21, 115–125; 146–154; 193–202).

В сказках меткий стрелок и мастер по фехтованию – главный герой, изучает шестьдесят девять профессий, одним из которых было кузнечное ремесло (22, 136–143; 27–31). У народов, исповедующих ислам, Дауд (пророк – *Р. Э.*) почитается как покровитель металла и металлических принадлежностей (1, 354). Рабгузи отмечает его кузнецом, изготовляющим подковы (23, 28), а Навои фиксирует его изобретателем кольчуги (24, 42), как и в Коране. В настоящее время в народе не только кузнец, но и все пользователи металлических инструментов – шоферы, швейницы,

мастера-плотники, даже строители жилищ устраивают угощения с благотворительной целью в честь Дауда.

Из вышесказанного можно сделать вывод, что металлический предмет (во многих случаях нож) имеет значение могущества, защиты и владычества. Иногда он выражают тотемистические значения: а) указывается на сына как продолжателя рода. Именно этот взгляд отражается в пословице: «Ўғли борнинг ўрни бор» (дословно: кто имеет сына, тот имеет место (в обществе)); б) указывается на могущество, исходя из статуса мужчины в обществе.

ЛИТЕРАТУРА


1. Мифы народов мира. – Т. II. – М.: С. Э., 1988. – 718 с.
2. Жаббор Э. Фольклор: образ ва талқин. – Қарши: Насаф, 1999. – 169 б.
3. Алпомиш (айтувчи Берди бахши). – Тошкент: Ёзувчи, 1999. – 117 б.
4. Урманчеев Ф. Мотив бездетности в тюркском эпосе // Советская тюркология. – Баку, 1988. – № 1. – С. 41–45.
5. Малика айёр. – Тошкент: Ғ. Ғулом номидаги нашриёт, 1988. – 335 б.
6. Зариф Ходи Ердан темиртак топган // Ўзбек тили ва адабиёти. – Тошкент, 1970. – № 4. – 65 б.
7. Ўзбек тилининг изоҳли луғати. Т. 2. – М.: Рус тили, 1980. – 715 б.
8. Alpomish (aytuvchi S. Panoh o'g'li) / Alpomish. Yodgor. – Toshkent: Yozuvchi, 2000. – 175 б.
9. Саримсоқов Б. Ўзбек маросим фольклори. – Тошкент: Фан, 1986. – 216 б.
10. Қуръон. – Тошкент: ТИУН, 2001. – 541 б.
11. Сафаров О. Ўзбек болалар поэтик фольклори. – Тошкент: Ўқитувчи, 1985. – 249 б.
12. Пайзиева М. Тошкент шаҳри ўзбеклари анъанавий дафн ва мотам маросимлари ҳақида айрим мулоҳазалар // Ўзбекистон этнологияси: янгича қарашлар ва назарий методологик ёндашувлар (ЎзРФА академиги К.Шониёзов таваллудининг 80 йиллигига бағишланган халқаро анжуман материаллари). – Тошкент, 2004. – 254 б.
13. Исмоилов Ҳ. Ўзбек тўйлари. – Тошкент: Ўзбекистон, 1992. – 184 б.
14. Ўзбек халқ эртаклари. – Тошкент: Ёш гвардия, 1981. – 286 б.
15. Ўзбек халқ эртаклари. «Қари наъматак». – Тошкент: Ёш гвардия, 1977. – 224 б.
16. Ernazar va Kimyonazar // O'zbek xalq ertaklari. II. – Toshkent: O'qituvchi, 2007. – 384 b.
17. Шониязов К. Карлуки – узбеки. – Ташкент: Наука, 1964. – 196 с.
18. Турдимов Ш. Рўмол рамзининг семантикаси ҳақида // Адабий мерос. – 1985. – №3. – 96 б.
19. Шадманов Т. Р. А. Лиеман о жизненных ритуалах тюрков Средней Азии в переводе Т. Шадманова // Ўзбекистон этнологияси: янгича қарашлар ва назарий методологик ёндашувлар (ЎзРФА академиги К. Шониёзов таваллудининг 80 йиллигига бағишланган халқаро анжуман материаллари). – Тошкент, 2004. – 254 б.
20. Гўрўғлининг туғилиши. – Тошкент: Ғ. Ғулом номидаги нашриёт, 1967. – 328 б.
21. Русские народные сказки. – Ташкент: O'qituvchi. 2007. – 480 с.
22. O'zbek xalq ertaklari. III. – Toshkent: O'qituvchi, 2007. – 384 b.
23. Носируддин Бурҳониддин. Қисаси Рабғузий. 2-китоб. – Тошкент: Ёзувчи, 1990. – 272 б.
24. Навоий А. Тарихи анбиё ва ҳукамо. – Самарқанд. 1990. – 138 б.

# СӘНГАТЬ БЕЛЕМЕ

*Р. И. Габдрахманов*
*Казань*

## ЭТНОКУЛЬТУРНЫЙ КОМПОНЕНТ ОРГАНИЗАЦИИ УЧЕБНО-ВОСПИТАТЕЛЬНОЙ ДЕЯТЕЛЬНОСТИ ПО СОХРАНЕНИЮ И РАЗВИТИЮ ТАТАРСКОЙ КУЛЬТУРЫ В ДМШ И ДШИ (На примере ДШИ № 4 г. Казани)

Воспитание в духе лучших национальных традиций – изначальное условие развития нравственности и духовности. Любовь и интерес к культурным ценностям и историческим традициям родного края – важнейший фактор, определяющий патриотическое начало личности. Детские школы искусств и детские музыкальные школы – неоценимые по значимости звенья системы дополнительного образования детей, призванные решать проблемы духовно-нравственного совершенствования подрастающего поколения. Огромная роль в решении этих проблем принадлежит патриотическому воспитанию, но не стихийному, а продуманному и планомерному, включающему не только изучение истории республики, татарской музыкальной культуры, национальных обрядов и праздников, но и воспитание чувства гордости и ответственности за свое Отечество, потребности достойно представить музыкальное искусство Татарстана на сценических площадках школы, района, города, страны и мира.

Татарская музыка является составной частью мировой музыкальной культуры, в ней находит свое отражение специфика художественного мышления татарского народа. В условиях современного информационного пространства очевидно, что при изучении характерных национальных особенностей наилучший результат может быть получен в случае использования двух взаимодополняющих ракурсов рассмотрения предмета: культурно-типологического и аутентично-контекстуального. Первый позволяет создать «панорамное» представление изучаемого предмета, понять его отличительные особенности в контексте мировой

культуры. Второй направлен на постижение предмета «изнутри», выявление его имманентных свойств; другими словами, позволяет реконструировать связанный с ним тип художественного мышления, объяснить особенности его функционирования.

Критерием эффективности любого учебного курса является способность ученика к развитию навыков, полученных в процессе обучения. В данном случае таковым следует считать способности эстетического осознания интонационных, структурных, образно-философских и других особенностей татарской музыки. Пути практической реализации данной основной цели исходят из дидактического принципа, сформулированного практикой прошлого века как раскрытие и понимание «музыкальных красот». Современная методика общего образования ориентируется именно на развитие «понимания музыкальных красот», которое выражается в доминирующем положении навыков творчества в трех основных формах – сочинение, исполнение и слушание музыки. Очевидно, что слушание музыки может стать творческим актом только при условии возникновения эмоциональной и/или интеллектуальной реакции. Поэтому педагогу необходимо внимательно отнестись к дидактически сложной задаче: изучение должно мотивироваться тем, что музыка «красивая» и «интересная».

Полноценная эстетическая реакция на музыку может возникнуть только при наличии навыков восприятия ее структуры. Поэтому особенно важно как можно раньше ввести в музыкальный кругозор ученика интонационные особенности и ритмические формулы, свойственные татарской музыке.

Изучая татарскую музыку, необходимо применять принцип выдерживания ладо-интонационной сферы на протяжении продолжительного периода занятий лучшему «вживанию» в нее слуха.

Обязательное практическое синхронизированное освоение образцов татарской музыки при взаимодействии учебных дисциплин дает наиболее плодотворный результат. Важно не допускать восприятие татарской музыки в качестве изолированного объекта.

Существует важный для раскрытия креативного потенциала учащихся предмет, как «творчество», включающий в себя импровизацию и композицию.

Композиция как вид музыкальной деятельности наиболее отвечает идее воспитания патриотизма посредством музыкальной творчества. Здесь ведется поиск одаренных детей, способных продолжить традиции лучших представителей национальной композиторской школы.

Важным в образовательном процессе школы является введение в программу предмета «Татарская музыкальная литература», на котором происходит углубленное знакомство с профессиональной и народной татарской музыкой: творчеством татарских композиторов, лучшими образцами национальной культуры.

На уроках специальности уже с первых лет обучения в репертуар учащихся включаются оригинальные произведения татарских композиторов и обработки народной музыки. Особое внимание уделяется игре на национальных инструментах: курае, гармони. На базе школы созданы ансамбли, концертный и конкурсный репертуар которых основан на татарской музыке.

Хоровых, ансамблевых и оркестровых произведений в репертуаре музыкальных школ недостаточно. Преподаватели реализуют свой творческий потенциал, создавая переложения народных песен, танцев, отрывков из опер и балетов татарских композиторов для фортепиано, струнно-смычковых и струнно-щипковых инструментов, вокальных ансамблей и хора, оркестра народных инструментов.

На отделении хореографии изучаются элементы народно-бытового танца. Через движения, музыку, костюмы учащиеся знакомятся с национальными обычаями и культурой татарского народа.

Сочетание таких способов развития творческой активности, как коллективное музицирование, изучение национального репертуара и выступления на концертных площадках имеет ярко выраженное воспитательное значение: у учащихся усиливается чувство гордости за свой коллектив и осознание своей роли в нем, а также радость быть причастным к общественным и музыкальным событиям Татарстана.

| **Наличие учебных часов, направленных на изучение культуры Татарстана** (неделя) | |
|---|---|
| Предмет | Количество часов |
| Специальный предмет | 0,5 |
| Творчество (композиция) | 1 |
| Татарская музыкальная литература | 1 |
| Исторический бытовой танец | 0,5 |
| Народный танец | 0,5 |
| Оркестр народных инструментов | 2 |
| Малые ансамбли | 0,5 |
| Хор | 1 |

Часть преподавателей школ свободно владеет татарским языком и имеет возможность вести уроки на родном языке, а также проводить тематические вечера, посвященные творчеству деятелей культуры Татарстана, фольклорные праздники, включающие, помимо музыки, элементы литературной драматургии и театрализации, например, «Навруз», «Сабантуй», «День матери».

Музыкальный кругозор учащихся расширяет постоянное участие в ежегодно проводимых в городе и республике конкурсах исполнительского мастерства. Самые яркие из юных исполнителей пропагандируют национальное искусство за рубежом, участвуя и побеждая в Международных конкурсах. Юные музыканты осознают высокую честь – представлять свою школу, свой город, свою Республику. Эти моменты являются наиболее яркими и действенными в комплексе мер, призванных воспитывать патриотическое начало.

Одним из основных средств формирования национального самосознания является знакомство с творчеством современных композиторов Татарстана. Налажена тесная связь с творческим союзом композиторов Республики Татарстан, гостями школы были Р. Еникеев, Р. Ахиярова, Р. Еникеева, Ш. Тимербулатов.

ЛИТЕРАТУРА

1. Раимова С. И. История татарской музыки: Учебное пособие. – Казань, 1986.

2. Нигмедзянов М. Н. Народные песни волжских татар. – М.: Сов. композитор, 1982. – 136 с.

3. Ахметьянов Р. Г. Музыкальные термины в поэме «Хусрав и Ширин» Кутба в их отношении к поволжскому тюрки // Страницы истории татарской музыкальной культуры. – Казань, 1991. – С. 109–115.

4. Давлетшин Г. М. Волжская Булгария: духовная культура (Домонгольский период X – нач. XIII вв.). – Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. – 192 с.

5. Джумаев А. Б. Ислам и музыка // Музыкальная академия. – 1992. – № 3. – С. 24–34.

6. Исанбет Ю. Огни, зажженные Сайдашевым: [вступ. ст.] // Сайдашев С. Огни, зажженные нами. – Казань: Татар. кн. изд-во, 1980. – С. 514.

*Э. М. Галимова*
*Казань*

# РЕКРУТСКИЕ ПЕСНИ ПЕРМСКИХ ТАТАР

Татароязычное население пермского этнокультурного региона в составе субэтноса казанских татар образует пермскую этнографическую группу. Пермские татары состоят из нескольких групп: 1) тулвинские татары (Бардымский район), 2) сылвенско-иренские татары (расселены по течению р. Сылва и р. Ирень и их притоков, 3) муллинская группа (Пермский район).

Изучение этнического формирования коренного населения данного края фактически началось ещё с XIX века. В настоящее время накоплен уже значительный материал. Ознакомление с научной литературой позволило выявить по данной проблеме различные точки зрения. Вопрос этногенеза пермских татар сыграл решающую роль в формировании музыкальных традиций и сохранении обрядов данного края. Некоторые образцы семейного обрядового фольклора пермских татар, уже неоднократно служили предметом внимания многих лингвистов, фольклористов [Р. К. Уразманова, А. В. Черных, Д. Б. Рамазанова]. В данной статье мы хотим обратить внимание на традиционные формы проведения обряда *солдатка озату, рекорт озату* (проводы солдата, проводы рекрута) и выявить особенности песен, исполнявшихся во время обряда[1].

Жанр рекрутской песни является одним из самых распространенных в Пермском крае. Обращение народа к этой теме было вызвано введением в России Петром I всеобщей воинской повинности (XVIII век). Однако ещё до указа Петра I чуваши, татары, марийцы, мордва, удмурты привлекались к военной службе в русской армии и поставляли во время войн по одному воину с трех ясачных дворов (4). Для населения многих этнографических групп, живущих обособленно, занимавшихся преимущественно сельским хозяйством, не знавших государственного языка и русской грамоты – рекрутчина воспринималась как трагедия и являлась фактически социальным бедствием, ибо в те времена служба длилась 25 лет.

В пермском крае существовало несколько традиций проведения обрядов: *солдатка озату, рекорт озату*. Сразу же после получения повест-

[1] Материалом исследования послужили экспедиционные записи автора, сделанные в июне 2011 года.

ки ритуал проводов *рекрута* (*рекорт, некорт, лекорт*) продолжался две недели. Каждый житель деревни приглашал его в гости. Затем в доме новобранца устраивали проводы с участием всех его соседей, родственников и друзей, которые приходили с подарками, а девушки дарили вышитые носовые платочки. Исследователь Р. К. Уразманова подчеркивает, что гостевания призывников проводились, как правило, в сроки *сабантуя* – весной, до сева. Известны факты призыва на воинскую службу и в осенний период времени. Вызывает интерес, что обряд поочередного гостевания рекрутов, длившийся несколько недель в деревнях Западного Предкамья, именовался аналогично весеннему обряду *сөрән (сөрән сугу, сөрән чабу),* связанный со сбором яиц (реже подарков), с последующим угощением. По данным Р. Уразмановой, этот обряд входил в комплекс праздника *сабантуй* (7, 102). По этимологическому толкованию, слово *сөрән* (общетюрк.-*сурән*) означает «тревога, клич, созыв войск» (2, 69). Возможно поэтому татары Предкамья, трактуют *сөрән* как созыв на воинскую службу. У пермских татар термин *сөрән* трактуется, скорее всего, как клич для участия народа в состязаниях на майдане в начальном этапе *сабантуя.*

С целью обезопасить новобранца на службе и его скорого возвращения, пермские татары придерживались определенных традиций магического характера. Так, существовал обряд, когда рекрут перед отъездом на службу надкусывал каравай хлеба. Этот каравай мать хранила до его возвращения: «Еда у тебя здесь лежит, дожидается своего хозяина»[1]. Данная традиция, которую проводили пермские татары, полностью совпадает с проведением обряда *проводы казака* (казак озату) у нагайбаков (3, 173). Примечательно, что пермские татары во время проводов готовили блюда из курицы, в связи с символическим представлением об этой птице: «курица гребет назад – солдат должен домой вернуться». Существовало и такое поверье, связанное с тем, что рекрут обводил вокруг пояса живой курицей, которую затем варили и отдавали ему в дорогу.

У тулвинских татар существовала обычай перед отъездом рекрута на службу, читать суры Корана. Не меньший интерес представлял обряд разделения бумажного листочка с записью мусульманской молитвы на две части: одну отдавали рекруту, а вторую оставляли дома. Считалось, что это способствует возвращению солдата, так как текст молитвы в бу-

[1] Записано со слов этнофора Минсадыровой Гадили Шариповны, 1938 г. р. из д. Усть-Турка Кунгурского района).

дущем непременно должен соединиться со своим смысловым продолжением (8, 261).

По другой традиции, *рекрут,* направляясь в дорогу, через порог своего дома должен был перешагивать с правой ноги. Знаковым считалось также поверье, как лошадь сделает свой первый шаг, отправляясь в путь: с правой ноги – определяли, что воинская служба будет хорошая, а если с левой – плохая. Когда жители провожали рекрута, все махали платками в свою сторону, а не от себя, для того, чтобы солдат как можно раньше вернулся с армейской службы. Мероприятия, связанные с проводами рекрута, сопровождались песнями и инструментальными наигрышами. Обязательным, во многих районах Пермского края, считалось в исполнении новобранца песни с текстами собственного сочинения. Лучшие из созданных песен сохранялись в народном репертуаре.

Ритуалы проводов в солдаты в наибольшей степени были развиты у тулвинских татар. Нами зафиксированы несколько образцов наигрышей на губной гармони «Шаян җыр», «Барда көе»[1]. Данные напевы исполняются также на тальянке и гармони во время застолья во время проводов рекрута. Инструментальные наигрыши тулвинских татар, аналогично удмуртам, отличаются узким амбитусом с обыгрыванием секунды и терции при повторяющемся ритмическим клише на фоне бурдонного баса (5, 158–169). По материаллам экспедиции, можно выявить, что некоторые рекрутские песни сылвенско-иренских татар[2] исполнялись на напевы, популярные у казанских татар и казанско-татарских кряшен. Например, основой напевов песен «Фронт җыры», «Сугыш елы такмаклары» послужили напевы *авыл көе,* известные у казанских татар как «Без дә биек таулар бар», а в песне «Армияга озату җыры» ярко выражено интонационное сходство с известным напевом кряшен «Суда балык йөзәдер».

| | |
|---|---|
| *Казарма биек булса да* | *Хоть высокая казарма* |
| *Кошлар оя ясамый* | *Птицы гнезда свои не вьют* |
| *Ай булса да, гөл булса да* | *Как бы не было все прекрасно* |
| *Туган илгә ошамый.* | *Не заменит родину мою.* |
| *Әйдә барыйк ар якларга* | *Пойдем на дальную чужбину* |
| *Сатин алыйк чаршауга* | *Купим сатин на занавески* |
| *Чит җирләрдә йөрсәм дә* | *На стороне я все хожу* |
| *Шөкер итәм баш сауга.* | *Жив, здоров, за все благодарю.* |

[1] Записаны от этнофора Зимасова Маулизяна Мухаматзяновича 1940 г.р. из д. Ишимово Бардымского района Пермского края.

[2] Записаны от этнофора Минсадыровой Гадили Шариповны, 1938 г.р. из д. Усть-Турка Кунгурского района.

| | |
|---|---|
| *Җаныкаем илдән киткәч* | *Как уехал я родная* |
| *Күрмәдем мин бер калач* | *Не пробовал не один калач* |
| *Иркәләргә ирең булмас* | *Не кому тебя любить* |
| *Солдатка булып калгач.* | *Раз осталась ты солдаткой.* |
| *Снарядлар ярылганда* | *Когда разрываются снаряды* |
| *Җимерелә калалар* | *Разрушаются города* |
| *Чит җирләрдә ятып калсам* | *Если останусь на чужбине* |
| *Ятим кала балалар.* | *Сиротами останутся мои дети.* |

Рекрутские песни муллинской группы пермских татар в основном трактуются в жанре *такмак,* со всеми характерными для этого жанра мелодико-ритмическими особенностями. Нами были зафиксированы песенные образцы «Армияга озату», «Солдат җыры»[1], из которых первая явно напоминает песню казанских татар «Ах, җаныем суларда».

| | |
|---|---|
| *Сау бул инде Кояново,* | *Прощай, прощай Кояново* |
| *Сәфәр тауларың белән* | *И горы Сафар* |
